ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ISSN 0130-2418

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

№ 11 (358)
НОЯБРЬ 2021

ТАТАРСТАН – УРТАК ЙОРТЫБЫЗ

ДУСЛЫКНЫ НЫГЫТУДАГЫ КАЗАНЫШЛАР ӨЧЕН

Редакция басмабызның ноябрь санын чакырылган мөхәррир – һөнәре буенча да, холык-фигыле буенча да дуслык җанлы ТР Халыклар дуслыгы йорты директоры Ирек Шәрипов җитәкчелегендә әзерләде.

Планеркада «Татарстан» чакырылган мөхәрриргә басмага 1977 елда тапшырылган Халыклар дуслыгы ордены белән мактанды. Журналыбыз СССР ГМЧ чаралары арасында иң беренчеләрдән булып әлеге абруйлы бүләккә лаек булган.

– Халыклар дуслыгы ордены – үзенчәлекле бүләк ул! – диде Ирек Илдусович. – Орден 1972 елда социалистик милләт һәм халыклар арасында дуслыкны һәм туганнарча хезмәттәшлекне ныгытуда ирешкән казанышларны билгеләп үтү өчен гамәлгә куела. Шуңа күрә безнең басманың әлеге бүләккә ия булганлыгы турында ишетү аеруча күңелле. Ул вакытта мин әле «Татарстан» журналының укучысы түгел, басма да «Татарстан коммунисты» дип атала иде. Бүген «Татарстан»ны мин генә түгел, безнең Дуслык йортына йөрүче бик күп милләт вәкилләре – рус, татар, грузин, үзбәк, ингуш, украин, кореяләр дә укый. 37 диаспора, 37 тел, 37 төркем дус бездә! Татулыкка чикләр юк дип кенә әйтәсе кала – тел ягыннан да, территория буенча да, милли яктан да!

Дуслык йорты директоры «Татарстан» редакциясенең милли составына да күз төшереп алды, процентларда санап та чыгарды: кайсы милләт күпме, катнаш никахларны да барлады, нәтиҗәләрдән канәгать калды кебек.

– Редакция коллективы журнал эшчәнлегенең 100 елы дәвамында үзенең күпмилләтле составы белән аерылып тора, – диде ул. – Бу турыда хәттә «Википедия»дә дә укып белеп була – мөхәррирләр һәм хәбәрчеләрнең фамилияләре ил географиясендә чагылыш тапкан: Таняев, Мансуров, Корбут, Хатаевич, Гыймранов, Абдуллин, Баскин, Пинхасик, Мөхәммәтов, Гыйльманов, Вәлиев, Афанасьев, Мостафин... Ә «Татарстан» журналының күренекле һәм даими авторларының фамилияләре гомумән бөтен дөнья географиясен чагылдыра: Горький, Маяковский, Ольшанский, Бабель, Жаров, Тихонов, Инбер, Кольцов, Якупов, Җиһанов, Айтматов... Журнал юкка гына үз республикасы исемен йөртми. Ул шундый ук күпмилләтле һәм дус-тату. Безнең уртак тырышлыкта эшләнгән саныбыз да шундый ук булып чыгар, дип өметләнәбез.

Сезнең күпмилләтле редакциягез

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасары:
Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Чыгарылыш мөхәррире:
Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре:
Олеся Бондаревская, Ольга Туманская,
Руфия Фазылова
Авторлар: Илдус Заһидуллин, Луиза Шарова
Фотографлар: Александр Ефремов, Илнар Өметбаев
Дизайн-макет: Олег Бурилов
Вёрстка: Игорь Глушков, Олег Бурилов
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Ләйсән Һадиева
Тышлыктагы фото Турсуной Хәбибуллаеваның шәхси архивыннан

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1977 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
2 400 данә
Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми.

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ №: Е-3658
Басарга кул куелды: 15.11.2021
Басмадан чыкты: 19.11.2021
Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева,
milyaushanb@tatmedia.com
Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:
Алсу Троицкая, alsu_1970@list.ru
тел.: (843) 222-09-79

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 2350 данә тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 4750 данә
Реклама 16+

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФАЗЛЫЕВА Ләйлә Ринатовна
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче:
«ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла
Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә
Ярты елга язылу бәясе: **960 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

100 яшь «Татарстан» журналына

\# Татарстанның 100 җәүһәре

\# бары тик Татарстанда

Бөтен дөнья әлифбалары

Дөньяда бердәнбер «Әлифба» музее Татарстанның Арча районында урнашкан. Музей экспозициясе дөнья халыкларында язма телнең барлыкка килүе һәм үсеше турында сөйли. Кайлардан гына килмиләр музейга – Норвегия, Финляндия, Германия, Франция, Италия, АКШ, Китай һәм башка илләрдән. Килүчеләр һәрвакыт экспонатлар арасында иң әүвәл туган телләрендәге әлифбаны эзләргә керешә. Һәм кагыйдә буларак табалар да – биредә 65 телдә басылган әлифба бар! Араларында иң кыйммәтлеләре – 1778 елда Сәгыйть Хәлфин тарафыннан төзелгән татар әлифбасы, шулай ук 1634 елда Мәскәүдә Василий Бурцов-Протопопов нәшер иткән рус әлифбасы.

© «Татарстан» журналы

WWW.PROTATARSTAN.RU

ЭЧТӘЛЕК

акыллы гамәлләр

6. Тынычлык һәм дуслык ассамблеясе
Дуслык йорты ни өчен төрле халыкларны туплау үзәгенә әверелде

14. Бәһрам Талыб оглы Мостафаевтан сабак
Туган яктан еракта үз телеңне һәм гореф-гадәтләреңне ничек сакларга

18. Әгәр мин милләтләр министры булсам
«Бурят милли-мәдәни автономиясе» иҗтимагый оешмасы рәисенең фикере

40. Халыклар дуслыгы сезнең өчен нәрсәне аңлата?
«Татарстан» журналы сораштыруы

игелекле эшләр

44. Миһербанлы затлар
Лаеш балалар йортының Әнисе

54. Венгр телендә күпме татар сүзе бар,
яисә Венгрия консулы кайсы татар ризыгын яратып ашый

мәңгелек кыйммәтләр

64. Тарих сәхифәләре
Кодрәт һәм түзем иясе Закир Кадыйри

68. Атаклы татарлар
Кытай сәясәте аксакалы

76. Безнең киштәдә
Яңа фильмнарга күзәтү

80. Татар авыллары
Урау юллар аша кире кайткан мәчетле авыл

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта: protatarstan.ru

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

8.10

Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Президенты, – Татарстан Республикасы Дәүләт Советына еллык Юлламасында:

– Татарстанда игълан ителгән Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елында без республикада яшәүче барлык халык вәкилләренең туган телен, мәдәниятен һәм гореф-гадәтләрен саклау һәм үстерүгә, күпмилләтле халкыбызның бердәмлеген ныгытуга, шулай ук татар милләтен берләштерүгә, ватандашларыбызга һәрьяклап ярдәм күрсәтүгә аеруча зур игътибар бирәбез. Һәр милләткә аның үзенчәлеген саклау, мәдәниятен үстерү һәм башка халыкларның мәдәнияте белән танышу, аңа якынаю мөмкинлеге бирү гаять мөһим. Һәркемнең кабатланмас шәхес булуын тану һәм үзара хөрмәт – гражданнар арасындагы бердәмлекнең нигезе.

28.10

Зилә Вәлиева, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе:

– Әйе, бездә төрле халыкларның бергә яшәү традицияләре кереп урнашкан, әйе, бездә төрле халыкларның мәдәниятен саклап калу юнәлешендә иҗтимагый берләшмәләр яхшы тәҗрибә туплаган. Әмма бүген динара татулык һәм халыклар дуслыгы темасы тагын да актуальләште кебек. Ул шулкадәр мөһим ки, дәүләт дәрәҗәсендә дә, гражданлык дәрәҗәсендә дә һичкайчан көн тәртибеннән төшмәде һәм төшмәячәк тә.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

28.10

Рамазан Абдулатыйпов, Россиянең Ислам хезмәттәшлеге оешмасындагы вәкиле, – «Многоликая Россия» XIII Бөтенроссия ачык журналистлар конкурсы җиңүчеләрен бүләкләү тантанасында видеомөрәҗәгатьтә:

– Татарстан – Россиянең милли сәясәт, милли тормышны һәм мәдәниятләрне көйләү-үстерү мәсьәләләре белән актив шөгыльләнә торган бик аз төбәкләреннән берсе. Республикада бер милләт тә игътибардан читтә калмый. Телләр һәм мәдәниятләр мозаикасы күпмилләтле бердәм мәдәният булып берләшә. Татарстанның уңышы әнә шуның белән бәйле.

Акыллы гамәлләр

акыллы гамәлләр /

Мәңгелек кыйммәтләр

Игелекле эшләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Бер урында 173 төрле милләт **НИЧЕК** яши

Дуслар ковидта **НИЧЕК** сынала

Диаспора җитәкчеләре **НИЧЕК** министр булып карадылар

ТАТАРСТАН – УРТАК ЙОРТЫБЫЗ

Татарстанда 173 милләт вәкиле яши. Димәк, 173 төрле тел, 173 төрле мәдәният, 173 төрле гореф-гадәт, менталитет, ниһаять. Аңлап җиткермәгәннәр өчен бу, бәлки, зур ыгы-зыгыны күз алдына китерүдән алынган җиңелчә шоктыр. Татарстанлылар өчен исә – горурлык өлкәсе, тормыш нормасы.

Без төрле телләрдә сөйләшәбез һәм бер-беребезне тылмачсыз да аңлыйбыз. Без үз традицияләребезне дә саклыйбыз, башкаларның гореф-гадәтләрен дә хөрмәт итәбез. Безнең мәдәниятләр, төрле булсалар да, бер-берсенә көндәш түгел, бәлки, үзара баю чыганагы. Гаҗәпме? Юк! Татарстан – уртак йортыбыз, дип раслый республикада яшәүче төрле милләт халыклары. Ә үз йортың – һәрвакыт җылы учак, уңайлы урын һәм сине ярты сүздән аңлый торган якын кешеләр дигән сүз ул. Башкача була да алмый.

Фото: …ександр Ефремов

МИЛЛӘТЛӘР АРАСЫНДА ТАТУЛЫК ЮЛЫН САЙЛАУ – ИҢ НӘТИҖӘЛЕСЕ

Автор: **Татьяна Вафина**

«Друга я никогда не забуду, если с ним повстречался… в ДД», – дип көйли-көйли бара грузин милли киемен кигән ханым коридор буйлап. Атаклы совет фильмында яңгыраган сүзләргә Казанда, безнең очрашу урынында, яңа төсмерләр өстәлә. Нәкъ менә биредә, тиңдәшсез татулык мохите хөкем сөргән Халыклар дуслыгы йортында, «Татарстан» ТР Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан халыклары ассамблеясе Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин белән очрашты. Халыклар дуслыгы йортында киң күләмле реконструкция үткәрергә җыеналар, без Фәрит Хәйруллович белән аның нинди булачагы турында да сөйләштек.

ҮТКӘННӘРДӘН – КИЛӘЧӘККӘ

– Монда безнең – бию залы, ә биредә Татарстан халыклары ассамблеясенең тарих музее булачак. Шунда ук конференц-зал һәм аппаратура урнашкан видео-тавыш яздыру студиясе урнашачак, – дип сүзгә керешә Халыклар дуслыгы йорты директоры Ирек Шәрипов, «киләчәк» буенча экскурсияне башлап.

– Халыклар дуслыгы йорты бөтенләй булмаган заманнар да бар иде бит... Ә бүген коридорда үзбәкчә, казахча һ.б. телләрдә сөйләшүләрне ишетү, бәйрәмнәрдә әрмән яисә грузин сыйларын тәмләп карау мөмкинлеге бездә гадәти хәл кебек кабул ителә. Төрле халыкларның җырларын тыңлау, аларның биюләренә соклану... Фәрит Хәйруллович, мондый йортны төзү идеясе туганда аңа чыннан да ихтыяҗ булачагына ышанычыгыз бар идеме?

– Киләсе 2022 елда Татарстан халыклары ассамблеясенә нигез салынуга 30 ел тула. Ерак 1992 елда республика җитәкчелеге, беренче Президентыбыз Минтимер Шәймиев Татарстанда халыкларның уртак тату тормышы өчен ниндидер институт һәм инструментарий булдырырга кирәклеген аңлады. Халыкларның беренче җыены узды, анда Милли-мәдәни җәмгыятьләр ассоциациясен оештыру турында резолюция кабул ителде. Ассоциация республика Юстиция министрлыгында теркәү узды. Җыенда ассоциациянең рәисе итеп Сәгыйть Җаксыбаев сайланды.

Әлбәттә, ул вакытта әле бернинди дә махсус бина юк иде. Казан Кремлендә бүлмә бирелде, Президентның мәдәният фонды аша берникадәр акча бүленде – юл башы шундый иде. Ассоциация һәм аңа кергән тугыз иҗтимагый милли-мәдәни җәмгыять төрле чаралар үткәрә башлады, шул исәптән дәүләт оешмалары белән бергә дә. Бу эш елдан-ел киңрәк колач ала барды, һәр яктан хуплау тапты. Һәм 2012 елда ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов ярдәме белән Россиядә мондый биналар арасында иң зур, җиһазландырылган, уңайлы йорт – Татарстан халыклары дуслыгы йорты үзенең ишекләрен ачты, аңа сулыш өрергә кирәк булды. Шул рәвешле биредә якшәмбе мәктәбе, үзешчән сәнгать коллективлары урын алды, әкренләп Дуслык йорты төрле халыкларны үзенә тартып торган үзәккә әверелде.

Тәүлекнең кайсы гына вакытында керсәң дә, биредә тормыш гөрли! Бу еллар эчендә Ассамблея тарафыннан үткәрелгән чараларның саны бик күпкә артты. Бу республикакүләм һәм һәр халыкта күп булган милли бәйрәмнәрне оештыру гына түгел. Татарстан районнары һәм шәһәрләрендә Дуслык йортының филиаллары пәйда булды. Муниципалитетлар эшенең көйләнгән системасы безнең дуслык, татулык, халыкларны аңлау төшенчәләренә НӘРСӘ салынганын әйтергә мөмкинлек бирә – иң беренче чиратта бу һәр халыкның үз мәдәниятен, телен саклау буенча позициясен яклауга юнәлдерелгән эшчәнлек. Бу – без иҗтимагый-дәүләти дәрәҗәдә хуплауга күтәргән мирас. Һәм Халыклар ассамблеясе боларның барысында да гаять мөһим роль уйный. Күптән түгел генә Президентыбыз Рөстәм Миңнеханов Милләтләр эшләре буенча федераль агентлык җитәкчесе Игорь Баринов белән очрашты. Бу очрашуда Агентлык җитәкчесе Татарстанда төрле халыкларны, телләрне һәм мәдәниятләрне якынайту өчен гаять зур эш башкарылуын билгеләп үтте. Мондый бәя бик кадерле! Соңрак ул миңа шалтыратты һәм: «Татарстанда мин күргәннәр – әлеге тематика буенча ил күләмендә күргәннәремнән иң уңышлысы. Болар турында сөйләтү өчен сезне ничек Мәскәүгә чакырыйк икән?» – диде.

Бик рәхәтләнеп сөйлим – болар барысы да эшләнгән бит инде, бернәрсә дә уйлап чыгарырга кирәкми!

ИХТЫЯҖДАН ЧЫГЫП ЭШ ИТӘБЕЗ

– Ягъни Татарстанның икътисадтагы, социаль сферадагы, иҗтимагый киңлекләрне үстерүдәге уңышлары кебек үк, республикада яшәүче халыклар арасында милләтара татулыкны ныгыту тәҗрибәсенә дә федераль дәрәҗәдә ихтыяҗ бар булып чыгамы?

– Без башкалардан алдарак йөгерү максатын куймыйбыз. Без ихтыяҗдан, кирәклектән чыгып эш итәбез. Татарстан халыклары ассамблеясе,

1

«Киләчәк» буенча экскурсияне Халыклар дуслыгы йорты директоры Ирек Шәрипов үткәрә.

2

Дуслык йортында кабынган дуслык онытылмый.

Дуслык йорты, аның муниципалитетлардагы филиаллары чыннан да кирәк. Безнең составта яшьләр юнәлеше дә актив эшли – ата-бабаларның йолаларын, гореф-гадәтләрен, җыр-биюләрен саклап калуда ярдәм итү өчен яшьләрне үзебезнең эшчәнлеккә тартырга тиешлегебез ачык күренә.

Чит ил студентларына, бигрәк тә Казанга килгән беренче курс студентларына, мондагы тормышка җайлашуда ярдәм кулы сузу Яшьләр ассамблеясе эшенең аерым юнәлеше булып тора.

Менә, сезгә мисал да. Кем бар безнең монда?

– Студентлар, – дип, аудиториягә чакыра безне Халыклар дуслыгы йорты директоры. – Ислам университетында укып, журналист булырга хыялланучы беренче курс студентлары өчен оештырылган мастер-класска рәхим итегез.

– Әгәр хыялланалар икән, димәк, булачаклар! – дип канат куя яшьләргә Фәрит Хәйруллович.

Булачак журналистлар Татарстан халыклары ассамблеясе Советы рәисе белән истәлеккә фотога төшә, һәм без кечкенә генә сәяхәтебезне дәвам итәбез.

– Федераль дәрәҗәдә даими чыгышлар ясарга тырышабыз, Татарстанда оештырыла торган зур чараларга башка төбәкләрдән коллегаларыбызны чакырабыз, – дип дәвам итә әзелгән әңгәмәбезне Фәрит Мөхәммәтшин. – Республикага килгән рәсми делегацияләрне Дуслык йортына һәм Ассамблеягә китерергә тырышабыз, уңышларга ничек ирешүебез турында сөйлибез-күрсәтәбез. Без үз тәҗрибәбезне бөтен Россиягә актив тарату бурычын куймыйбыз. Мөгаен, кайдадыр эш итүнең башка формалары да бардыр. Мөгаен, бөтен төбәкләр дә безнең кебек күпмилләтле түгелдер – бездә 173 милләт яши бит! Әмма Татарстан сайлаган юл безгә иң нәтиҗәлесе, уңышлысы кебек тоела. Бу турыда Мәскәүдән һәм башка төбәкләрдән килгән кунаклар да еш кына билгеләп үтә. Ә без уртача алганда елына 40 делегация кабул итәбез!

МӘКТӘП ИЛЕ

...Дуслык йортының өченче катын реконструкцияләү әлегә каралмаган. Биредә барысы да күзне иркәли. Уңайлы, якты, матур. Чөнки без Күпмилләтле якшәмбе мәктәбендә. Әниләр үзләренең кечкенә укучыларын урамда түгел, холлга куелган йомшак диваннарда көтеп утыра.

– Быел мәктәп оешуга 25 ел булды, – дип, зур горурлык белән сүзен дәвам итә Фәрит Хәйруллович. – Ул Казанда яшәүче төрле милләт балаларына һәм өлкәннәргә туган телләрен, милли мәдәниятләрен һәм гореф-гадәтләрен, фольклорын, җыр-биюләрен, үзләренең тарихи ватаннарының тарихын һәм географиясен өйрәнү өчен мөмкинлек тудыру максатында ачылган иде. Монда 460 кеше укый. Алар өчен 21 бүлек эшли, шуларның 18е – милли, тагын әле вокал, хореография һәм чит телләр бүлекләре дә бар.

Мәктәп укучылары – бу безнең һөнәри артистлар, сүз уңаенда әйткәндә, халыкара конкурслар лауреатлары!

Без дипломнар куелган стенд янына киләбез: «Энҗе бөртекләре» вокаль күпмилләтле коллективы, «Агыйдел дулкыннары» башкорт биюе ансамбле, «Сантош» һинд биюе ансамбле, «Кавказ» дагстанлылар биюе ансамбле...

Ә «Оцнеба» грузин биюе ансамбленең дәртле чыгышын күрү бәхетенә дә ирештек – хореография залында репетиция бара иде...

– Мәктәп мәктәп инде ул, якшәмбе мәктәбеме, башкамы – мөһим түгел, – ди Фәрит Хәйруллович. – Алар һәрвакыт нәрсәгәдер әзерләнәләр, һәрвакыт кайдадыр җиңәләр – конкурсларда, олимпиадаларда, фестивальләрдә. Быел, мәсәлән, безнең укучылар «Татарстанда яшәүче халыкларның туган телләрендә диктант» яздылар – барлыгы 14 телдә!

ЯРДӘМ ҮЗӘГЕ

– Дуслык йорты каршында Россия халыклары ассамблеясенең ресурс үзәге эшли. Ул нәрсә белән шөгыльләнә?

– Бу ярдәм үзәге. Мондый эш формасы методик ярдәм күрсәтү өчен кирәкле булып чыкты. Анда документлар эшләнә, кешеләр бирегә юридик һәм башка төр ярдәм сорап мөрәҗәгать итә, ихтыяҗ булганда уку-укытулар оештырыла. Ресурс үзәге социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар белән милли-мәдәни берләшмәләр арасындагы

3
Булачак журналистлар – Ислам университеты студентлары белән истәлеккә төшкән фото.

4
– Мәктәп мәктәп инде ул, якшәмбе мәктәбеме, башкамы – мөһим түгел, – ди Фәрит Хәйруллович. – Алар һәрвакыт нәрсәгәдер әзерләнә, һәрвакыт кайдадыр җиңәләр – конкурсларда, олимпиадаларда, фестивальләрдә.

5

«Татарстан» журналыннан бүләк – 1994 һәм 2017 елгы саннар.

6

Ә «Оцнеба» грузин биюе ансамбленең дәртле чыгышын күрү бәхетенә дә ирештек – хореография залында репетиция бара иде...

7 8

Массакүләм матбугат чараларында эшчәнлек алып бару буенча «Татмедиа» Республика агентлыгы оештырган курсларда ТР милли-мәдәни автономияләре белгечләре белән бергә квалификациябезне күтәрик.

мөнәсәбәтләрдә ярдәмче, аларга мәгълүмати, методик, консультатив булышлык күрсәтә. Бу казанда агымдагы һәм киләчәккә караган төрле мәсьәләләр эшкәртелә. Әлегә тәҗрибәбез зур түгел, аны әле үстерергә кирәк. Ресурс үзәге хезмәтеннән актив файдаланснннар өчен күпмедер вакыт таләп ителә. Аны оештыруның ахыргы максаты да – иҗтимагый милли-мәдәни берләшмә җитәкчеләре һәм әгъзаларының оешмалар белән җитәкчелек өлкәсендәге, проект эшчәнлеген үстерүдәге, социаль партнерлыкны формалаштырудагы һәм милләтара хезмәттәшлекне тирәнәйтүдәге белем-күнекмәләрен ныгыту бит. Биредә мәдәни яктан да агарталар, милли сәясәт өлкәсендә танылган белгечләрне, күренекле галимнәрне чакырып, түгәрәк өстәлләр һәм лекцияләр дә оештыралар, ММЧ белән дә эшләргә өйрәтәләр, интернетта оешманы тәкъдим итүне дә аңлаталар, социаль челтәрләрдә эшчәнлегеңне дә яктырталар, грант алырга да ярдәм итәләр...

Югарыда аталганнарны раслап, без массакүләм мәгълүмат чараларында эшчәнлек алып бару буенча Татарстан халыклары ассамблеясе, ТР милли-мәдәни автономияләре белгечләренең квалификацияләрен күтәрү курсларын да үреп чыгабыз. Курсларны «Татмедиа» Республика агентлыгы оештырган.

ЯРДӘМГӘ – ТУЛЫ БЕР ЕЛ!

– Президентның 2021 елны Татарстанда Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы дип игълан итүен милли-мәдәни берләшмәләр ничек кабул итте? Ел тәмамланырга күп калмады – планнарның кайсыларын тормышка ашырырга мөмкин булды?

– Рөстәм Миңнеханов бу турыда Дәүләт Советына Еллык юлламасында игълан иткән иде. Аның тәкъдимен хуплап, зур рәхмәт хисе белән каршы алдылар. Соңрак, мәдәни автономияләр рәисләре белән очрашу вакытында, минем тагын бер мәртәбә бу турыда игълан итүемне торып басып, алкышлар белән каршы алдылар.

Һәркем Президентның телләр һәм халыклар бердәмлеге мәсьәләләренә шундый игътибар күрсәтүен зур рәхмәт белән кабул итте. Барысы да республикабыз хөкүмәте тарафыннан финанс ярдәме күрсәтеләчәген аңлый. Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елына кагылышлы барлык сораулар да дәүләт программасы кысаларына кертелде һәм уртак эш башланып китте. Мин ММЧна, журналистларга үз программаларында әлеге теманы һәрьяклап яктыртканнары өчен рәхмәтемне белдерәм. Газета-журналлардагы һәр материал, радио, телевидениедәге һәр чыгыш төрле милләт вәкилләреннән рәхмәт сүзләре белән тәмамланды. Әрмәнме, үзбәкме, кытаймы – алар барысы да республика җитәкчелегенә һәм төп халыкка ТР халыкларының тату гаиләсендә яшәүләре өчен рәхмәтле.

Ә бу эшле булу, үсеш, республикага эмиграция шартларында килүчеләргә яисә монда туганнарга үзтәңгәллекләрен саклау өчен яңа шартлар пәйда була дигән сүз. Татарстанда мондый шартлар тудырыла – кечке мәктәптә укыр, ресурс үзәгендә ярдәм алыр, республикабыз мәдәниятен үзләштерер, үз казанышларыңны күрсәтер өчен мөмкинлекләр тудыру аша. Һәм бу бәйрәмнәрдә генә түгел, гадәти тормышта да чагылыш таба.

Татарстан халыклары ассамблеясе өчен мөһим елда республика халыкларының туган телләрен һәм мәдәниятләрен саклауга һәм үстерүгә бәйле дистәдән артык яңа проект тормышка ашырылды. Алар барысы да ТР җитәкчелеге тарафыннан хупланды һәм финанс ярдәме алды. Бу – «Без

бергә!» республика күчмә фестивале дә, «Театраль сезоннар» – Идел буе төбәкләре милли театрларының төрле телләрдәге постановкалары да, Идел буе халыклары телләрендә мәктәп укучылары өчен «Туган тел» әдәби конкурсы да (иң яхшы эшләр тупланган җыентыкны бастыру юлы белән), «Сугыш елларында СССР халыклары телләрендә басылган 100 уникаль плакат һәм газета» күргәзмәсе дә... Әлеге чараларның күбесе ковидка бәйле рәвештә онлайн үткәрелде, әмма бу аларның географиясен киңәйтте генә.

ДУСЛАР КОВИД ВАКЫТЫНДА БЕЛЕНӘ

– Ягъни ковид халыклар дуслыгына комачауламый?

– Дуслык авырлык килгәндә сынала да! Пандемия вакытында иҗтимагый милли-мәдәни берләшмәләр Татарстан территориясендә яшәүче ватандашларына һәм җирле халыкка гуманитар ярдәм күрсәтте һәм күрсәтүләрен дәвам итә. Битлекләр, азык-төлек тараталар, эшләрен югалткан гаиләләргә матди яктан булышалар, дарулар китерәләр. Татарстан халыклары ассамблеясендәге ярдәмчел кешеләрнең булышлыгы белән меңләгән кеше үзләренә, гаиләләре янына китә һәм Татарстанга кайта алды. Волонтерлык хәрәкәтенә бигрәк тә таҗик, кыргыз, азәрбайҗан, вьетнам, үзбәк җәмгыятьләре актив кушылды. Үзбәк диаспорасы, мәсәлән, инде икенче ел ял-йокы күрмичә татарстанлыларны ковидтан дәвалаучы табибларны сыйлау өчен 500 кг пылау пешерергә җыена.

ГАМӘЛИ ФАЙДА

– Ассамблея казанышларыннан нәрсәләр республикада яшәүчеләр өчен бәхәссез гамәли файда китерә?

– Һичшиксез, бу миграция өлкәсендә алып барыла торган эш. 20 елдан артыграк элек Татарстан халыклары ассамблеясе беренче «Миграция сәясәте өлкәсендә хезмәттәшлек турында килешү»гне имзалау һәм ТР буенча РФ ЭЭМ һәм республика Милли-мәдәни берләшмәләре җитәкчеләренең Координация советын оештыру башлангычы белән чыкты.

Милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр мәсьәләләре буенча ведомствоара эшче төркем утырышлары квартал саен уздырыла. Анда миграция торышы анализлана, чит ил кешеләре тарафыннан хокук бозу очраклары тикшерелә. Мондый формат килеп туган проблемаларны тиз арада хәл итәргә булыша.

Дуслык йортында ММА җитәкчеләре үзләренең ватандашларын кабул итә, миграция, эшкә урнашу, эш бирүчеләрдән хезмәт хакы алу, Вакытлыча тоту үзәгендә урнашкан чит ил гражданнарына булышу мәсьәләләрен, шулай ук консуллык эшенә кагылышлы сорауларны хәл итә. Мәсәлән, ТР үзбәк һәм таҗик милли-мәдәни автономияләре елына 2000 гә якын кешене кабул итә.

Татарстан – мигрантлар белән эшләү турында ЭЭМ белән уртак килешү имзалаган бердәнбер Россия субъекты. Аның максаты – килгән кешеләргә эшкә урнашырга, алар тарафыннан хокук бозуларга юл куймаска, ватандашлары белән аралашуны оештырырга ярдәм итү.

– Милләтара татулыкны һәм бердәмлекне саклау – ул бер елга исәпләнгән чара түгел, күп көч таләп итә торган даими хезмәт. Әлеге мәсьәләгә президент дәрәҗәсендә ныгытылып, аерым игътибар күрсәтелгән ел үтеп бара. Ассамблея киләчәккә нинди ниятләр белән яши?

– Күркәм чараларга байлыгы буенча киләсе ел быелгысыннан ким булмас. Ассамблея өчен юбилей елы котелә – киләсе елга оешуга 30 ел тулуны билгеләп үтәчәкбез. ТР Президенты ярдәмендә Халыклар ассамблеясенең яңа ачылган вәкиллекләренә 10 яңа микроавтобус биреләчәк. Рөстәм Нургалиевич Дуслык йортын капиталь ремонтлау турындагы карарны да хуплады. Моннан тыш, 2022 ел илдә Халык сәнгате һәм Россия халыкларының матди булмаган мәдәни мирасы елы дип игълан ителәчәк. Һәм без көн саен бергә хәл итә торган сорауларга дәүләт тарафыннан элеккечә үк аерым игътибар биреләчәк. Безнең уртак системага салынган эшебез, чаралар үткәрүдә яңа, заманча ысулларны һәм стандартларны исәпкә алып, күпмилләтле республикабызда, илебездә тынычлык һәм татулыкны саклау нигезенә эверелергә тиеш.

9
– Күркәм чараларга байлыгы буенча киләсе ел быелгысыннан ким булмас, – Фәрит Мөхәммәтшин.

8

9

Фото: Александр Ефремов

ТАТАРСТАН ДИАСПОРАЛАРЫ ҖИТӘКЧЕЛӘРЕ

ТЫНЫЧ, ДУС-ТАТУ ЯШӘҮ ТУРЫНДА

Татарстанның милли-мәдәни автономияләре рәисләре күпмилләтле республикада яшәү хәлләре турында фикер алышу, тәҗрибә уртаклашу һәм журналистларны кызыксындырган сорауларга җавап бирү өчен «Татарстан» журналында түгәрәк өстәлгә җыелды:

1 **Татарстанны еш кына илдә иң толерант республика дип атыйлар. Бу нәрсәләрдә чагылыш таба?**

2 **Мультимәдәни җәмгыятьтә диаспорагызга тел һәм мәдәниятне (милли үзтәңгәллекне) сакларга нәрсәләр булыша?**

3 **Бүген бөтен кеше дә туган телен белми. Ни өчен дип уйлыйсыз?**

4 **Әгәр сез милләтләр эшләре буенча министр булсагыз, иң беренче чиратта нинди карар кабул итәр идегез?**

Фото «Наш дом – Татарстан» журналы редакциясеннән алынды

АЗӘРБАЙҖАННАР

БӘҺРАМ ТАЛЫБ ОГЛЫ МОСТАФАЕВ,

«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЗӘРБАЙҖАННАРЫ» ТӨБӘК ИҖТИМАГЫЙ ОЕШМАСЫ РӘИСЕ

1 Татарстан бер территориядә төрле дин вәкилләренең тыныч һәм имин яши алуына тиңдәшсез үрнәк булып тора. Республикадагы күпмилләтле халыкның үсеше өчен барлык шартлар тудырылган. **Безнең менә дигән Халыклар дуслыгы йортыбыз бар, анда балаларыбыз, оныкларыбыз, аларның балалары туган телне, йолаларыбызны, мәдәниятебезне һәм гореф-гадәтләребезне сакларга өйрәнә.**

2 Халыклар дуслыгы йортында 1990 елдан бирле Күпмилләтле якшәмбе мәктәбе эшли, балалар монда туган телне өйрәнә. **Күптән түгел мәктәптә өлкәннәр өчен дә азәрбайҗан теле курслары ачылды.**

3 Гаиләдә туган телдә сөйләшәләр икән, балалар да, оныклар да аны һичшиксез беләчәк. **Без, мәсәлән, өйдә азәрбайҗанча аралашырга тырышабыз.** Оныгыбыз – яшьтәшләре белән рус телендә, балалар бакчасында татарча сөйләшә. Ә өйдә без аны туган теле – азәрбайҗан теленә өйрәтәбез. Өстәвенә, без ел саен туган якка, Бакуга кайтып киләбез – анда рәхәтләнеп туган тел мохитенә чумабыз. Ана телен бу телдә сөйләшмичә генә белү мөмкин түгел. Ә тел, гореф-гадәтләр, мәдәният онытыла икән, кешенең рухы зәгыйфьләнә, халык үз көчен югалта, җәмгыять таркала, бу исә аның деградациясенә китерә.

4 **Милләтара мөнәсәбәтләрне ныгытыр идем.**

Фото: www.addnt.ru

PRESSA

БАШКОРТЛАР

ГАЛИ ХӘСӘНОВ,

«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАШКОРТЛАРЫНЫҢ МИЛЛИ-МӘДӘНИ АВТОНОМИЯСЕ» ТӨБӘК ИҖТИМАГЫЙ ОЕШМАСЫ РӘИСЕ

1

Без, төрле милләт вәкилләре, Татарстанда тату яшибез, Сабан туен да, Май чабуны да, Нәүрүзне дә, башка бәйрәмнәрне дә бергәләп билгеләп үтәбез, бер-беребезгә булышабыз. Дәүләт хакимияте органнары һәм җәмәгатьчелек белән тыгыз элемтәдә эшлибез, уртак проектларны гамәлгә кертәбез. Аерым алганда, безнең оешма милли мәдәниятне, гореф-гадәтләрне саклап калуга һәм үстерүгә, тынычлыкны һәм татулыкны саклауга юнәлдерелгән яшьләр социаль проектларын тормышка ашыра. Безнең проектлар Президент грантлары фонды җиңүчеләре булып тора. Проектларны тормышка ашыруда башка милли-мәдәни берләшмәләр вәкилләре дә ярдәм итә. Сүз уңаеннан, минем өчен толерантлык һөнәремнең мәҗбүри шарты булып тора.

Без, табиблар (мин Түбән Камада күппрофильле клиникада эшлим), авыруларны аларның милләтенә, җенесенә, тән төсенә карамыйча дәвалыйбыз, барысына да бертигез дәрәҗәдә ярдәм күрсәтәбез.

2

Безнең төбәк автономиясе 2003 елдан бирле эшли. Без башкорт бәйрәмнәрен бергә билгеләп үтәбез. Чаллыда «Гөлнәзирә», Түбән Камада «Сал Урал» һәм Казанда «Ак тирәк» фольклор ансамбльләре мәдәниятебезне, гореф-гадәтләребезне, телебезне пропагандалый. Шәһәр, республика, илкүләм фестивальләрдә, конкурсларда, конференцияләрдә катнашабыз.

Казан, Чаллы һәм Түбән Кама Халыклар дуслыгы йортларында эшләп килгән якшәмбе мәктәпләрендә башкорт телен өйрәнү өчен барлык шартлар да тудырылган.

«Чишмә» Халыклар дуслыгы йортында «Әманәт» шигъри берләшмәсе актив эшли. Без Бөтенроссия проектларында җиңүләр яуладык, яшьләребезнең социаль проектлары 2020 һәм 2021 елларда Президент грантлары фондында җиңүче дип табылды. 2020 елда без РФ Дәүләт милли сәясәте өлкәсендә проектларны гамәлгә ашыра торган коммерциячел булмаган оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләр җитәкчеләренең VI Бөтенроссия конкурсында җиңдек.

3

Минемчә, балалар туган телгә беренче чиратта гаиләдә өйрәнергә тиеш.

Өйдә туган телдә сөйләшү, гореф-гадәтләрне саклау, аларны буыннан буынга тапшыру кирәк.

4

Татарстанда барлык халыкларның телен, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен саклау һәм үстерү, милләтара тынычлыкны һәм дини татулыкны саклау юнәлешендә төпле, уйланылган сәясәт алып барыла.

Беренче чиратта, мин милләтара иминлекне һәм татулыкны саклау буенча мөһим эшне дәвам итәр идем.

Фото «Наш дом–Татарстан» журналы редакциясеннән алынды

БУРЯТЛАР

СЭСЭГМА БУБЕЕВА,

«КАЗАН ШӘҺӘРЕ БУРЯТЛАРЫ МИЛЛИ-МӘДӘНИ АВТОНОМИЯСЕ» ИҖТИМАГЫЙ ОЕШМАСЫ РӘИСЕ

1 Татарстанда кешеләр, җенесе, тән төсе, теркәлү урыны яки яшәү урынына карамастан, ирекле тормыш кора, эшли, укый һәм балаларына белем бирә ала.

Күп кенә якташларым дәүләт хезмәтендә дә, муниципаль хезмәттә дә эшли.

Моны исә төбәкнең һәркем өчен ачыклыгы, һәркем өчен уңайлы булу күрсәткечләренең берсе дип саныйм.

2 Барыннан да элек, һичшиксез, гаиләдәге тәрбия, аның көнкүреше һәм нигезләре турында сүз бара.

Без автономиябездә, әлбәттә, милләттәшләребездә үз мәдәниятебезгә карата кызыксыну уятырга һәм мәхәббәт тәрбияләргә тырышабыз, гореф-гадәтләребезне сакларга ярдәм итә торган чаралар уздырабыз.

3 Кызганыч, бүген туган телен барысы да белми. Тел мохитенә чуму күренеше юк, нәтиҗәсе – күз алдында.

Бала туган телне, барыннан да элек, өйдә ишетергә тиеш, әгәр бу шарт үтәлмәсә, бернинди сүзлекләр һәм дәреслекләр дә ярдәм итмәячәк.

4 Мин, бала кайда гына яшәсә дә, ул укыган мәктәптә күпме генә күләмдә булса да, һичшиксез, нәкъ менә аның туган телен мәҗбүри өйрәтүне кертер идем.

Һәр халык үз телен, мәдәниятен һәм туган илен хәтерләгән дәвергәчә яши. Ана теле укытучыларына, бигрәк тә туган иле файдасына аннан читтә эшләүчеләргә төрлечә булышу, бүләкләү турында карар кабул итәр идем.

Фото: Александр Ефремов

PRESSA

КАЗАХЛАР

СӘГЫЙТЬ ҖАКСЫБАЕВ,

«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЗАХЛАРЫНЫҢ МИЛЛИ-МӘДӘНИ АВТОНОМИЯСЕ» ТӨБӘК ИҖТИМАГЫЙ ОЕШМАСЫ РӘИСЕ

1 Татарстанда бу республикада яшәүче төрле милләт һәм халык вәкилләренә ярдәм итү өчен кирәкле матди шартлар тудырылган. **Хакимиятнең финанс мәсьәләсендә генә түгел, ә рухи яктан да ярдәм итүе – этномәдәни үсеш өчен көчле этәргеч ул.**

2 **Милләтара якшәмбе мәктәбе бик булыша.** Бу проектны тормышка ашыру һәм үстерүдә казахлар оешмасы да ярдәм итә. Мәктәптә казах бүлекчәсе дә бар.

3 Хәтта казахлар күпләп яши торган төбәкләрдә дә туган телне саклап калу җиңел түгел. Оренбург һәм Томск өлкәләрендә, мәсәлән, махсус милли мәктәпләр булдырырга кирәк, дип саныйм. **Татарстанда мондый проблема юк, монда,** кабатлап әйтәм, якшәмбе мәктәбе яхшы эшли.

4 Бездә милләтләр эшләре буенча министр юк, әмма **барлык кирәкле функцияләр дә иҗтимагый оешмалар һәм дәүләт катнашында Татарстан Республикасы халыклары ассамблеясе аша гамәлгә ашырыла.** Министрлык юк та кебек, ләкин эшләре үтәлеп тора.

Фото: www.adannt.ru

МАРИЛАР

ЛЮДМИЛА МУСИХИНА,

«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАРИЛАРЫНЫҢ МИЛЛИ-МӘДӘНИ АВТОНОМИЯСЕ» ТӨБӘК ИҖТИМАГЫЙ ОЕШМАСЫ РӘИСЕ УРЫНБАСАРЫ

1 Татарстанда төрле халыклар дус һәм тату яши.

Бу исә – асылда республика җитәкчелегенең зирәк сәясәте нәтиҗәсе.

Татарстан халыклары ассамблеясе, Халыклар дуслыгы йорты да үзләренең саллы өлешен кертә. Милли җәмгыятьләрнең, оешмаларның үзара хезмәттәшлеген тәэмин иткән төгәл система төзелгән. Халыклар дуслыгы йорты Казанда гына түгел, аннан читтә дә төрле мәктәп укучылары белән дуслык һәм татулык дәресләре үткәрә. Һәм, әлбәттә, без халыклар дуслыгы ник шулкадәр мөһим икәнлеген барыбыз да аңлыйбыз.

2 Үсеп килүче буынга тарихи һәм заманча үрнәкләрдә рухи-әхлакый һәм патриотик тәрбия бирү, социаль мөһим инициативаларны, проектларны үстерү һәм аларга ярдәм итү зур әһәмияткә ия.

Үзара аралашу, бигрәк тә интернет мохитендә элемтә тоту булыша.

Иҗтимагый оешмаларның, милли-мәдәни автономияләрдәге активистларның роле зур. Алар яшьләрдә үз тарихларына һәм мәдәниятләренә карата мәхәббәт тәрбияли, халык җыр-биюләрен популярлаштыра.

3 **Туган телне саклап калырга ниндидер акыллы закон проектлары гына ярдәм итә ала, дип уйламыйм.**

Әгәр бала өйдә туган телендә сөйләшмәсә, балалар бакчасында ана телендә аралашмаса, дәреслекләр сатып алуга акча бирү дә, мәктәптә туган телләрне укыту да булышмаячак.

4 **Гомуми белем бирү мәктәпләрендә Идел буеның төп халыклары, аларның мәдәнияте, тарихы, диннәре турында мәҗбүри дәрес кертер идем.**

Әлбәттә, уку-укыту программаларын һәм кулланмаларны тулыландыру хисабына. Ата-аналарны балаларга үз тамырлары, ата-бабалары турында сөйләргә мәҗбүр итәр идем. Ата-бабалары белән элемтә тойган кеше генә аякта нык басып торып, үз көченә ышана ала.

Фото «Наш дом – Татарстан» журналы реда…

МОРДВАЛАР

НАТАЛЬЯ САБИТОВА,

«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МОРДВАЛАРЫНЫҢ МИЛЛИ-МӘДӘНИ АВТОНОМИЯСЕ» ТӨБӘК ИҖТИМАГЫЙ ОЕШМАСЫ РӘИСЕ

1

Татарстан миниатюрадагы Россия булып тора.

Бездә 173 милләт вәкиле дус һәм тату яши. Биредә хезмәт сөючән күпмилләтле халык гомер кичерә. Тарихи яссылыкта Татарстан – Идел буеның мәдәни үзәге генә түгел, ә сәүдә-сәнәгать үзәге дә ул.

2

Гаиләдә туган телдә сөйләшсәләр, бу – уңышның 90% ы дигән сүз. Хәзерге дөньяда телне саклау һәм үстерү өчен аны цифрлаштыру да бик мөһим.

Әгәр тел Интернет челтәрендә яши икән, хәтта ана телендә даими аралашудан мәхрүм ителгән кешеләр дә, туган тел мохитенә чумып, башка милләтәшләре белән элемтәдә тора ала.

Әмма кешеләрнең үзләрендә дә туган телне өйрәнүгә, белүгә кызыксыну саклануы кирәк, әлбәттә. Процесс алар өчен кызыклы, хәтта отышлы да булырга тиештер.

3

Глобальләшү процесслары чикләрне юа, яңа кагыйдәләр урнаштыра, мәдәни матрицаны алыштыра. Кешеләр туган телдә сөйләшүдән туктый.

Мөгаен, бу проблеманы 20–25 ел элек үк, мәсәлән, телетапшырулар челтәре контентын да күбәйтеп, туган телләрдә белем бирүне цифрлаштыруны да көчәйтеп хәл итә башларга кирәк булгандыр.

Туган телләр саклансын өчен, алар үсәчәк һәм кулланылачак мохит кирәк. Барысы да гаиләдән башланырга тиеш.

4

Мин бер төркем тәкъдим күтәреп чыгар идем.

Аларның максатлары: а) мәктәпкәчә белем бирү өлкәсендә туган телләрне өйрәнүне арттыру; б) туган телләрдә белем бирү эшендә цифрлаштыруны тәэмин итү; в) туган телләрдә белем бирә торган мәктәпләр, мәдәни оешмалар өчен грантлар һәм проектлар санын күбәйтү.

Фото: www.addnt.ru

РУСЛАР

ИРИНА АЛЕКСАНДРОВСКАЯ,

ТАТАРСТАН ХАЛЫКЛАРЫ АССАМБЛЕЯСЕ СОВЕТЫ РӘИСЕ УРЫНБАСАРЫ, «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ РУС МИЛЛИ-МӘДӘНИ БЕРЛӘШМӘСЕ» ТӨБӘК ИҖТИМАГЫЙ ОЕШМАСЫНЫҢ ИДАРӘ РӘИСЕ

1

Мин «толерантлык» төшенчәсен яратмыйм. Ул илебездә борын-борыннан яшәүче халыкларның үзара мөнәсәбәтенең асылын ачып бирми.

Ә менә Татарстанда төрле халыкларның үзара тыныч, дус һәм тату яшәүләре, үзләрен уңайлы хис итүе – монысы хакыйкать.

Татарстан халыклары ассамблеясе – күпмилләтле халкыбызның ярдәмләшеп гомер итүенең, мәдәниятләр багланышының тиңсез тәҗрибәсе. «Безнең йорт – Татарстан», «Мәдәниятләр мозаикасы» кебек һәркемгә мәгълүм фестивальләр һәм Ассамблеянең башка инициативалары моны ачык күрсәтә. Бездә Каравон, Сабан туе, Май чабу, Нәүрүз, Уяв, Валда шинясь һәм башка халык бәйрәмнәрен бергәләп билгеләп үтү гадәткә кергән.

2

Үз гореф-гадәтләренә, үз тамырларына мәхәббәт, ата-бабаларыбыз тарихына, мәдәниятенә һәм көнкүрешенә хөрмәт теләсә кайсы халыкка милли үзенчәлекне саклап калырга юл ача.

Ә бу исә гаиләдә, үз тамырларыңны онытмыйча, гаилә ядкәрләрен ихтирам итеп, ата-бабалар турында истәлекләрне саклаганда гына мөмкин.

3

Глобальләшү, компьютерлаштыру, инглиз телле дөньякүләм мохитнең бик тиз киңәюе хәтта француз, алман, рус телләре кебек шундый киң таралган телләрнең үсешенә дә куркыныч туугa китерә.

Хәзер көндәлектә кулланыла торган рус теле, шул исәптән рус халкы вәкилләренеке дә, сүз төсмерләренең байлыгы, лексик күптөрлелеге, грамматик һәм стилистик дөреслеге белән әллә ни мактана алмый. Ә күп кенә сүзләрдә басымны дөрес куймаулары бөтенләй кәефне төшерә! «Тел белән килделе-киттеле эш итү фикерләү дә шулай килделе-киттеле дигән сүз: төгәл түгел, хаталы, якынча гына», – дип язган Алексей Толстой. Минемчә, бу гыйбарә шуны гаять анык белдереп, ассызыклап күрсәтә: сөйләмдә булсынмы, язудамы – телгә игътибарсызлык, андагы наданлык, ярлылык ялгыш карарларга, кайчагында төзәтеп булмаслык авыр нәтиҗәләргә китерергә мөмкин. Шуңа күрә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов тарафыннан игълан ителгән Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы бик вакытлы булды һәм «Татарстан Республикасының Рус милли-мәдәни берләшмәсе» оешмасы активы тарафыннан хупланды.

4

Милләтләр эшләре буенча министр булсам,

беренче чиратта мин, теләсә кайсы очракта да «зыян китермә» принцибы буенча эш йөртергә, дигән карар кабул итәр идем.

Фото «Наш дом–Татарстан» журналы редакциясеннән алынды

ТАҖИКЛАР

САБРИДДИН ТОИРОВ,

«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТАҖИКЛАРЫ МИЛЛИ-МӘДӘНИ АВТОНОМИЯСЕ» ТӨБӘК ИҖТИМАГЫЙ ОЕШМАСЫ ИДАРӘСЕ РӘИСЕ

1

Толерантлык көнкүрештәге гади нәрсәләрдә, гадәти тормышта күренә. Монда, Татарстанда, без, мөселманнар, мәчеткә йөрибез, анда төрле милләт вәкилләре бер үк вакытта гыйбадәт кыла. Ә мәчеттән ерак түгел башка бер гыйбадәтханә – чиркәү урнашкан. Бер мәхәллә кешеләре – мөселманнар да, христианнар да бер-берсенә яхшы, игелекле мөнәсәбәттә. Без, таҗиклар, Россия Федерациясе гражданнары булдык, балалар мәктәпкә, оныклар – балалар бакчасына йөри.

Татарстанда кемнеңдер башка милләт вәкиленә карата начар сүз әйткәнен беркайчан да ишетмәдек.

Татарстанда үзебезнең милли бәйрәмебез – Нәүрүзне билгеләп үтәбез. Корбан гаетен, Ураза гаетен барлык республика халкы бәйрәм итә.

2

Тел, мәдәният, гореф-гадәтләребезне саклауда диаспорабыз ярдәм итә. Тормышыбыз кече Ватаныбызга әйләнгән Татарстан белән тыгыз бәйләнгән.

Халыклар дуслыгы йортында якшәмбе мәктәбе эшли, анда таҗик теленә өйрәтәләр.

Әле биредә искиткеч бәйрәмнәр, фестивальләр дә уза, анда безнең халык җырларын тыңлап, биючеләребезне алкышлый аласыз. Халыклар дуслыгы йорты – һәр диаспора, һәр халыкның милли үзенчәлеген саклый һәм популярлаштыра торган урын ул.

3

Гаиләләребез русча һәм татарча сөйләшергә өйрәнде, әмма, ни кызганыч, туган телне барыбыз да белми!

Ул онытылмасын өчен, балалар һәм оныклар белән күбрәк, ешрак аралашырга кирәк.

4

Татарстан толерантлык һәм тату күршелек үзәге булып калсын өчен,

башкарыла торган барлык эшләрне дәвам гына итәр идем.

PRESSA

Фото: Александр Ефремов

УДМУРТЛАР



АНДРЕЙ ГЕРАСИМОВ,

«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ УДМУРТЛАРЫНЫҢ МИЛЛИ-МӘДӘНИ АВТОНОМИЯСЕ» ТӨБӘК ИҖТИМАГЫЙ ОЕШМАСЫ РӘИСЕ

1

Сүзне иң мөһименнән башлыйк. Бездә Татарстан халыклары ассамблеясе белән Дуслык йортларының иҗтимагый берләшмәсе бар, алар милли-мәдәни автономияләрнең төбәк иҗтимагый оешмалары, башкарма һәм муниципаль хакимият органнары, Мәдәният министрлыгы, Мәгариф һәм фән министрлыгы, Яшьләр министрлыгы белән тыгыз хезмәттәшлек алып бара, бу исә күпсанлы уртак чаралар, республика милли бәйрәмнәре, конкурслар,фестивальләр уздыруда чагылыш таба. **Мәктәпкәчә яшьтәге һәм башлангыч мәктәп яшендәге балалар өчен «Мудорвай» («Үсенте») удмурт мәдәнияте республика конкурсында удмурт милләтендәге малайлар-кызлар гына түгел, башка милләт балалары да катнашуын мисал итеп китерергә мөмкин. Әлеге бәйге барышында алар удмурт халкының теле һәм мәдәнияте белән таныша.** Шунысы игътибарга лаек: балалар үзләре дә бәйгегә теләп катнаша, эти-әниләре дә хуплый гына.

2

Минемчә, **халыкның төрле катламнары өчен үткәрелеп, туган телләрне, мәдәниятне һәм гореф-гадәтләрне өйрәнүгә этәргеч бирә торган конкурслар, фестивальләр,** хакимиятнең барлык тармаклары белән бәйләнештә уздырыла торган республиканың милли бәйрәмнәре уңай йогынты ясый.

3

Урбанизация, глобальләшү, туган телне мәҗбүри өйрәнүне таләп иткән кайбер законнарның юклыгы **милли мәдәниятләрне саклау һәм үстерү эшенә тоткарлык булып тора,** дип саныйм.

4

Минемчә, бер карар – ул диңгездәге тамчы гына, ул һични үзгәртмәячәк. Системалы һәм комплекслы карарлар мөһим. **Ә инде системалы һәм комплекслы эш иткәндә, беренче чиратта, туган телләрне, мәдәниятне, гореф-гадәтләрне саклау мәсьәләләренең бөтен проблемаларын ачыклар идем, алга таба максатларны билгеләп, мәдәниятне, гореф-гадәтләрне саклау-үстерүдә кирәкле ресурсларны ачыклар идем дә фикердәшләр белән бергә шул максатларны тормышка ашыра башлар идем.**

PRESSA

Фото: ww

УКРАИННАР

ТАТЬЯНА КУТЕПОВА,

«КАЗАН ШӘҺӘРЕ УКРАИННАРЫНЫҢ МИЛЛИ-МӘДӘНИ АВТОНОМИЯСЕ» ҖИРЛЕ ИҖТИМАГЫЙ ОЕШМАСЫ РӘИСЕ

1

Казанда 17 ел яшим, әлбәттә, монда килгәндә, рус телендә юньләп сөйләшә дә белми идем, татар телен әйтеп тә торасы юк. **Ләкин республикада берәүдән дә кырын караш сизмәдем, битәрләгән сүз ишетмәдем.** Башкалада гына түгел, бөтен республикада эшләп килгән Дуслык йортлары, халыкларның бергә күңел ачулары, татарлар гына түгел, ә Татарстандагы башка милләтләрнең дә бәйрәмнәрен республика күләмендә уздыру – толерантлыкка мондый мисалларны бик күп китерергә мөмкин.



2

Татарстандагы Дуслык йортлары һәм Татарстан халыклары ассамблеясе бик булыша. **Без кабинет һәм концерт залыннан тулысынча бушлай файдаланабыз.** Биредә концертлар, бәйрәмнәр оештырабыз, туган телдә фильмнар карыйбыз, балалар һәм өлкәннәр өчен иҗади осталык дәресләре уздырабыз, шул рәвешле мәдәниятебез һәм гореф-гадәтләребезне саклап калырга омтылабыз.

3

Чыннан да, һәркемнең үз туган телен белмәве – зур бәла. **Хәзерге җәмгыять, ни кызганыч, балаларда, оныкларда туган телгә мәхәббәт тәрбияләми.** Милләтара катнаш никахлар да үзенекен итә (шәхсән аларга каршы булмасам да, чөнки үзем дә шундый ук хәлдә). Гаиләдә ата-ананың икесе дә бер милләттән булганда, шиксез, тел югалмый, ә менә катнаш гаиләләрдә андый күренеш еш очрый.

4

Иң мөһиме – илләр арасында элемтә урнаштыру, чөнки бәйләнешләр булмаудан кешеләр интегә. Әйтик, хәзерге вакытта Россия белән Украина арасында тимер юл аша да, һава юллары аша да элемтә юк, туганнар еллар буе күрешә алмый.

PRESSA

Фото: www.addnt.ru

ЧУВАШЛАР

ДМИТРИЙ САМАРЕНКИН,

«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА ЧУВАШ МИЛЛИ-МӘДӘНИ АВТОНОМИЯСЕ» ТӨБӘК ИҖТИМАГЫЙ ОЕШМАСЫ РӘИСЕ

1 **Бу тату күршелектә күренә.**
Гасырлар буе бергә яшәүче халыклар, республикабызның мәдәни палитрасын булдырып, бер-берсен рухи-әхлакый яктан тулыландыра. Мәчетләр дә, чиркәүләр дә, өстәвенә, мөселман һәм христиannar белән берлектә төзелгән мәчетләр һәм чиркәүләр булган шәһәр-авыллар – моның дәлиле.

2 Татарстан чувашлары – республикада борынгыдан яшәгән халык. Бай рухи һәм мәдәни мирас калдырган ата-бабаларыбыз җирендә яшәвеңне аңлау үсешкә көч бирә.
Хәзерге дөньяда, таркау яшәгән хәлдә, милли үзенчәлекне саклап калу бик авыр, шуңа күрә без берләшергә һәм халык язмышы турында карарларны бергәләп кабул итәргә тырышабыз.
Безнең автономия эше – бу уңайдан үрнәк ул.

3 Тел – тере субстанция. Аны саклау һәм үстерү күп факторларга, шул исәптән милли мәгарифкә дә бәйле.
Әмма туган телең алгарыш теле булса, ул һичшиксез сакланачак.

4 Бу вазыйфада үземне күз алдына китерә алмыйм.
Ләкин төрле халыкларның гореф-гадәтләрен өйрәтә торган курсларны бөтен җирдә дә кертер идем.
Үзара аңлашу һәм дуслыкка ачкыч ул.

Әңгәмәдәш:
Ксения Сёмина

«ТЕЛ УЛ – МИСТИК СУБСТАНЦИЯ»

Лингвист-полиглот Дмитрий Петров телләрне саклау өчен көрәшү зарурмы, ни өчен укырга кирәк һәм татар телен ничек «тәмле» итеп өйрәнеп була кебек сорауларга җавап бирә.

– Дмитрий Юрьевич, сезнең лингвист портфолиогызда берничә дистә чит тел бар. Алар сезнең өчен нинди әһәмияткә ия?

– Алар – минем дусларым. Әле берсе, әле икенчесе белән аралашасы килә. Мин күңелем яткан телләрне генә өйрәнәм.

– Оригинал телендә укырга яраткан китапларыгыз бармы соң?

– Ричард Бахның «Иллюзии»ләре – минем өчен төп әсәр, бу китап бераз гына булса да дөньяга һәм чынбарлыкка мөнәсәбәтемне чагылдыра. Рус язучыларыннан Михаил Булгаковны яратам. Поэзиягә мөкиббән китәм. Минем өчен шигырь – тел дәрьясына керер өчен кирәкле әфсен ул. Итальян теле өчен – Дантеның «Божественная комедия», француз теле өчен – Вийон балладалары һ.б.

– Ә татар теле өчен?..

– Тапшыруга әзерләнгәндә, мин Габдулла Тукай һәм Муса Җәлил әсәрләрен укып карадым. Татар теленең көен отарга тырыштым.

– Һәр телнең үз ритмы бармыни?

Фото: Эдуард Хәйруллин

ДОСЬЕ:
Дмитрий Петров – психолингвист, полиглот, тәрҗемәче, телевидение алып баручысы, чит телләрне өйрәнү буенча уникаль система төзүче, Мәскәү дәүләт лингвистика университеты мөгаллиме, «Культура» телеканалындагы «Полиглот» программасы һәм «Базовый татарский с Дмитрием Петровым» программасы авторы. Төрле дәрәҗәдә 40 тел белә, шулардан сигезен актив файдалана.



– Әлбәттә. Татар телендә, мәсәлән, бу бик моңлы мелодика. Ул телнең структурасын, әлеге телнең һәм, димәк, халыкның әйләнәтирә мохитне шигъри тоемлавын чагылдыра.

– Сезнең методиканың үзенчәлеге нидә?

– Беренчедән, өйрәнүнең җыйнаклыгында. Мин атнасына бер тапкыр гына шөгыльләнеп нинди дә булса уңышка ирешүгә ышанмыйм. Хәзерге заманда кеше мәгълүматны җыйнак, кыска, тыгыз формада һәм чикләнгән вакыт эчендә генә кабул итә. Мәсәлән, берничә атна буе көн саен шөгыльләнеп. Икенчедән, образлар системасыннан файдалану мәҗбүри. Тел дәреслекләр белән түгел, бәлки, тере образлар белән ассоциациядә булырга тиеш. Өченчедән, шәхси фактор мөһим. Беренче көннән үк нәкъ менә сезнең өчен кирәкле темаларга сөйләшү. Дүртенчедән, грамматиканың база алгоритмнарын, спортның нинди дә булса төрен яки музыка уен коралын үзләштергәндәге кебек үк, тулысынча автоматлаштыру зарур.

– Кешенең күңеленә ятышлы ниндидер мәдәни код телне өйрәнүгә ачкыч була алайса? Мисаллар китерә аласызмы?

– Бу теләсә нәрсә була ала. Мәсәлән, минем өчен татар теле, шигърияттән тыш, әле кулинария дә. Без программаны төшергәндә, мине төрле деликатеслар белән сыйладылар, һәм шуннан бирле мин һәркемгә татар халык ашларын татып карарга киңәш итәм. Гаҗәеп Казанга барырга өндим. Һәм бик күпләр бара да.

– Ә нинди дә булса ерактагы, мәсәлән, япон телен, алсак?

– Япон архитектурасы, сынлы сәнгать. Яшьләр хәзер анимега мөкиббән. Бу да үзенә бер төрле ачкычка әйләнә ала.

– Чыннан да телне берничә сәгать эчендә өйрәнеп буламы?

– Өйрәнеп булмый инде, ә менә аның мантыйгына төшенеп һәм элементар дәрәҗәдә сөйләшә башлап була. Биредә төп сүз – мотивация. Әгәр кешедә мотивация һәм бераз тәртип бар икән, аңа яңа тел мохитенә күнегү өчен махсус сәләтләр, күп вакыт һәм энергия таләп ителмәячәк. Безнең программалардан соң, мәсәлән, актерларның шактые телләрне өйрәнүләрен дәвам итә, кайвакыт бу аларның яңа рольләре белән бәйле була.

– Хәзер кайсы телләрне өйрәнү популяр?

– Беренче урындагы инглиз теленнән тыш – испан, кытай һәм гарәп телләре. Аларның популярлыгы арту бу телләрдә сөйләшкән илләрнең үзләренең икътисадый, сәяси йогынтысын куәтләндерүенә бәйле. Демографик фактор да мөһим. Мәсәлән, испан телендә сөйләшүчеләр саны теләсә кайсы башка телдә сөйләшүчеләр санынннан тизрәк арта.

– Аларны өйрәтүдә нәрсә дә булса үзгәрдеме?

– Һәркемгә аңлаешлы сәбәп буенча, хәзер төп тренд – онлайн-өйрәтү.

– Ул нәтиҗәлеме?

– Аудиториядә өйрәтүдән күпкә нәтиҗәсезрәк әлбәттә. Гәрчә пандемия вакытында аның әһәмияте артса да, ул мөгаллим белән күзгә-күз карап шөгыльләнүне алыштыра алмый.

– Сез үзегез укытырга яратканга шулай уйлыйсызмы?

– Мин чагыштыра алганга күрә шулай уйлыйм, чөнки тегеләй дә, болай да укытам, шул исәптән, университетта төрле онлайн-платформалар ярдәмендә дә. Онлайн-төркемнәрдә нәтиҗәлелек кимрәк. Тик бернишләп тә булмый, чынбарлык шундый, күнегергә туры килә.

– Сез ясалма интеллектның кеше-мөгаллимне алыштыра алуына ышанасызмы?

– МИН АТНАСЫНА БЕР ТАПКЫР ГЫНА ШӨГЫЛЬЛӘНЕП НИНДИ ДӘ БУЛСА УҢЫШКА ИРЕШҮГӘ ЫШАНМЫЙМ. Хәзерге заманда кеше мәгълүматны җыйнак, кыска, тыгыз формада һәм чикләнгән вакыт эчендә генә кабул итә.

– ИҢ БАШТА УК ҮЗЕГЕЗ ӨЙРӘНӘ ТОРГАН ТЕЛ МАНТЫЙГЫНЫҢ СЕЗНЕҢ АНА ТЕЛЕГЕЗДӘН НИ БЕЛӘН АЕРЫЛУЫН АҢЛАУ МӨҺИМ. Әйтик, төрки телләрдә тартым кушымчалары бар, ә славян һәм башка һинд-европа телләрендә алар юк.

– Тулы кыйммәтле ясалма интеллект әле уйлап табылмаган. Әгәр шундыйны уйлап тапсалар, әйе, алыштырачагына ышанам. Әмма инде бүген үк нейрочелтәрләр ярдәмче роль уйный, мәсәлән, телләрне өйрәнү өчен кушымталар сыйфатында. Язма һәм телдән тылмачлык итүче электрон тәрҗемәчеләрнең һаман саен камилрәк версияләре булдырыла. Алар тизлек кирәк булган очракларда бик файдалы. Гомумән, киләчәктә лингвистика күпмедер бер дәрәҗәдә ясалма интеллект үсешенә бәйле булачак, аның төп бурычларыннан берсе – кешеләр белән аралашу бит.

– Әлеге дәвер килеп җиткәнче, яшьләрне татарчага өйрәтүне нинди ысуллар белән яхшыртып була?

– Без күп вакытыбызны виртуаль киңлектә – социаль челтәрләрдә, мессенджерларда үткәрәбез. Һәм бүген мәдәни продукт еш кына нәкъ менә шул виртуаль дөньяда пәйда була. Шуңа күрә кайбер телләр сакланып кала. Мәсәлән, веб-сериаллар ярдәмендә. Алар бик популяр, төшерү гаять күп акча да, камил техника да таләп итми. Аларны телефонга төшереп була. Менә шул юнәлештә кызыклы, актуаль, ә иң мөһиме уникаль продукт булдырырга мөмкин. Матбугат белән дә шул ук хәл. Күпсанлы татар телле басмалар, тәрҗемәдән азрак файдаланып, үз контентларын күбрәк тудырса, бик шәп булыр иде.

– Безнең блогерлар эзләгечләрдә тел продуктын үстерүнең кыенлыгына зарлана.

– Кайбер илләрдә дәүләт теле булмаган кече телләр нейрочелтәрләр, социаль челтәрләр ярдәмендә үстерелә. Мәсәлән, Испаниядә, дәүләт теле саналган испан теленнән тыш, каталон, баск, галисия телләре дә үсештә. Әлеге телләрдә сөйләшүчеләр үз телләрен саклау һәм үстерү бурычын хәл иткән. Халыкара тәҗрибәгә таянырга кирәк. Анда менә шул баланс игътибарга лаек: күп илләрдә – Һиндстан, Швейцария, Бельгиядә, бер яктан, тел мирасын саклау һәм үстерү, икенче яктан, телләрнең берберсе белән конфликтын киметү мөмкинлеген тапканнар. Милли телне торгызуга акыл белән керешкәндә, ул һәрвакыт уңай нәтиҗә бирә. Шул ук вакытта элекке СССРның кайбер республикаларындагы кебек аяныч тәҗрибә дә күз алдында: тел сәясәте административ ысуллар белән гамәлгә кертелгәндә, бу яхшыга алып бармый.

– Өйрәнү өчен катлаулы яки җиңел телләр булуы дөресме?

– Бу – уйдырма. Безгә үз туган телебездән ерак тел катлаулы булып тоела. Иң башта ук үзегез өйрәнә торган тел мантыйгының сезнең ана телегездән ни белән аерылуын аңлау мөһим. Әйтик, төрки телләрдә тартым кушымчалары бар, ә славян һәм башка һинд-европа телләрендә

алар юк. Төрки телләрдә алар тартым алмашлыкларын алыштыра. Төрки телләрдәге, шул исәптән татар телендәге дә, килеш кушымчалары системасы кирәкмәгән бәйлекләрне алыштыра. Ягъни бер урындагы катлаулылык икенче урында җиңеллек китерә. Мәсәлән, бик күп дөрес булмаган фигыльләрне ятлау таләп ителгән инглиз теленнән аермалы буларак, татар фигыльләре системасында чыгармалар юк диярлек. Татар телендә, тамырын белсәң, син үзең сүзнең, шул исәптән фигыльнең, бөтен формаларын ясый аласың. Мондый әйберләрне иң башта ук төшендерү кирәк.

– Дәреслекләр еш кына артык катлаулы язылган, дигән фикер бар.

– Бу шулай. Кызганыч ки, тел дәреслекләренең күпчелеге филологлар өчен филологлар язган кебек төзелгән. Ә бит телне өйрәнергә теләгән һәркемгә аңлаешлы дәреслекләр кирәк.

– Телне өйрәнергә тагын нәрсә булыша?

– Уку. Бу сүзлек запасының табигый рәвештә артуына китерә, чөнки сүзләрне контексттан башка ятлаудан мәгънә юк диярлек.

– Әмма хәзер укуга күп вакыт бирү каралмаган.

– Бу – безнең мәгълүмат кабул итү системабызны деградациягә китерә торган аяныч тенденция. Кеше тәфсилле озын текстларны укудан туктый икән, аңа, беренчедән, башкалар әйткән фикерне аңлау, икенчедән, үз фикерен әйтү кыенлаша.

– Тел – мистик субстанция. Ул нибары сүзлек һәм грамматика белешмәлеге генә түгел, бәлки күңел халәте, билгеле бер үлчәнеш, киңлек.

– Сез ничек уйлыйсыз, игътибарны туплау сәләте югалу эволюция процессын чагылдырамы, әллә бу кире элекке хәленә кайтырлык нәрсәме?

– Төгәл генә әйтә алмыйм. Мөгаен, кеше электрон җайланмаларга һаман саен күбрәк бәйле була барадыр. Хәзер нәрсәнедер – нинди дә булса адрес яки телефонны – истә калдыру өчен хәтерне туплау кирәкми, чөнки барысы да смартфонда бар бит. Һәм боларның барысы да когнитив сәләтләрне шактый зәгыйфьләндерә. Шунлыктан баш миен, хәтерне күнектерүгә үзеңне формада тоту өчен спорт белән шөгыльләнүгә караган кебек әһәмият бирергә кирәк.

– Мәсәлән, лонгридлар уку сәләтен югалтмау өчен, укуга көненә күпме вакыт бүләргә кирәк?

– Бередә мөмкин кадәр уңайлы юлны сайлау зарур. Бүген – биш минут, иртәгә – ун, аннары – унбиш. Әкренләп үзегезгә укыр өчен иң уңайлы вакыт күләмен табачаксыз.

– Сез хәзер нәрсә дә булса укыйсызмы?

– Гадәттә мин берничә китапны берьюлы укыйм. Хәзер бу санскрит мисалында һинд-европа телләре эволюциясе турында текст һәм оригиналда Марсель Прустның «Югалган вакытны эзләгәндә» романы. Классик әдәбият уку бераз тырышлык һәм түземлек таләп итә, әмма мин әлеге күнекмәне югалтмаска тырышам.

– Без тикшергән тенденцияләрне исәпкә алганда, телләрне саклауга куелган көчнең мәгънәсе бар, дип саныйсызмы?

– Мин, артык телләр булмый, дип уйлыйм, тик бу процесс тулысынча табигый һәм уңайлы булырга тиеш. Һиндстанны позитив мисал сыйфатында китереп була. Анда бизнеста, фәндә, технологияләрдә инглиз теле өстенлек итә. Ә милли хинди мәдәният, болливуд теле, кешеләрнең үзара аралашу теле булып кала. Әле тагын һәр штатта җирле телләр бар. Мондый табигый бүленеш әллә ни көч түгүне таләп итми, шул ук вакытта телләрнең һәркайсына гаять зур ресурслар бирә.

– Фантастик «Килү» фильмында төп герой килмешәкләрнең катлаулы телен үзләштерә, һәм ул үткән һәм киләчәкнең теләсә кайсы мизгеленә сәяхәт өчен инструмент булып чыга. Чынбарлыкта моңа охшаш хәлләр булгалыймы?

– Әлбәттә. Тел – мистик субстанция. Ул нибары сүзлек һәм грамматика белешмәлеге генә түгел, бәлки күңел халәте, билгеле бер үлчәнеш, киңлек. Тел һәрвакыт халыкның менталитетын һәм шул халык туплаган тарихи тәҗрибәне чагылдыра. Нинди дә булса бер яңа тел өйрәнә башласагыз, моны шунда ук тоячаксыз.

МИҢА ТАТАРСТАНДА БАРЫННАН ДА БИГРӘК КЕШЕЛӘР ОШЫЙ!

1 ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ СЕЗНЕҢ ӨЧЕН НӘРСӘ УЛ?

УКРАИНЧА

Виталина Резнюк:

– Це вміння жити в мирі, злагоді і дружбі! Повага до іншої національності, її культури та віросповідання!

Бу – үзара дуслыкта тыныч һәм килешеп яши белү. Башка милләткә, аның мәдәниятенә һәм диненә хөрмәт!

МОРДВАЧА

Дарья Долгова:

– Моньксен, ялгаксшись народонь те коли сембе фассе и ладязь эрейсть.

Минем өчен халыклар дуслыгы – бердәмлек һәм берләшеп ныгу ул.

КАЗАХЧА

Карина Кабдуллина:

– Мен үшін халықтар достығы – бұл әртүрлі мәдениеттердің, менталитет пен қызығушы-

2 КАТНАШ НИКАХЛАРГА МӨНӘСӘБӘТЕГЕЗ НИНДИ?

УКРАИНЧА

Руслан Бабенко:

– Шлюб – це союз двох люблячих людей. Це любов, а у любові немає національностей. Любов врятує світ!

Никах – ул бер-берсен яраткан ике кешенең бергә кушылуы. Бу – мәхәббәт, ә мәхәббәтнең милләте юк. Дөньяны сөю генә коткара алачак!

Виталина Резнюк:

– Моє ставлення позитивне! Такі шлюби змінюють ваше життя, об'єднують дві культури, розширюють кругозір, виховують толерантність щодо інших людей!

Милләтара катнаш никахлар безнең тормышыбызны үзгәртә, ике мәдәниятне берләштерә, дөньяга карашны киңәйтә, башка кешеләргә карата сабыр мөнәсәбәт тәрбияли. Мин андый никахларны яклыйм!

МОРДВАЧА

Дарья Долгова:

– Беди кельгсак ломанть, то аф ванат кона шкайти сон тии крест, сяде эрявикс кода ломансь теет кельгуви, ста кода ваны жизнеть лангс.

3 ТАТАРСТАНДА БАРЫННАН ДА БИГРӘК НӘРСӘ ОШЫЙ?

УКРАИНЧА

Виталина Резнюк:

– Татарстан – самобутня республіка з тисячолітньою історією! Подобається те, що тут живуть в дружбі та злагоді люди багатьох національностей, пліч-о-пліч йдуть дві релігії. Культура, традиції, пам'ятки архітектури та природи, ставлення людей один до одного!

Татарстан – чал тарихка ия үзенчәлекле республика. Биредә күп милләт вәкилләренең дус һәм тату гомер кичерүе, ике диннең янәшә яшәве күңелгә хуш килә. Мәдәният, гореф-гадәтләр, архитектура һәм табигать һәйкәлләре ошый.

МОРДВАЧА

Дарья Долгова:

– Татарстан – моньксен аф вκе лацонь традициетне, ломатьне кона тясе эрейсть и кодаме коень коряс сынь тиисть.

Татарстан – милләтләр, мәдәниятләр, гореф-гадәтләрнең тиңдәшсезлеге ул.

«Дуслык», «мәхәббәт», «ышаныч», «ошый» кебек сүзләр Татарстан халыклары телләрендә ничегрәк яңгырый? Үз йортларына әйләнгән, үзләренә сыеныр урын тапкан төбәк турында төрле милләт кешеләре ни уйлый? Бу сорауларга җаваплар шул телләрнең үзендә бирелә, чөнки Татарстанда андый телләр бик күп. Бу телләрдә сөйләшүче милләтләр белдергәнчә, алар бик матур һәм дөрес яңгырый. Чөнки биредә бу телләрне саклау өчен кулдан килгәннең барысы да эшләнә.

лықтардың өзара түсіністігі мен бірігуі. Мен бұл бірлікті шығармашылықтан көремін. Әр ұлттың қатар тұрып бір сахнада қалай өнер көрсеткенін көру өте керемет.

Минем өчен халыклар дуслыгы – ул төрле мәдәниятләр, төрле менталитетлар һәм мәнфәгатьләрнең бердәмлеге һәм үзара аңлашуы. Мин үзем өчен бу берләшүне иҗатта күрәм. Бер-берсеннән шулкадәр аерылып торган милләтләрнең бер сәхнәдә бергә басып тора һәм янәшә чыгыш ясый алуын күрү бик күңелле.

УДМУРТЧА

Елизавета Бехтерева:

– Мон понна пӧртэм калыкъёслэн эшъяськонзы пыӵамын колоритэн: нылъёс дышето пӧраны асьсэ калык сиёнъёсты, пиос йӧскалык инструментъёсын шудыны.

Минем өчен халыклар дуслыгы – күпмилләтле төсмерләргә бай дуслык ул, бу вакытта кызлар үз милли ашларының рецептлары белән уртаклаша, егетләр милли уен коралларында уйнарга өйрәтә.

Мәхәббәтнең милләте дә, дине дә юк. Иманыгызның нинди булуы мөһим түгел, иң әһәмиятлесе – сез сайлаган кешенең үзегезгә рухи яктан никадәр туры килүе.

КАЗАХЧА

София Цой:

– Оң көзқарастамын. Мен өзім де ұлтаралық отбасынанмын: анам – татар, ерлі-зайыптылар жұбы корей ұлтынан. Мен өзім татарға тұрмысқа шықтым. Менің ойымша, ұлт маңызды емес, ең бастысы – салт-дәстүрді сақтау және ұрпақтан-ұрпаққа жеткізу.

Уңай карыйм. Мин үзем дә катнаш гаиләдән, әнием татар, этием – кореяле. Татар кешесенә кияүгә чыктым. Милләт роль уйнамый дип уйлыйм, иң мөһиме, гореф-гадәтләрне саклау һәм аларны буыннан-буынга тапшыру.

УДМУРТЧА

Ольга Чайникова:

– Туала арын уд ни паймы, ку ке кылдо пӧртэм йӧскалык семьяос. Со туж умой мон понна. Мыным кельше, ку ке кык пӧртэм адямиос пумисько, шедьто огкыл но кылдо семья. Туж шумпотӥсько соос понна.

Хәзерге вакытта катнаш никахлар сирәк күренеш түгел. Бөтенләй ике төрле кешенең милләт һәм дин, тән төсе һәм тел аерымлыгына карамастан, бер гаилә тудыруы – бик хуп. Минемчә, бу – бик шәп нәрсә. Әлбәттә, мин хуплыйм гына.

КАЗАХЧА

Карина Кабдуллина:

– Бәрінен де Татарстанда маған адамдар ұнайды! Біздің халықтардың менталитеті өте ұқсас, сондықтан мен өзімді Қазанда үйде жүргендей сезінемін! Мұндағы адамдар өте мейірімді, жылы пейілді, қонақжай және әрқашан көмек беруге дайын!

Миңа Татарстанда барыннан да бигрәк кешеләр ошый! Безнең халыкларның менталитеты бик охшаш, һәм нәкъ менә шуңа күрә мин Казанда үземне туган яктагы кебек хис итәм. Биредә кешеләр бик игелекле, ягымлы, кунакчыл, һәрвакыт ярдәмгә килергә әзер!

УДМУРТЧА

Елизавета Бехтерева:

– Бигерын туж трос ортчо пӧртэм проектъёс, шулдыр пумиськонъёс. Мыным туж кельше соосы пыриськыны но кудог дыръя юрттӥськиськыны соосты ортчытъяны.

Татарстанда мәдәни тормыш кайнап тора. Бик күп проектлар һәм чаралар үткәрелә, ә мин андыйларга йөрергә һәм аларны оештыру эшенә кушылып китәргә яратам.

1 ЯЗЫЛ

2022 елның 21 гыйнварына кадәр «ТАТМЕДИА» АҖнең бер газета һәм бер журналына языл (акциядә катнашучы басмалар белән tatmedia.ru сайтында танышып була)

2 ҖИБӘР

«Акция» билгесен куеп, язылу квитанцияләренең копиясен безгә җибәр (телефон номерыгызны язарга онытмагыз). Адрес: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 яки podpiska@tatmedia.ru

3 ОТ

электр иттарткыч, робот-пылесос, телевизор, кар көри торган җайланма. Төп бүләк — санаторийга 2 юллама

Тулырак мәгълүматны, акциянең узу вакытын, бүләкләр, аларны алу тәртибе турында tatmedia.ru сайтында белә аласыз. Акция 22.10.21 — 20.03.22 кадәр үткәрелә. Гаризалар 21.01.2022 кадәр кабул ителә. Оештыручы — ТАТМЕДИА АҖ. Реклама 16+ Товарлар рәсемдә күрсәтелгәннән үзгә булырга мөмкин.

акыллы гамәлләр

игелекле эшләр /

мәңгелек кыйммәтләр

игелекле эшләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Ятимнәргә **КАЙДА** яхшы шартлар тудырылган

Венгр консулы безне **НӘРСӘ** белән сыйлады

БАЛАЛАР ЙОРТЫНЫҢ ӘНИСЕ

Күз уртасы. Лаеш балалар йорты директоры Рузалия Вәлиуллина белән йөзләп төп роза үсеп утырган ишегалдына узабыз. «Розаларыгыз бигрәк күп икән, салкынга да бирешмәгәннәр», – дим. «Әйе, мин розалар яратам. Үзем дә чәнечкеле бит», – дип куйды директор. Аннан соң нәтиҗә ясагандай: «Үсемлекләр дә җылы карашны сизә», – дип дәвам итте.

Автор:
Руфия Фазылова

САБАК

Лаеш балалар йортында моннан берничә ел элек булган идем. Ул чакта да төзек, матур иде ул. Ләкин бина бүген тыштан да, эчтән дә курчак өен хәтерләтә. 2018 елда капиталь төзекләндерү үткәрелгән. Монда хәзер тозлы һава сулый торган кабинетка кадәр бар.

– Балалар йортының 100 еллыгын билгеләп уздык. Капиталь төзекләндерү – әлеге күркәм вакыйга уңаеннан ТР җитәкчелегенең безгә зур бүләге, – ди Рузалия Вәлиуллина. – Республикабызның беренче Президентының да бездә булганы бар. Минтимер Шәриповичны якын итеп «әтиебез» дип йөрибез. Аллага шөкер, Рөстәм Миңнеханов та безгә карата зур кайгыртучанлык күрсәтә.

– Берничә ел элек, бала гаиләдә тәрбияләнергә тиеш, дигән фикерне алга сөрделәр, – дип искә алды директор. – Ләкин мин ул чакта да әйттем, хәзер дә шул фикердә калам: әти-әнисез калган барлык балаларны да гаиләләргә урнаштырып бетереп булмый. Бала ул уенчык түгел. Аның җаны, уй-фикерләре бар. Башта гаиләгә тәрбиягә бирелеп, аннан соң алардан баш тарткан малай-кызлар бик күп бездә. Өчәр, дүртәр гаиләдә яшәп чыккан балалар бар. Бу бит язмышлар белән уйнау. Әле менә бүген дә бездә берничә шундый бала бар – башта аларны бер гаилә тәрбиягә алган, аннары – икенчеләре. Нәтиҗәдә, ул балаларның психикалары бүтәнчә формалашкан. Яшермим, алар белән безгә дә җиңел түгел.

– Бер тәрбиягә алгач, ни өчен ата белән ана баладан баш тарта? – дим.

– Төрле очрак була. Гадәттә, өлкәннәр тәрбиягә алган бала белән уртак тел тапмый. Баланың үз дөньясы, үз гадәтләре. Аның яңа гаиләгә буйсынасы килми. Сәбәпләр күп инде... Холыклар бер төрле генә булмый бит...

Рузалия апа күп балалы гаиләдә тәрбияләнеп үскән – әтисе белән әнисенең унынчы баласы ул. Әлки районының Яңа Чаллы авылы кызы. Әтисе үлгәндә аңа ике яшь ярым гына була.

– Ятимлекнең ни икәнен беләм, – ди Рузалия апа. – Әйе, безнең әнкәй бар иде. Тик әтисез бала

Фото: Александр Ефремов

үзен яклаучысыз дип кабул итә. Рәхмәт, эти ролен олы абыебыз Госман үтәде. Тик озакламый ул да армиягә китте. Аның белән яшь аермасы унсигез ел. Кыскасы, туганнар күпме булса да, эти белән әнине алыштыра алмый. Шуңа да балалар йортында тәрбияләнүче малай-кызларның күңел халәтен аңлыйм, тоям. Андый балалар кечкенәдән үзләрен якларга өйрәнә.

Яклау дигәннән. Рузалия апа балачагы белән бәйле бер истәлек сөйләде. Кызчыкка дүрт-биш яшьләр тирәсе. Күрше малае үзләренең койма башына менеп баскан да кызның гаиләсен мыскыллый торган сүзләр (кушаматларын) кычкыра. Рузалия озак уйлап тормый – таш ала да малайга таба ата. Таш күрше малаеның әчәнә барып та тия, тегесе койма башыннан егылып та төшә.

– Мин бәрәңге бакчасына качтым, – ди Рузалия апа. – Ә күрше малаеның әнисе мине табып алды да сөйрәп өйгә алып керде. Әни бу вакытта казанда аш пешерә иде. «Чынлап та таш аттыңмы?» – диде. «Аттым», – дидем. Һәм ни өчен икәнне дә сөйләп бирдем. Тик әни өчен бу дәлил булмады. Күрше апасы мине яхшылап кычыткан белән ярды.

– Шулвакыт якламаганы өчен әниегезгә ачу килдеме? – дим.

– Юк. Ул очрак миңа зур сабак булды. Нәрсә эшләсәң дә, син үзең өчен җавап бирергә тиешсең. Шуннан мин алай кызулык белән эш йөртми башладым.

«АРТЫК БАЛАМ ЮК»

Рузалия апаның балачагы җиңел булмый. Бу аңлашыла да, сугыштан соң ил тергезелеп кенә килә. Гаиләдә балалар ишле, җитмәсә эти кеше дә исән түгел. Тик Рузалия апа бер генә дә зарланмый. Киресенчә, мәрхүм әнисенә карата аның рәхмәте, ихтирамы бик зур. Бер вакыйга аның күңелендә мәңгегә уелып калган.

– Математиканы әйбәт белә идем, – дип сөйли әңгәмәдәшем. – Дүртенчене тәмамлаган елны мәктәпкә Базарлы Матактан кешеләр килде. Директор әлеге кешеләрне безгә алып килде. Мине кечкенә якта калдырдылар да, үзләре түр якка чыктылар. Сүзләре озакка киткәч, ишекне ачып, боларны тыңлап тора башладым. Баксаң, мине Казанга интернатка укырга җибәрергә телиләр икән. «Балаларың да күп, бер тамакка ким булыр. Рузалия яхшы белем алачак, кызыңның киләчәген уйла», – диләр. Әни кырт кисте: «Юк, булды, җитте. Артык балам юк. Алты балага таптан ипине җиденчесенә табармын. Рузалияне бер җиргә дә җибәрмим», – диде. Әни шактый кырыс кеше иде, шуңа да директор бүтән сүз куертып тормады – кунакларны алып чыгып китте. Инде үсеп, акыл кергәч, бигрәк тә балалар йортында эшли башлагач, әнинең бу адымын аңладым һәм мең кат рәхмәт әйттем. Ул мине ятим итмәгән...

Рузалия апа һөнәре буенча математика укытучысы. Дөрес, аның беренче белгечлеге икътисадчы. Казан дәүләт педагогика институтына керә алмагач, кыз башта Лаеш авыл хуҗалыгы техникумын тәмамлый. (Туры килүен кара, язмыш махсус аны шушы районга алып килгән диярсең!) Инде техникумны кызыл дипломга тәмамлагач, Рузалия максатына ирешә – педагогика институтына укырга керә.

– Аллаһы Тәгалә миңа студент чагымда ук ятимнәрнең проблемаларын күрсәтте, – ди Лаеш балалар йорты директоры. – Институтта укыганда Казанның 48 нче мәктәбендә практика уздык. Менә шул чакта бишенче сыйныфта укучы бер малайны Алабуга балалар йортына озаттылар. Хәтерлим, малайны кызганып, бөтен мәктәп елап калды. Бер биш көн узгандыр, дәрес алып барам – ишек артында кемнеңдер мыш-мыш килгәнен ишетәм. Коридорга чыгып карасам, Алабугага җибәрелгән малай ишек төбендә елап утыра. Өс-башы пычрак. «Минем ятимнәр йортында яшисем килми, өйгә кайтасым килә», – дип, туктаусыз елый. Ә өенә кайтарырга ярамый – эти-әнисе исерек, хокукларыннан мәхрүм ителгән. И, ул чакта бу баланы кызганганнарым. Мәңгегә истә калды...

Кулына диплом алгач, Рузалия туган ягына эшкә кайтып китә. Дөрес, аның үз мәктәбендә – Яңа Чаллыда укытасы килә, ләкин урын булмый. Яшь белгечне Иске Әнҗерә мәктәбенә билгелиләр.

– Миңа сыйныф җитәкләргә бирделәр, – ди Рузалия апа. – Сигезенчеләрне, «усал» дигән яманатлары чыкканнарны. Тора-бара алар белән уртак тел таптык. Җәен Мәскәүгә барабыз дип план кордык. Һәм юлга дип, балалар акча эшләргә тотынды – атна саен көл, кәгазь җыйдылар. Тик ул елны Мәскәүгә барырга ярамады. Нәтиҗәдә, бергә җыелып Казанга экскурсиягә дә бардык. Укучыларымны авылга килгән концертларга да кертә идем. Ул чакта

1
Лаеш балалар йорты директоры Рузалия Вәлиуллина белән йөзләп төп роза үсеп утырган ишегалдына узабыз.

2 3
Балалар йортында яшәү, белем алу, һөнәр үзләштерү өчен барысы да бар.

мәктәп укучыларына йөрергә ярамый. Директор белән конфликтка килдек, ләкин үз дигәнемә ирештем. Ул сыйныфым белән әле дә аралашып торабыз. Вотсапта төркем бар, шунда языштабыз.

ТАРТУ КӨЧЕ...

Мәктәп эше белән янып йөргән бер мәлдә Рузалияне район үзәге – Базарлы Матакка чакырып алалар. Һәм шунда яшь мөгаллимәгә район комсомолының өченче секретаре вазыйфасын тәкъдим итәләр. Кыз башта карыша, ә аннан ризалаша. Партия кушканны эшләми кара син!

– Мәктәптән авырлык белән киттем, – ди әңгәмәдәшем. – Балалар белән эшләү рәхәт иде. Комсомол эше җиңел булмады. Авыллар буенча йөрергә кирәк. Ул заманда хәзерге кебек машина белән бару юк. Кышын-җәен, нинди һава торышы булуга карамастан, ат арбасында, чанасында йөрдек. Аннары безгә иске генә бер «УАЗ» машинасы бирделәр. Шуны йөртергә өйрәндем. Хәтерлим, берсендә төнлә юлда барганда, алдыбыздан нәрсәдер тәгәри. Карасак, машина тәгәрмәче икән.

Матур гына эшләп йөргән вакытта комсомолның өлкә комитеты секретаре Рушания Вахитова шалтырата. 1986 елның җәе була бу. «Лаеш балалар йортына директор урынбасары кирәк. Балалар белән эш тәҗрибәң, чаялыгың бар. Барасың килмиме?» – ди. Шул мизгелдә Рузалия Казан мәктәбендә практика узгандагы теге вакыйганы искә төшерә. Малайның елап, шешенеп беткән күзләре, пычрак өс-башы күз алдына килеп баса. Тәҗрибәле кыз озак уйлап тормый – ризалаша. Шулай итеп, ун елдан соң ул янә Лаешка әйләнеп кайта.

– Балалар йортында эшләү тәҗрибәм юк иде бит, – дип искә ала ул көннәрне Рузалия апа. – Җиңел булды, димим. Ул чакта биредә 114 бала иде. Ләкин шуңа төшендем: бу балаларның күңелен аңлыйм икән. Беренче гаҗәпләндергән нәрсә – биредә эшләүчеләр һәр баланың исемен беләә! Каян истә калдырып бетерергә, дип уйладым. И, бер атна эчендә үзем дә бөтен малайкызның исемен ятладым. Исемен генә түгел, һәркайсының язмышын, холкын да өйрәндем.

1994 елда Рузалия Вәлиуллинаны Лаеш балалар йортының директоры итеп билгеләделәр.

– Элеккеге директор Виктор Васильевич белән сигез ел эшләдек, – ди Рузалия апа. – Әлбәттә, ул мине күп нәрсәгә өйрәтте. Мин аңа бик рәхмәтле.

ЯРАТУ...

Өч дистә елдан артык балалар йортында эшләү дәверендә, Рузалия ханым кемнәр белән генә дә очрашмаган да, нинди генә проблемаларны хәл итмәгән... Аның гаиләсе дә, балалары да шушы – балалар йорты.

– Рузалия апа, гафу, шәхси сорау бирәм. Сезнең гаиләгез юк. Берәр баланы тәрбиягә алу нияте булмады? – дим җитәкчегә сак кына.

Рузалия апа берничә секунд уйга калды. Аннан күзгә карап сүзен башлады:

– Бу хакта берәүгә дә сөйләгәнем юк. Әйе, булды. Моннан дистә еллар элек берничә кечкенә баланы алып килделәр. Мин әле директор урынбасары булып эшли идем. Шулар арасында бер нәни генә кыз бар. Сәламәтлеге начар, безгә килгәнче ул ятып кына торган. Без аңа кулдан килгәнчә ярдәм иттек. Ярты елдан кызчык аягында йөгереп йөри башлады. Биш-алты яшьләрендәге әлеге сабый белән безнең арада аерым бер җылы мөнәсәбәт урнашты. Эшкә килүгә аның янына барам. Ул да гел мине көзли. Шулай бер сөйләшкәндә дусларыма: «Балалар йортындагы бер кызчыкны тәрбиягә аласым килә», – дидем. Шулвакыт күбесе: «Әгәр бу кызны тәрбиягә алсаң, синең башка балаларга игътибарың кимиячәк, эшкә вакытың калмаячак», – дип киңәш бирде. Мин уйлана калдым.

Язмышымы, башкамы, шулай икеләнеп йөргән мәлдә Рузалия апаның эш бүлмәсенә киңәшкә дип бер гаилә килеп керә. Тәрбиягә бала алыр-

га телиләр икән. Нәкъ шул вакыт теге кызчык та биредә була. (Рузалия апа янына бик еш кереп йөри башлый ул.) Һәм алар бер күрүдә шушы кызчыкны ошаталар, тегесе дә аларга карап елмая. Ир белән хатын балалар йортына икенче көнне дә килә. Кызга дип бүләкләр алып киләләр. Бер-ике ай вакыт узгач, кызны гаиләләренә тәрбиягә алалар.

– Күңелегезгә хуш килгән баладан аерылу авыр булдымы? – дидем.

– Озак уйладым. Беренчедән, ир белән хатынтулы гаилә. Икенчедән, кызга мөнәсәбәтләре бик әйбәт икәненә инандым. Ә иң мөһиме – кызчыгым да бу гаиләне яратты. Димәк, Аллаһы Тәгалә хәерлесен биргән. Без алар белән аннары да аралашып тордык. Чынлап та, кыз ул гаиләдә бәхетле булды. Әти-әнисе сәламәтлеген дә кайгыртып яшәделәр, укыттылар, кеше иттеләр. Ул яктан күңелем тыныч.

– Ә аннан соң тагын тәрбиягә бала алу уе тумадымы соң?

– Юк. Тәҗрибә туплаган саен, балаларны аермаска өйрәндем – барысын тигез күреп яратам. Алай да, балалар йортында тәрбияләнүче малай-кызларны өйгә алып кайткан чаклар булды.

«ҺӘР БАЛА ӨЧЕН БОРЧЫЛАМ»

Лаеш балалар йортында бүген 32 бала тәрбияләнә. Шуннан артык сыймый икән. Яңа таләпләр буенча, бер төркемдә сигез баладан артмаска тиеш. Биредә кечкенәләр, зурлар аерым яши. Мәктәпкәчә яшьтәгеләрнең шартлары нәкъ балалар бакчасындагы кебек. Иртән торалар, ашыйлар, рәсем ясау, уку белән шөгыльләнәләр, аннан саф һавага чыгалар. Шуннан соң төшке аш, йокы... Ә зурраклар, үсмерләр исә Лаеш район үзәгендәге мәктәпләрдә белем ала. Биш вакыт кайнар ризык, чиста урын-җир, яңа киемнәр – барысы да бар. Әти белән әни генә юк...

– Балалар йортларында бүгенге кебек шартлар бөтән беркайчан булмады, – ди директор. – Һәм бу безнең балалар йортында гына түгел, республика буенча шулай. Ашау турында әйткән дә юк. Гаиләдә яшәүче балаларның яртысы болай тукланмыйдыр.

– Иганәчеләр дә ярдәм итәме?

– Әйе, рәхмәт яусын. Безнең исемлектә кемнәр генә юк. Хәзер бит балалар да заманча фикер йөртә – бүләккә конфет кына канәгатьләндерми. Кулланылышта яраклы, кызыклы әйбер кирәк аларга. Телефон, сәгать, башкасын сорыйлар. Бу турыда иганәчеләргә җиткерәбез инде.

Лаеш балалар йорты гомергә спортка игътибар биргән. Бүген дә шулай. Биредә тәрбияләнүчеләр арасында спорт мастерлары, чемпионнар бар. Ярышларга кайларга гына йөрмиләр.

– Ремонттан соң республика буенча балаларны өр-яңадан җыйдык, – диде Рузалия апа. – Шуңа башта авыррак та булды. Төрле җирләрдә тәрбияләнгән балалар бит. Бер оя, бер гаилә итеп туплау өчен вакыт, сабырлык, көч кирәк. Кайбер балалар белән бүген дә сәгатьләр буе сөйләшеп утырам. Мәктәп белән дә проблемаларны хәл итәргә туры килә. Арттырып әйтү түгел – һәр бала өчен борчылам.

Балалар йортының ишегалдына чыктык. Мәктәптән кайтып, тамак ялгап алган малай-кызлар да монда иде. Кайсы роликта йөри, кемдер волейбол уйный. Мондый заманча спорт мәйданчыклары республикада да санаулы гынадыр. (Бер иганәчеләр төркеменең бүләге икән бу.) «Озакламый машина белән түгәрәкләргә барачакбыз», – диде алар.

Машина дигәннән, Лаеш балалар йортына автобус кирәк. Рузалия апа хәтта аның маркасын да әйтте – «Вектор NEXT ПАЗ».

– Капиталь төзекләндерү булды, моның өчен республика җитәкчелегенә зур рәхмәт. Тик менә автобус та сорарга кыюлык җитми. Ә ул безгә бик кирәк. Җиңел машинага балаларның барысын да сыйдырып бетереп булмый, алар бит төрле түгәрәкләргә йөри. Автобус белән бөтән шәһәрләргә дә йөрер идек.

Рузалия апа – тынгысыз җан. Кеше үз балалары өчен дә болай йөгермәс. (Әле бит балалар йортыннан киткәндә, егет-кызларны төрле уку йортларына үзе алып барып урнаштыра. Аннан соң да хәлләрен белеп тора.) Очрашкан саен гаҗәпләндерә, ихтирам уята ул. Дөньяны матурлык коткара, дибез. Тагын менә Рузалия апа кебек миһербанлы җаннар да, дип өстәр идем.

4
– Тәҗрибә туплаган саен, балаларны аермаска өйрәндем – барысын тигез күреп яратам, – ди Рузалия Вәлиуллина.

Шәриф Камал

БУРАНДА

(Кыскартып бирелде)

Рәсем «Татарму[illegible]н алынды



1

Яшь бала елый иде...

Тышта җил, буран дөньяның астын өскә китерерлек булып кузгалган, лапас һәм морҗаларда җил әллә нинди моңлы җырлар җырлана иде...

Ярты төн узган, эшле, эшсез йоклый, әмма бала һаман елый иде. Биш-ун минутка туктап тора, тагын башлый... Бишеге янында юатыр өчен газапланган анасы бигрәк тә, ирем һәм кунак тынычлап йоклый алмый торганнардыр, дип борчыла иде.

Әлбәттә, кунак йокламый иде.

Инде авылның төрле ягында әтәч тавышлары ишетелә, мөәзин, манарадан азан кычкырып, мөселманнарны йокыларыннан уята... Шул чагында гына бала йоклады...

Хөсәен кунагы белән иртәнге чәй янына утырган иде.

– Буран азрак басылган, ахры... – диде кунак.

Хөсәен аның сүзләрен шаяртуга юрап, сүзнең киресен аңлата торган тавыш белән:

– Әйе... басылган! – диде.

Һаваның начарлыгы чиктән тыш иде. Тыкрык һәм читән буйларында кар эскертләре, тау-тау өелеп, өй һәм сарайлар белән тигезләнә, унбиш-егерме саженьнан читтә бернәрсә күренми, туктаусыз буран улый иде.

Алар бик тәкәллефсез кылана, чөнки ике ел солдатта бергә булганнар иде. Хөсәен үткән ел ук кайткан иде. Иптәшенең хәзерге кунаклыгы – солдаттан кайтышы иде.

Хөсәен бүген иптәшендә кызык кына бер алышыну күрә, каш астыннан гына карый һәм гаҗәпләнә иде. Чөнки иптәшенең хәрәкәт һәм кыланышында әллә нинди бер аптырау күрә иде.

Һәрнәрсәгә мыскыл күзе белән карый, бер сүзгә дә ышанмый, кеше сөйләгәнне тыңламый, үзе сөйләсә, кешедән көлә торган салкын һәм җан җылысыз бу кешенең аптырау һәм оялуы чыннан кызык иде.

Хөсәен чыдамады:

– Мостафа, син әллә нинди бүген?.. – диде.

– Иптәш, ат әзерләп куй. Миңа тизрәк китәргә кирәк.

– Китәргә? Мондый һавада? «Тизрәге» дә бар тагын!

– Әйе, мөмкин кадәр тиз.

– Мондый буранда, иптәш... Барыбер илтүче табып булмас... Бүген кунарсың! Иртәгә...

– Табылмаса, җәяү китәм!

Бу җавап бик катгый иде. Ике иптәш бераз эндәшми торды.

Хөсәен әллә ни әйтмәкче иде, Мостафа тагын:

– Әйе, китәм, – диде.

2

Хөсәеннең хатыны Гайшә өстәл җыештырып маташа, Мостафа идән буенда йөри иде. Хөсәен чыгып китте.

Тышта буранның сызгыруы белән стенадагы сәгать тыкылдавыннан башка өй эчендәге тынлыкны бернәрсә дә бозмый, тик бишектә йоклаган баланың ара-тирә көрсенеп ыңгырашуы гына ишетелгәли иде.

– Көн бик начар, – диде Гайшә. – Соравыбызны кабул итмисең инде... Бик туйдың, ахры; балабыз елаграк шул...

– Сез аналар... Һәммәгез дә шулаймы?

– Ничек?

– Бала өчен газапланасыз...

– Һәммәбез булмыймы соң? Йөрәктән төшкән булгач, бар дөнья шул бала инде...

– Әмма бала усал! – диде Мостафа һәм, бизгәкле кеше кебек, ашыга-ашыга киенә башлады.

Ике тәрәзә арасындагы көзге турысына килде; башлыгының очларын алдан әйләндереп, артка бәйләп маташты. Аның картузы кызыл тирәле булып, шинель погоннарына сары буяу белән Германия императорының вензеле төшерелгән иде.

Ул тагын:

– Бала усал... – диде.

Ул Гайшәгә нәрсәдер сөйләргә теләгән иде, ишектән Хөсәен керде һәм:

– Иптәш, ат әзер! – диде.

3

– Юлны яхшы беләсеңдер бит? – диде Мостафа.

– Белергә беләм дә бит...

Мостафаны авылына илтүче кеше алтмыш яшьлек бабай иде. Алай да җавапны кистереп әйтә алмады: чөнки кырда юлны югалтмый бару шактый читен иде.

Бабай, тынычсызланып, як-якка карана. Читләрендә бернәрсә дә күренми, тик кар диңгезе генә кайный. Ара-тирә күренгән сызыклар, чана эзләре – менә бабайның бар ышанычы һәм өмете иде...

– Менә шул коега бездән дүрт чакрым, – диде бабай, – егерме чакрымлап әле артыгы белән барырга...

– Әле дә ерак... – диде Мостафа.

Бераз эндәшми баргач:

– Хода сакласын! Адашмыйк кына, – диде карт. – Ходa сакласын... Кайтмыйкмы, дим? Буран артык тилерә бит...

– Барыйк әкертен генә. Анам карчыкны бик күрәсем килә, барыйк. Әйдә, әкренләп...

Бу соңгы сүзләр гүя әллә нинди аһәң белән сөйләнде. Карт моңар сихерләнгән кебек бирелде... Каршысында җәһәннәм яисә кайнап котырып торган диңгез булса да кечерәк иде.

Алар сөйләшми бара.

Мостафа чикмәнгә чорналган, уйлый: ул – кечкенә бала... Төш күрә: әллә нинди канатлы һәм бик матур балалар белән уйный. Алар аны тарткалый... этә... уяна – анасы аны үбепүбеп елый:

– Күзем нурым! Атаң мине сөрә... Каласың, бәгырем! – ди.

Атасы читтәрәк көтеп тора:

– Күрештең, – кулы белән күрсәтеп, – юлыңны кара! – ди.

Ул вакытта Мостафа алты гына яшьтә булса да, шулвакыт күргәннәрен бик ваклап хәтерли иде.

Мәсәлән, ул вакытта, йокысыннан уянган чакта, битенә тамган күз яшьләренең кайнарлыгын һәм шул кайнар күз яшьләрен анасының чыланып беткән яулык белән сөртеп маташуын, хәтта яулыкның төсе зәңгәр булып, читләре ак иканлеген хәзер дә ачык хәтерли. Узган төннән бирле гүя шул кайнар тамчылар тагын аның битенә тама һәм пешерә... Анасы, куркынган һәм аптыраган хәлдә, чыланган яулыгы белән аларны сөртә...

– Анаң безне сөймәде, икенче иргә китте...

Менә ул вакытларда – анасы белән кечкенә кардәше Фатыйманы юксынганда – атасының аңар әйтә торган шул сүзләре аның күңелендә анасына ниндидер салкынлык һәм нәфрәт хисләре уяндырганлыгын һәм, ниһаять, анасыннан бөтенләй бизгәнлеген уйлап, ул хәзер газап чигә иде.

Ул анасыннан бизгәнмени инде? Әйе, ул үзен тудырган һәм бишеге янында басып, караңгы, тын һәм күңелсез төннәрне «балам» дип йокысыз уздырган анасыннан бизгән иде!

Ул яшьрәк вакытында:

– Син минем анам түгел! – ди иде.

Хәтта бервакыт йөзенә көл бәргән иде. Аны котырттылар:

– Мокай килгән! Битенә көл бәр!.

– Әйдә!..

Болар һәммәсе – яшь вакытында, әмма зур булгач? Менә хәзер аның беренче мәртәбә бармагын тешләп аптыраганы да – үзенең анасына каршы атасы барында күрсәткән тәрбиясезлекләреннән тыш, атасы үлгәч тә, анасыннан гафу сорамавы, һаман аңар илтифатсызлыгы һәм салкын мөгамәләсе өчен иде...

Төш вакыты узган, буран һаман дулый... Карт бик дикъкатьле һәм җанлы күренә иде.

– Ярты юлны килгәнбездер? – диде Мостафа.

– Артык булыр... Ястү вакытларында җитәрбез, – диде карт һәм янә өстәде: – Хәзер анаң бик сөенеп көтә булыр... Сагынгандыр... Дүрт ел бит!

– Егерме ел... Ләкин бүген кайтасымны белми ул...

Карт бераз уйга калды.

– Аналар белә... Алар сизә... – диде.

Мостафа эндәшмәде.

Ахшам вакыты. Әкрен генә караңгы төшә иде.

Мостафаның хыяллары күзенә күренгән кебек була. Гүя сөйли дә иделәр.

Ул чикмәнгә бөркәнгән, анасы, аның күзенә карап, әкрен генә сөйли:

– Мостафа! Күз нурым, анаң булам... Ник килмисең? Кил, үбим, бәгырем... Ачуланмыйм, битемә көл бәрүеңә дә ачуланмыйм... Кил, үбим дә, бер генә мәртәбә «анам» дип әйт!..

Мостафа анасының аягына ташланырга дип чикмәнне ача... Күз алдында – очсызкырыйсыз караңгылык кына... Бураннан каплана, тагын шул таныш чырай, таныш тавышлар...

Ул Мостафага чана яныннан җәяүләп килгән шикелле күренә... Куәтле һәм кискен җилдән аерылып та, Мостафаның колагы яныннан искән әллә нинди йомшак, шәфкатьле җил агымы, киңәшеп кенә:

– Әйт! Анам дип әйт... Егерме ел инде... Ишетәсеңме?!. – ди иде.

Алда, әллә кайларда, диңгез аркылы күренгән төсле тымызык һәм төмсә ут шәүләләре чагылып тора; Мостафаның колагына, ерактан, кичәнең караңгылыгына кушылып, үзалдына бер моң һәм зар белән көйли торган тавышлар ишетелә башлады... Этләр өрә иде...

4

Ахшам үтте. Буранның котыруына карамыйча, капкадан йөри иделәр... Хатыннар берсе килеп кергәндә, икенчесе бик кайгылы кыяфәттә чыгып бара һәм күңелсез генә берәр сүз катыша иде...

Тәрәзә алдына яткан сары эт, зур һәм кара күзләрен сөзеп, килгәнне каршы ала, киткәнне күзләре белән озата иде. Ул гүя кайгылы иде... Аның сөйгән тәрбиячесе хуҗа хатын бу кич инде үлемнең куркынычлы арасында сугыла иде...

...Аның яме киткән, төсе балавыз кебек саргайган, күзләре төпкә баткан, кул һәм аягы салкын, күкрәге, бер кабарып, бер төшеп, авыр-авыр сулый. Бичара хатынның хәяттән өлеше бетеп килә иде...

Илле ел тәнен, уен идарә иткән җан үзенең иске тонык тәрәзә кебек күзләреннән кемгәдер актык мәртәбә карап, тынычланып китәсе килә иде. Бичара хатын, кызганыч ана, күзләре белән нидер эзли, нидер юксына, кемнедер күрмичә үләсе килми, торып-торып:

– Килмәдеме?.. – дип сорый иде.

Кызы Фатыйма бертуктамый елый.

Анасының бер тәүлектән бирле кабатлаган шушы «килмәдеме» соравы аның күңелендә әллә нинди тирән һәм иске җәрәхәтләрне яңадан ача иде...

Өч атнадан бирле авырып яткан анасы узган кич беренче мәртәбә төн уртасында:

– Фатыйма! Тор. Тизрәк чыгып кара... Килмәдеме? – дип аны куркыткан иде.

Менә шуннан бирле һаман көтә... Көн уртасында инде сабырсызлык күрсәтә һәм саташа башлады.

Икенде белән ахшам арасында тартышыптартышып елады: гүя кайдадыр аның бер дә тиңсез сөекле баласы бар, имеш, алар гомер буе күрешә алмый, кемнәрдер күрештерми, имеш. Хәзер ул актык сулышында актык бурычын түләргә, анасы белән күздән мәхәббәт яшьләре түгешергә килгән, имеш, ләкин... бичараны кертмиләр, әллә кайларга кайтарып җибәрәләр, имеш...

Ахшам вакытында аның тавышы беткән иде инде. Шулай да һаман әлеге «килмәдеме» дигән сүзләрне күзләре, иреннәре белән аңлатырга тырыша иде...

Бичара ана! Биш-ун сулыш, һәрберсе газап.

Шәфкатьле ана! Бу кадәр хәсрәт кичерергә тиеш түгел иде. Әй, мәрхәмәтле ана! Соңгы сәгатьләреңдә генә «аны» онытсаң иде...

Ананың инде кул-аяклары сизми, кузгалмый, алар салкын һәм авыр ташлар кебек... Ул диңгез төбенә төшеп бара... Ә диңгез һаман салкыная... Ләкин... аһ, ялгыз гына... «Ул» да янында булса иде...

Чү! Ишек катында кемнәр?

Ишек ачылды. Керделәр... Ике кеше...

Берсе катып калды... Тезләнде... Елаган тавыш белән:

– Анам!.. – дип кычкырып җибәрде дә карчыкның күкрәгенә йөзен куеп елый башлады...

Бу Мостафа иде.

– Килдем... Шәфкатьле анам! Бер генә йөземә кара! Анам, җаным, күзем... Анам! – дип акырып-акырып елый, әмма анасы илтифат итми иде... Ул гүя үпкәләгән иде. Аһ!.. Бер генә карасын!..

Ләкин ул инде карый алмый иде...

Тышта буран һаман дулый иде...

Тәртип

Казан 93,1 FM
Яр Чаллы 90,2 FM

Тәртипле халык югалмый!
Татар тәртипсез була алмый!

tartip.tatar
@tartip.tatar
tartip.tatar

App Store
Google Play

Реклама 6+

РЕДАКЦИЯ КУХНЫ
Журнал
ТАТАРСТАН
Редакционная кухня
Обращение к народам всего мира
Татарстан

ВЕНГРИЯ КОНСУЛЫННАН МАҖАР ГУЛЯШЫ

Автор: Татьяна Вафина

Күптән бер венгр ризыгы да ашаганыбыз юк. Беркайчан да ашаган юк дип тә әйтергә була. Һәм менә ул теләгебез чынга ашты: «Татарстан» Венгриянең Казандагы Генераль консулы Адам Штифтерда кунакта бүген. Кунакчыл халык вәкиле буларак, кунакчыл хуҗа үз иленең төп ризыгы – маҗар гуляшын әзерли. Зу-у-ур кәстрүлдә!

– Бу кадәр гуляш белән бөтен Татарстанны сыйларга мөмкин. Әле тагын күрше республикаларга да калачак!

– Без, венгрлар, ике-өч кашыклык ризык пешереп маташмыйбыз да, – ди Адам. – Гуляш һәрвакыт күп булырга тиеш, бөтен гаиләгә һәм кунакларга җитәрлек. Ә кунакларыбыз һәрвакыт күп, без – бик кунакчыл халык.

ЧИПЕТКЕМЕ, ӘЛЛӘ УМАЧМЫ?

– Маҗар гуляшы башкаларныкыннан ни белән аерыла?

– Пешереп бетергәч, авыз итеп карарсыз да үзегез әйтерсез. Ә әзерләү үзенчәлегенә килгәндә... Бездә ул шундый куе аш, шулкадәр туклыклы, ул беренче ашны да, икенче ашны да алыштыра. Анда ит, борыч, яшелчәләр күп. Туган шәһәрем Надькерештә, мәсәлән, гуляшка чипетке дә өстиләр әле. Әмма бу бөтен җирдә дә түгел. Минем Венгриядә миннән 35 километр ераклыктагы калада яшәгән ярдәмчем Эрика гуляшка чипетке салмый. Чөнки бездә гуляш төрләре бик күп, һәр җирдә шул як халкы нәрсәдер үзенекен өсти, үзенчә пешерә: алфёльд, сегед гуляшы, сербча, коложварча, бетярча, ликочча гуляш, чанго халкы гуляшы бар...

– Без дә чипетке өстәмибез, чөнки аның хәтта нәрсә икәнен дә белмибез.

Фото: Александр Ефремов

КИРӘК БУЛАЧАК:

- Ит – 2 кг (сыер ите)
- Суган – 1,2 кг
- Сельдерей тамыры – 0,5 кг
- Кишер – 0,8 кг
- Бәрәңге – 1 кг
- Татлы борыч – 0,3 кг
- Сарымсак – 1 баш
- Төелгән татлы борыч – 3-4 аш кашыгы
- Ачы борыч – тәменчә, 1 аш кашыгы.
- Ысланган борыч – 1 аш кашыгы
- Тоз – тәменчә, 1-2 аш кашыгы
- Әнеч – 0,5-1 аш кашыгы
- Томат пастасы – 100 г
- Чипетке: 2 йомырка, 150 г он, тоз

1

– Гуляш һәрвакыт күп булырга тиеш, бөтен гаиләгә һәм кунакларга җитәрлек.

2

– «Чипетке» – бездәге «чип» сүзеннән, рус телендәге «щипнуть, отщипнуть» дигәнгә якын. Русча чипетке «отщипки» дип аталыр иде, мөгаен, ә татарча «чеметке» дип була.

– Чипетке бик вак макаронны алыштыра, андыйлар бирелдә сатылмый. Он һәм йомыркадан камыр басыла, аннан вак кына кисәкләр чеметеп алына, алар шарчык рәвешендә бөтерелә эвәләнә дә, тәмам әзер булырга 10 минут кала, гуляшка салына. Ягъни «чипетке» – бездәге «чип» сүзеннән, рус телендәге «щипнуть, отщипнуть» дигәнгә якын. Русча чипетке «отщипки» дип аталыр иде мөгаен, ә татарча «чеметке» дип була.

– Чумарга охшаган, бездә чумарлы аш пешерәләр, тик алар эрерәк. Гәрчә рус телендәге чумар – «клецки» сүзе алманнардан кергән: kloß – «төерчек» дигән сүздән... Рус халык әкиятләрендә камырдан ясалган шарны «колобок» дип атыйлар бит...

– Бездә дә «Колобок» – Кабартма турында әкият бар. Тик анда шар камырдан түгел, ә иттән.

– ???

МАҖАР КАБАРТМАСЫ РУСНЫКЫ ӨЧЕН ҮЧ АЛА

– Венгриядә эч-бавырлардан шундый йомры кабартмалар ясап, аларны чормага какланырга элеп куялар. Ә әкият менә мондыйрак, мин аны еш кына үз балама сөйлим:

Гаиләдә бөтен ит ризыгы бетә. Һәм эти-әнисе кече кызларын, Кабартманы алып төшсен дип, чормага менгереп җибәрә. Кыз менә, Кабартма бәйләнгән бауны пычак белән кисәргә җыенгач, тегесе: «Нигә кирәк мин сиңа?» – дип сорап куя. Кыз аны өйгә кичке ашка алып төшәчәген, шунда ашап бетерәчәкләрен аңлата. Шуннан соң Кабартма: «Мин сине үзем ашыйм!» – ди дә, һап итеп, кызны йотып җибәрә!

Ә өйдә аны көтә-көтә көтек булалар. Кызны алып төшәргә улларын менгерәләр. Шул ук хәл – Кабартма аны да кабып йота. Аннары әни кешене, этине, әбине, бабайны ашый... Ишегалдына тәгәрәп чыга да мәче, эт, бозау, сыерны йотып җибәрә... Шуннан урамга тәгәри. Ә анда кылычлы солдатны очрата. Кабартма батыраеп китә, ул инде зур була – күпме халыкны йотты бит! «Хәзер сине дә ашыйм!» – дип, кылычы-ние белән солдатны да кабып йота, ә тегесе корсакны эчтән ярып җибәрә. Һәм кыз да, малай да, аларның эти-әниләре дә – барысы да котыла. Һәркем исән-сау! Әкият менә шундый күңелле тәмамлана.

– Кот очыра торган фильмның бәхетле тәмамлануы бит бу. Бездәге Кабартма беркемне дә ашамый, бөтенесенә дә җырлап бирә һәм барысыннан да кача...

– Аның каравы барысы да Кабартманы ашарга маташа: «Кабартма, мин сине ашыйм!» – дип торалар.

– Анысы да хак. Маҗар Кабартмасы русныкы өчен үч ала булып чыга.

МИН РУС ТЕЛЕН... ДОСТОЕВСКИЙНЫ УКУ ӨЧЕН ГЕНӘ БУЛСА ДА ӨЙРӘНЕР ИДЕМ

– Сез рус телен кайда шулай яхшылап өйрәндегез? Һәм рус әкиятләрен дә?

– Белемем буенча мин филолог, Венгриянең Сегед университетын тәмамладым. Телләр өйрәнү һәрвакыт күңелемә якын булды. Инглизчә, алманча беләм – аларын гимназиядә укыдым... Рус телен Венгриядә үк өйрәнә башладым, әмма аны бу телдә кайда сөйләшәләр, шунда өйрәнү яхшырак икәнен аңлый идем. Грантка гариза бирдем, оттым да Мәскәүнең Пушкин исемендәге Рус теле институтына укырга кердем. Русча китаплар укырга яратам, бигрәк тә Достоевскийны, ул – минем яраткан язучым. Аны мажарча да укыдым, әмма оригинал телдә күбрәк ошады. Пушкинны да яратам. Мажар телендә китап табу мөмкин булмаган Мәскәүдә эшләгәндә, Стивен Кингны русча укыдым. Бу китаплар киштәмдә аерым урын алып тора. Шәхсән үзем укырга яратам һәм шуңа да игътибар итәм: китапларга мәхәббәтнең сүрелүе турында ни генә сөйләсәләр дә, Россиядә күп укыйлар. Мин кәгазьдә басылган китаплар укыйм – аларның исе дә, битләрне ачып-ябу да үзенчә әсәрләндерә. Электрон китапларны үзем белән самолетка гына алам, чөнки балаларым икәү, барысы да китап ярата, әгәр һәркайсыбыз өчен кәгазь китап алсак, багаж тиешледән авыррак була.

КЫСТЫБЫЙ ҺӘМ ГӨБӘДИЯ

– Ә татар теленә мөнәсәбәт ничегрәк?

– Әлегә өйрәнү процессында. Әмма Татарстанда инде бишенче ел эшләвем сәбәпле, әңгәмә татарча барганда, мин, нигездә, сүзнең нәрсә турында барганын аңлыйм. Бездә уртак сүзләр бик күп, аеруча көнкүрештә. Мәсәлән, алма, болта (балта)...

– Татар ризыкларына карашыгыз?

– Миңа кыстыбый бик ошый. Чөнки мин бәрәңге яратам – ә анда ул шундый тәмле! Хатыным гөбәдия дә пешерергә өйрәнсен иде, миңа ул да бик ошый. Бигрәк тә кызгылт эремчеге. Корт дип атыйлар бугай. Андыйны башка беркайда да ашаганым булмады.

Бездә камыр ризыкларын хатын-кызлар пешерә. Ә инде учакта берәр нәрсә пешерергә дигәндә, анысы инде ир-атныкы. Гуляш та – ир-атлар әзерли торган ашамлык. Шуңа күрә, хатыным мажар ашларын гына түгел, әйтик, хәтта теленнe йотарлык итеп борщ әзерли белсә дә, гуляшны һәрчак мин пешерәм.

ПРОДУКЦИЯ ҺӘМ ТЕХНОЛОГИЯЛӘР

– Венгрия белән Татарстан 30 елга якын хезмәттәшлек итә. Бу еллар дәвамында бергәләп нәрсәләр эшләнде?

– Венгрия авыл хуҗалыгы өлкәсендә бик алга киткән дәүләт, ул аграр ил санала, ә Россия борын-борыннан Венгрия продуктлары һәм технологияләре өчен базар булып санала. Без әле совет чорында ук тыгыз хезмәттәшлек иттек, үз продукциябезне җибәреп тордык. Аеруча Татарстанга, чөнки республика – сөт җитештерү тармагында әйдәп барган төбәкләрнең

3

– Венгрия Республикасы Президенты Арпад Гёнцны Минтимер Шәймиев каршы ала һәм аны «тынычлык илчесе» дип атый.

берсе. Монда Венгриядән мөгезле эре терлек бик күпләп кайтартыла. Шулай ук төрле үсемлек, кукуруз орлыклары килә, бу чәчүлек, мал-туар белән ничек эшләргә кирәклеген өйрәткән үстерү һәм җитештерү технологиясенә дә карый. Әлеге технологияләр бездә яхшылап эшләнгән. Венгриядә бер сыердан савым күләме елына 10 мең, ә кайвакыт хәтта 11 мең литрдан артык була. Бу – бик зур сан! Татарстанда әлеге күрсәткеч якынча 6 мең литрны тәшкил итә. Татарстанда гына түгел, Россиянең башка төбәкләрендә дә шулай. Бездә – ике тапкыр күбрәк. Югыйсә сыерлар шул ук. Болар барысы да Венгриядәге шартлар, климат белән бәйле, диләр, әмма эш анда гына түгел. Малны карау-тәрбияләү башка. Мәсәлән, сөт җитештерү буенча әйдәп барган төбәкләрдән берсе булган Ленинград өлкәсендә күрсәткечләр Венгриядәге кебек – бер сыердан елына 11 мең литрга якын сөт савыла. Югыйсә анда климат Татарстандагыга караганда күпкә начаррак. Барысы да җитештерү технологиясенә бәйле. Мөгезле эре терлекләрне биредә мөмкин кадәр күбрәк сатуга ирешү өчен, нәкъ менә шушы технологияләр белән шөгыльләнәбез.

Тагын да колачлырак проектлар да бар, әйтик, 2019 елда Венгриянең NNG компаниясе мәгълүмати технологияләр өлкәсендәге проектын башлап җибәрде, Иннополиста үз үзәген булдырды. Инвестицияләр күләме 689 млн сум тәшкил итә. Алар машина төзелеше өлкәсендә навигация системаларын эшләгән, һәм Россиядәге җитештерүчеләрне автомобиль йөртүчегә ярдәмнең заманча интеграцияләнгән системалары белән тәэмин итү буенча эш алып бара. Венгрия компанияләре һәм Россия базасы нәкъ менә Иннополиста урнашкан. Быел җәй безнең тышкы эшләр министры Петер Сийярто Татарстанга килде һәм Рөстәм Нургали улы белән бергә Түбән Камада, «ТАНЕКО» базасында резина битумы җитештерү заводы төзелешен

4

Ә хәзер шуны ук кабатлагыз, зинһар, тик бу юлы маҗарча...

5

Ипекәйне Эрика кызы Ленке белән бергә үзенчәлекле маҗар рецепты буенча, куаслы әчеткедә пешергән.

башлап җибәрде. Асылын сез инде беләсездер, сүз кулланышта булган иске автомобиль шиннарыннан битум ясау турында бара, шуннан юллар төзеләчәк. Тулысынча Венгрия технологиясенә генә нигезләнгән ысул. Мондый юлларда тормоз юлы шактый кыскарак, алардан йөрү куркынычсызрак, автомобильләр хәрәкәтеннән тавыш та түбәнрәк, мондый катлам температура үзгәрешләренә дә чыдамрак. Татарстанда җәен – плюс 37–38, кышын исә минус 27–30 градуска җитә, аерма 60 градуска якын, шуңа күрә юлларны еш ремонтларга туры килә. Мондый технологияне кулланганда, юллар шактый озаграк хезмәт итәчәк. Бу – Венгрия нефть компаниясе һәм «ТАНЕКО»ның уртак проекты.

САНКЦИЯЛӘР АША – КАЗАНГА

– Сез үз һөнәрегезгә һәм Казанга ничек килеп эләктегез?

– Россиягә каршы санкцияләр һәм Венгрия товарларына каршы Россия санкцияләре кертелгәндә, мин нәкъ менә сәүдә өлкәсендә эшли идем, яшелчә, җиләк-җимеш саттым. Безнең барлык товарларыбыз да тыелганнар исемлегенә эләкте. Венгрия, мәсәлән, төрле сорт алмалар үстереп сата иде. 30 ел дәвамында алар Россия базарына эшләде. Алга таба аларга ничек яшәргә? Нәрсә эшләргә һәм кайда сатарга – моны белми идек. Продуктларның сыйфаты бик яхшы, күләме дә тел тидерерлек түгел, әмма алар барысы да тыелганнар исемлегендә. Җитештерүчеләргә яңа мөмкинлекләр табарга ярдәм итү өчен, министрлыкта махсус команда оештырылды, мине шул командага эшләргә чакырдылар. Россия белән эш алып барганымны анда беләләр иде, аларга нәкъ менә шундый белгеч кирәк булган, һәм менә шул рәвешле мин дәүләт хезмәтенә эләктем. Аннары Санкт-Петербургта сәүдә-икътисадый мәсьәләләр буенча консул булып эшләдем. Ике елдан соң Казанга Генераль консул итеп күчерделәр. Гомер буе Россия белән эш йөрттем, мин Венгриядә Россияне, аның кешеләрен, мәдәниятен, сәясәтен, ничек эшләргә һәм ничек аралашырга кирәклеген белә торган, сәүдәдә зур тәҗрибә туплаган кешеләрнең берсе. Менә шундый минем тарихым.

Казанга беренче тапкыр 2015 елда Сәүдә делегациясе составында килдем. Шәһәр, кешеләр – барысы да ошады. Аннары Венгриянең Тышкы эшләр министрлыгы составында килдем – биредә генконсуллык ачтык. Ә 2017 елда мине монда Генераль консул итеп билгеләделәр.

Бүген без туристлык юнәлешен актив үстерәбез.

ОЛЫ ТИГӘНӘЛЕ – МАҖАРЛАРНЫҢ БОРЫНГЫ БИШЕГЕ

– Венгрлар россиялеләрне ничегрәк күзаллый?

– Көнчыгыш блокка караганлыктан, бездә социалистик сәяси система булды һәм без элек-электән совет халкына җылы карадык. Мөнәсәбәтләребез яхшы булды. Россиялеләр – иң әүвәл дуслар. Моннан тыш, әгәр тарихны тирәнрәк актарып карасак, мажар кабиләләренең, X гасырда Карпат бассейнына күченгәнче, озак еллар нәкъ менә шушы территориядә яшәгәнен беләбез. Борынгы бишекләребезнең берсе Башкортостан һәм Көнчыгыш Татарстан территориясендә урнашкан. Иң зур мажар каберлеге Татарстанда, Алексеевск районының Олы Тигәнәле авылында табылды. Анда 150 мажар кабере билгеле. Болгар янындагы Тәнки авылында да мажар каберлекләре бар. Геннар дәрәҗәсендә бу якынлык әлегәчә сизелә. Безнең археологлар бирегә еш килә, җирле белгечләр белән уртак эш алып барыла.

1990 нчы елларда, Советлар Союзы җимерелгәннән соң, кем белән дус булырга һәм ничек дус булырга икәнлеге аңлашылмаган дәвердә Татарстанга иң беренче Венгрия делегациясе килүе белән горурланабыз. Венгрия Республикасы Президенты Арпад Гёнцны Минтимер Шәймиев каршы ала һәм аны тынычлык илчесе дип атый. Минтимер Шәрип улы бу сәфәрне Татарстанның яңа юлын хуплау һәм уртак тарихыбызга хөрмәт билгесе буларак кабул итүләре турында сөйләде. Сәяси строй үзгәрергә мөмкин, әмма дуслык сакланып кала икәнлеген үрнәк итеп күрсәттек – тормышта нәкъ шулай булырга тиеш тә. 1993 елда бу очрашуны Рамил Гали фотога төшергән һәм истәлекле сурәтне безгә дә бүләк итте.

САГЫНУ

– Советлар Союзы чорында туып-үскән халкыбызда совет тормышын сагыну бик көчле. Сезнең халыкта да мондый хис бармы?

– Әлбәттә, бар. Бу чор 45 ел диярлек дәвам итте. Шуңа күрә сагынусыз була да алмый. Шәхсән мин ул вакыттагы автомобильләрне сагынам. Хатынымның бабасында җиденче модель «Жигули» бар иде. Күптән түгел аны сатты, автомобиль бик яхшы хәлдә иде: тавышы дисеңме, исе дисеңме, йөреп тора. Могҗиза машина! Аның белән аерылышканда бик җәлләтте.

Һәр Венгрия шәһәрендә диярлек совет солдатлары яшәде. Ул вакытта Венгриядә хезмәт иткән танышларым монда да күп. Венгриядә туган Татарстан кызы да бар, әтисе шунда хәрби хезмәт үткән булган. Аның паспортында: «Туган урыны – Секешфехервар шәһәре, Венгрия», – дип язылган. Ягъни кешеләрнең бәйләнеше, элемтәләре бар. Һәм алар бу элемтәләрне югалтырга теләми. Ул чакта яхшырак яки начаррак булды дип әйтмим. Барысы да үзгәреп тора. Әмма үткәннәрне, яшьлекне сагыну хисе һәрвакыт яши.

6

Һәр шәрабның үз риваяте бар...

СТУДЕНТЛАР БЕЗГӘ ЯРДӘМ ИТӘЧӘК

– Татарстанда күпме венгр яши?

– Бик аз. Егермеләп кеше. Шуңа күрә, ни кызганыч, без Казанда Венгрия бәйрәмнәрен һәм чараларын тулысынча күрсәтә, тәкъдим итә дә алмыйбыз. Хәтта безне футбол уйнарга чакырганда, үз илебез данын яклардык команда да туплый алмыйбыз. Шуңа күрә мин хәзер Казанга Венгрия студентлары укырга килгәнгә бик шат, яшьләребез киләчәктә дә монда укырга килер дип уйлыйм.

Ә Венгрия өчен Россия студентлары сирәк күренеш түгел. Югары уку йортларында белем алу өчен, Россия студентларына ел саен 200 грант бирелә. Бу бик шәп, минемчә. Чөнки кешеләр шул рәвешле Венгриягә килә, анда тормыш кора, белем ала, яңа дуслар таба, алар белән инде гомер буе элемтә тотачаклар. Сәүдә-икътисад тармагында булсынмы, мәдәният өлкәсендә булсынмы, гомумән, теләсә кайсы өлкәдә дә безнең мөнәсәбәтләр ныгыячак! Венгриягә бик күп россиялеләр нефть тармагы буенча укырга килә. Илебезнең бу өлкәдә горурланырлык нәрсәләре бар. Төзүче, инженер һөнәрләре дә – популяр юнәлеш. Кайберәүләр мажар телен өйрәнү өчен махсус килә. Ижевскида, мәсәлән, мажар теле кафедрасы бар-анда студентларны бик югары дәрәҗәдә укыталар, алар соңыннан мажарча бик әйбәт сөйләшә. Шуннан соң алар Венгриядә мажар телен чит ил кешеләре түгел, ә белгеч буларак, тагын да югарырак дәрәҗәдә өйрәнә. Һәм бик шәп тәрҗемәчеләр, мажар теле укытучылары булалар. Бу безнең өчен бик мөһим. Мондый кешеләр аша илләребез арасында бәйләнеш тагын да ныгый бара.

7

Гадәттә дипломатик сөйләшүләр алып барыла торган өстәлгә бик зур кәстрүл килеп кунаклый. Консуллык хезмәткәрләренең бүгенге төшке ашы – баш аш-су остасы Адам Штифтердан маҗар гуляшы.

ҺӘР ЭШНЕ ЕЛМАЮ ХӘЛ ИТӘ

– Маҗар кешесен нинди билгеләр аша танып, аерып була?

– Без һәрвакыт елмаябыз.

– Тай халкы кебекмени?

– Тагын да киңрәк итеп. Безнең акцент та үзенчәлекле, шуңа күрә сөйләшә башлауга ук сизеп алачаксыз. Гомумән, без – аралашучан, ачык күңелле, кунакчыл халык. Хәер, татарстанлылар шундый ук. Мәскәү кебек артык зур шәһәрләр кешелек мөнәсәбәтләрен боза, адәм балалары үз эченә йомыла, бер-берсеннән читләштерелә. Ә Казанда мондый хәл юк. Биредә төрле милләт кешеләре яши һәм барысы да әңгәмә корып җибәрергә әзер, ачык йөзле, игелекле.

Без дә илебездә төрле халыкларның күп булуы белән горурланабыз, һәм аларга дәүләт тарафыннан ярдәм инфраструктурасы да шактый үсеш алган. Барысының да үз мәдәни үзәкләре, фестивальләре, бәйрәмнәре бар. Словаклар, сербларның диаспоралары бик зур, татар диаспорасы бар. «Татар кызы» бәйгесе дә менә 2018 елда Венгриядә узды. Без үзебезнең маҗар кызларының матурлыгы белән горурланабыз, әмма татар туташларының чибәрлеге алардан бер дә калышмый.

ВЕНГРИЯДӘ – ТӨРЕК МУНЧАЛАРЫ, РАИФАДА – БӘКЕ

– Венгриядә беренче чиратта нәрсәләр карарга киңәш итәр идегез?

– Будапешт – бик матур кала. Анда баргач термаль комплексларны күрмичә китәргә ярамый. Бөтен ил буенча аларның саны 1300дән артык. XVI гасырдан, Төркия Венгриядә 150 ел кунак булган, Будапешт Госманлы империясенең Венгриядәге үзәге вазыйфасын башкарган чордан бирле эшләп килсәләр дә, бу бассейнлы мунчаларның күбесе яхшы хәлдә, заманча инфраструктуралы. Венгриядә әлегә кадәр төрек мәчете, төрек мунчалары, биналары – барысы да сакланган, барысы да хезмәт күрсәтә – кер дә рәхәтләнеп коен.

– Ә татарстанлылар Венгриягә еш йөриме?

– Визаларны бик күп бирәбез. Татарстанлылар Будапештны бик ярата. Әле Хевизга да баралар – анда вулкан кратерындагы күлдә хәтта кышын да ачык һавада су температурасы 25 градустан түбән төшми. Табигый термаль су файдалы үзлекләргә ия. Венгриядә теләсә кайсы авыру өчен җаның теләгән шифалы термаль суны табарга була.

– Венгриядән килгән дусларыгызны Татарстанда кая алып барыр идегез?

– Казанда дусларымны һәрвакыт Кремльгә дәшәм. Венгриядән килгән кешеләр Казаннан ни көтәргә, монда ни карарга икәнен бик төшенеп бетми. Күпләр Интернеттан фотолар карап, укыштырып, алдан әзерләнә, әмма үз күзләре белән күргәч, архитектурага, риваятьләргә, гомуми манзарага таң кала. Татар бистәсен күрсәтәм, консуллык тәрәзәсеннән ул искиткеч матур булып күренеп тора. Һичшиксез Зөя каласына алып барам. Венгрлар Раифаны да бик ярата. Бигрәк тә кышын Кач ману бәйрәменә туры килсәләр, шаккаталар! Аларның кышын бәкегә, бозлы суга чуму йоласы турында хәтта ишеткәннәре дә юк.

ҖИҢЕЛМӘҮ СЕРЕ

Әңгәмәбез шактый озак һәм кызыклы булып чыкты – гуляшка рәхмәт, ул пешсен өчен өч сәгатькә якын вакыт кирәк. Аның каравы гаҗәеп тәмле килеп чыга икән! Өстәвенә матур да – вак-вак чипеткеле – әллә чумар шунда, әллә умач белән. Гадәттә дипломатик сөйләшүләр алып барыла торган өстәлгә бик зур кәстрүл килеп кунаклый. Консуллык хезмәткәрләре табын җәя, аның уртасына Венгрия байрагы төсләрендәге тасма белән бәйләнгән зур ипекәйне тантаналы рәвештә чыгарып куялар. Ипекәйне Эрика кызы

1 Суган турыйбыз

2 Кишер уабыз

3 Сельдерей тамырын ваклыйбыз

4 Борыч турыйбыз

5 Ит турыйбыз

6 Бәрәңге турыйбыз

7 Камыр басабыз

8 Чипетке ясыйбыз

9 Суганны томалап пешерәбез

10 Кишер салабыз

11 Сельдерей өстибез

12 Ит салабыз

13 Борыч сибәбез

14 Су өстибез

15 Сарымсак өстибез

16 Чипетке салабыз

Ленке белән бергә үзенчәлекле мажар рецепты буенча, куаслы әчеткедә пешергән.

– Гуляшны ипи белән ашарга кирәк! – ди катгый итеп Генераль консул. – Һәм тагын шәраб та булырга тиеш. Мажар шәрабы – Венгриядә төшке һәм кичке ашларның аерылгысыз өлеше. Биредә андыйны тапмассың, чөнки ул бездә дә чикләнгән күләмдә генә җитештерелә. Чөнки Венгриянең һәр төбәгендә климат шартлары аерыла, һәркайсы виноградның үзенә ярашлы сортларын үстерә. Виноградның төрле сортларыннан төрле сорт шәраб килеп чыга – аларның ассортименты бик зур. Шуңа күрә, мәсәлән, Россия яки Кытайга җитәрлек күләмдә җитештерү өчен нинди дә булса бер сорт юк.

Һәр шәрабның үз риваяте бар. Менә монысы хакындагысы, мәсәлән, төрекләр белән бәйле. Мажарларны җиңә алмагач, алар ник шундый көчле һәм кыю икән, дип озак уйлаган төрекләр. Күзәтә торгач, ниндидер кызыл нәрсә эчкәннәрен күргәннәр. Мажарлар үгез каны эчә, шуңа күрә бер дә җиңелү белмиләр икән, дигән карарга килгәннәр. Шәрабның исеме дә шуннан килеп чыга – «Үгез каны». Эчеп җибәрәсез дә һич җиңелмәс, бирешмәс затка әйләнәсез! Т



Дорогие читатели журнала!

Надеюсь, что сегодняшний гуляш Вам понравился, и желаю, чтобы по рецепту успели его дома тоже приготовить!

Всем желаю крепкого здоровья, и надеюсь, что увидимся с Вами на наших мероприятиях, или в нашей чудесной Венгрии!

С наилучшими пожеланиями,

Адам Штифтер

Kedves Olvasók!

Remélem, hogy tetszett Önöknek mai receptünk, és kívánom, hogy sikerüljön a gulyást otthon is elkészíteniük!

Jó egészséget kívánok, és várom a következő találkozást, akár Magyarországon!

Stifter Ádám

ЭНИКС:
АШКЫНУЛЫ ТАРИХ

«ЭНИКС» АҖ ясаган җитештергән дөньякүләм дәрәҗәдәге пилотсыз очу аппаратлары Россиянең һәм Җир шарының төрле почмакларында уңышлы хезмәт итә. Өч йөз кешедән гыйбарәт бердәм һәм куәтле команда, пилотсыз очкычлар тармагында күп нәрсәдә беренче булып юл ярып, дөньяның андый очу аппаратлары җитештерә торган иң эре ширкәтләренә лаеклы көндәшлек тудыра.

Компаниянең фәнни-тикшеренү эшләре һәм аларның нәтиҗәләре пилотсыз очкычлар өлкәсендә иң актуаль адымнар һәм тәкъдимнәрдән гыйбарәт. Шул ук вакытта ЭНИКС – эшләп чыгарыла торган техниканың сызымнарын эшләүдән алып очкычка сервис хезмәте күрсәтүгә кадәр тулы цикллы җитештерүне тәэмин итә торган заманча предприятие ул.

КАИ тәмамлаган өметле егетләр үз предприятиесен инде бик күптән – 1980 нче елларда ук булдыра. Валерий Побежимов ул вакытта авиамоделизм түгәрәген җитәкли һәм яшь авиамодельчеләрне яңа фирмага чакыра. Россия Федерациясенең Оборона министрлыгы һәм көч структуралары аларның продукциясен төп кулланучылар булыр дип ул чакта уйлап карадылар микән? Бик шикле. Тик алар шәхси вакытлары белән дә, финанс кыенлыклары (андый проблемалар да була) белән дә исәпләшмичә, бөтенесе бер булып, предприятиене ничек тә күтәрергә тырыша. Айны йөгәнләрдәй колачлы хыяллар белән янган уйлап табучы-новаторларның барысын да бер уртак теләк берләштерә – нindидер принципиаль яңа нәрсә булдыру. Шушы нияттә компания 90 нчы еллар ахырында сәнәгать өлкәсендәге коточкыч авыр кризисны да, 2000 нче еллар башында предприятие үсешенең яңа чорын да кичерә. Нәтиҗәдә, бүген ЭНИКС – ватаныбызда төрле максатлардагы пилотсыз авиация комплексларын әзерләү, җитештерү һәм серияле эшләп чыгару тармагында иң алдынгыларныңдан берсе. Компания тәкъдим иткән инновацияле технологияләр Оборона министрлыгында кызыксыну уята.

Әүвәлгечә, Е95М мишене миллиардлаган сумлык товар әйләнешенә ия ширкәтнең иң күп сатыла торган эшләнмәсе булып тора.«Игла», «Панцирь» һәм һава һөҗүменнән саклануның күпләргә билгеле башка системалары нәкъ менә шуларга атып сынала. Компания үз дәверендә 900 дән артык мишень җитештергән. Моннан тыш, Россия хәрбиләре өчен бик күп сугышчыларыбызның гомерен саклап калырга мөмкинлек биргән 600 дән артык пилотсыз разведчик очкычлар эшләнгән.

Тел шартлатып куярлык шундый нәтиҗәләргә ирешүдә, элеккечә үк, кайчандыр «Кулибиннар бандасы» дип аталган төркем – предприятиенең төп нигезен тәшкил иткән хезмәткәрләрнең өлеше зур. Хәзер аларга яңа кан – креатив идеяләр белән янып торган яшь һәм өметле новаторлар кушыла. Компаниянең тагын бер горурлыгы – үз программа продукты: ул да ЭНИКС командасындагы тәҗрибә, белем һәм техник үҗәтлекнең файдалы хезмәттәшлеге нәтиҗәләреннән берсе.

14 ноябрьдә компания үзенең 33 еллыгын билгеләп үтә. Аның тарихы туры мәгънәсендә дә, күчерелмә мәгънәдә дә ашкынулы, кызу бара. Предприятиенең югары класслы белгечләре коллективына яңа идеяләр һәм мөһим эшләрендә уңышлар телибез!

Фото «ЭНИКС» АҖ тарафыннан бирелде. Реклама.

Мәңгелек кыйммәтләр

Мәңгелек кыйммәтләр

Игелекле эшләр

Акыллы гамәлләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Закир Кадыйри тарихта **НИНДИ** эз калдырган

НИ ӨЧЕН Кытай сәясәтенең аксакалы татар кешесе булган

Иске яңа мәчет **КАЙСЫ** авылда урнашкан

КОДРӘТ ҺӘМ ТҮЗЕМ ИЯСЕ ЗАКИР КАДЫЙРИ

Автор: Илдус Заһидуллин

XX гасыр башы татар җәмгыятендә яңарыш хәрәкәте идеологиясен формалаштыруда һәм аны тормышка ашыруда Көнчыгыш университетларында укыган, дөнья мәдәниятен яхшы белгән татар зыялылары төркеме мөһим роль уйный. Алар сәясәтчеләр, журналист, мөхәррир, язучы, галим, мөгаллим, тәрҗемәчеләр буларак танылa. Шундый яңа буын җәмәгать эшлеклеләреннән берсе – Закир Кадыйри.

БЕЛЕМ ЭСТӘҮ ЮЛЫНДА

Закир Кадыйри 1878 елның 2 сентябрендә элекке Самара губернасы Урта Кандал авылында (хәзерге Ульяновск өлкәсе Чардаклы районының Абдулла авылы) ата-бабалары буыннан-буынга муллалык итеп килгән Мөшфика абыстай һәм имам-хатыйб Мөхәммәтхәлим Кадыйровлар гаиләсендә дөньяга килә. Әтисе улына җитди дини белем бирергә омтыла һәм теләгенә ирешә. Күрше Иске Кандал башлангыч мәктәбеннән соң, мәхдүм укуын Сембер шәһәре мәдрәсәсендә дәвам итә. 16 яше тулгач, егет, әтисе киңәше белән, Бохарага юл тота һәм бирәдә биш ел гарәп, фарсы телләрен, ислам гыйлемен үзләштерә.

Бер Бохара баеның гозерен үтәп, аның исеменнән хаҗ кылырга бара, ләкин кире әйләнеп кайтмый: Истанбулдагы Якуб Мостафа исемендәге университетның дин факультетына укырга керә, беркадәр вакыттан соң Каһирәдәге «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә, аннары Әл-Әзһәр университетына күчеп, дини гыйлемен тирәнәйтә. Әйтергә кирәк, бу елларда әлеге уку йортында бер төркем татар яшьләре белем ала (М. Бигиев, З. Камали, Г. Лотфи, И. Камалов, Г. Баттал).

Каһирәдә студент Закирның тагын бер сыйфаты калку күренә. Егет, активлык күрсәтеп, 1900 елда чыга башлаган һәм колониализмга каршы көрәшне максат итеп куйган «Әл-Лива» («Байрак») газетасында актив языша, редакциясе белән якыннан аралаша. 1906 елда Россиядә ачлык башлангач, Закир ватандашларына ярдәм сорап берничә мәкалә бастыра. Каһирә мөселманнарыннан җыелган 4 мең сум иганә акчасын газета редакциясе Россиягә юллый.

МӨДӘРРИС ҺӘМ МӘГАРИФ ЭШЛЕКЛЕСЕ

12 ел дәвамында чит илләрдә белем туплаган Кадыйри туган иленә 1906 елда шәрык телләре, тарихы, әдәбияты һәм фәлсәфәсе буенча зур белгеч булып кайта. 27 яшьлек Закирны Риза Фәхретдин тәкъдиме белән «Хөсәения» мәдрәсәсенә мөдәррис итеп куялар. Киң эрудицияле Кадыйри бирәдә ике уку елы дәвамында шәкертләргә гарәп теле, әдәбияты һәм фикъһе буенча лекцияләр укый. Публицистик эчтәлекле язмаларын Санкт-Петербургта 1906–1907 елларда Г.Р. Ибраһимов нәшер иткән «Әт-Тилмиз» («Укучы») журналына юллый, шулай ук Оренбург шәһәрендәге «Вакыт» газетасында һәм 1908 елдан чыга башлаган «Шура» журналында, Уфада басылган «Әл-Галәми әл-Ислами»да урнаштыра.

1909–1912 елларда Закир Каһирәдәге Әл-Әзһәр университетында бергә укыган Зыя Камали Уфада оештырган «Галия» мәдрәсәсендә гарәп телен, Европа һәм ислам фәлсәфәсен, дин тарихын һәм мантыйк фәннәрен укыта. Шулай ук татар мәдрәсәләре өчен заманча дәреслекләр язу өлкәсендә

Фотолар автордан алынды

зур хезмәт куя. 1911 елда дөнья күргән «Хәяте Мөхәммәд галәйһи әс-сәлам. Тарих исламнан» китабында Мөхәммәд пәйгамбәрнең тормыш юлын тасвирлаудан, Коръәнне һәм хәдисләрне аңлатудан тыш, гарәп халкы, гарәп әдәбияты һәм фәне, дәүләт идарәсе, биредәге җәмгыятьнең исламгача тормыш-көнкүреше сурәтләнә. Гарәп теле укытудан тупланган тәҗрибәсе мөдәрриснең бүген дә методик яктан әһәмиятен югалтмаган «Гарәп нәхүе» («Гарәп теле синтаксисы», 1912) һәм «Гарәп сарыфы» («Гарәп теле морфологиясе», 1912) дип аталган уку әсбапларында чагылыш таба.

1916 елда ул Уфада яңа гына ачылган һәм башлангыч кызлар мәктәпләре мөгаллимәләре әзерләячәк хатын-кызлар семинариясендә ислам дине тарихын укыта.

Закир Кадыйри татар мәгарифен камилләштерү юллары хакында уйлана. Анынча, милли мәгариф Мәхкамәи шәргыя йогынтысыннан аерылган һәм дәүләт күзәтүеннән азат, татар телендә укыта торган һәм алдынгы Европа белем бирү кагыйдәләренә нигезләнгән, ярышка йөз тоткан белем бирү системасы булырга тиеш. Аның бу өлкәдә абруйлы белгеч булуы I Бөтенроссия мөселман съездының (1917 елның 1–11 май көннәре) Закир Кадыйрига мәгариф буенча резолюция төзүне ышанып тапшыруында чагылыш таба.

ЯҢА ФИКЕРЛӘР ТАРАТУЧЫ

Закир Кадыйри уку әсбаплары язуны һәм дөньякүләм танылган фикер ияләренең китапларын тәрҗемә итүне укымышлы, хөр фикерле яшьләр тәрбияләү концепциясенең нигезе дип карый. Моны ул максатчан рәвештә татар җәмгыятенә яңа идеяләр тарату һәм мәктәп-мәдрәсәләрдә укыту алымнарын камилләштерү аша башкарырга кирәк дип саный.

Кадыйри биш китаптан торган «Гаилә» сериясен эшли, аңа мөселман хатын-кызлары тормышын яхшыртуга юнәлдерелгән тәрҗемә эшләре керә. Шушы серия кысаларында ул Франциядә белем алган Мисыр галиме Касыймбәк Әминнең ике китабын тәрҗемә итә. Галимнең «Хатын-кызны азат итү» китабы нигезендә хатын-кызларга ир-атлар белән тигез хокуклар бирергә кирәк дигән өндәү ята. Бу авторның «Яңа хатын-кыз» хезмәтендә җенесләр арасындагы тигезсезлектә исламның катнашы, гаебе юк, дигән фикер уздырыла; китап кызларны яхшы белем алырга өнди.

Каһирәдә вакытта Кадыйри Европа иҗтимагый фикерен тирәнтен өйрәнә. Ул инглиз фәлсәфәчесе Герберт Спенсерның Англия һәм АКШтагы педагогик фикергә зур йогынты ясаган «Фәнни, әхлакый һәм физик тәрбия» исемле мәшһүр хезмәтен беркадәр кыскартып тәрҗемә итә. Шушы сериядә басылган 4 нче һәм 5 нче китапларны үзе яза: «Кызлар дөньясы» (1911) һәм «Хатын-кыз мәсьәләсе» (1915) дип атый.

«Кызлар дөньясы»нда автор, Коръән һәм хәдисләргә таянып, хәзерге җәмгыятьтә хатын-кызның тоткан урыны ислам тәгълиматында язылганга караганда күпкә кайтыш дип белдерә; белем һәм тәрбия, хатын-кызның гаиләдә һәм җәмгыятьтә тоткан урыны турында фикерләре белән уртаклаша. Хатын-кызның хәлен яхшы якка үзгәртүне Закир Кадыйри сыйфатлы белем биреп, әхлак кагыйдәләрен төгәлләштереп һәм дөрес гаилә моделен төзеп тормышка ашырмакчы була.

«Хатын-кыз мәсьәләсе» китапчыгын автор 1915 елда Уфада халык университетының мөселман бүлеге әгъзалары үтенече буенча хатын-кыз эмансипациясе турында укыган лекцияләре нигезендә әзерли. Анда хатын-кызларга сайлау хокукы бирү, табиб, укытучы һәм башка һөнәрләр үзләштерү өчен яңа уку йортлары ачарга кирәклек хакында сүз алып барыла.

Кадыйри тәрҗемә иткән тагын бер төркем хезмәтләр татарларга Коръәнне, хәдисләрне һәм, гомумән, ислам тәгълиматын яңача аңлатуны һәм милләттәшләрен ярышка алып баруны максат итеп куя. Ул гади халык арасында киң таралган, мөселманлык – ритуалларны вакытында һәм дөрес үтәүдән гыйбарәт, дигән караш белән килешми, фикерен ислам дөньясында танылган гыйлем ияләре хезмәтләре ярдәмендә дәлилли.

Кадыйри 1910 елда мөселман дөньясының ярыш идеологы Мөхәммәд Абдоның хәзерге цивилизациянең нигез баганаларын ихтыяр ирегe һәм акыл ирегe тәшкил итә дип белдергән хезмәтен «Гыйльме кәлям дәресләре» исемле уку әсбабы итеп бастыра. Әсбапка үзенең шәрех-аңлатмаларын да өсти. Шул рәвешле яшьләргә дин фәлсәфәсенә караган алдынгы фикерләрне җиткерергә омтыла.

Шушы ук елда Кадыйри шәкертләр өчен, төрек галиме З. Садыйкый һәм башка зыялыларның китапларын файдаланып, «Куәт һәм рух» исемле уку әсбабы язып бастыра. Анда да фәлсәфәчеләр һәм ислам галимнәренең тормыш-яшәешне аңлатуы урын таба. Автор ислам дине галимнәренең һәм дөньяви галимнәрнең карашларын (әйтик, Дарвинның Җирдә тереклек эволюциясе турындагы тәгълиматын) янәшә куеп, дин һәм фән позицияләрен ачыклый.

Тагын бер тәрҗемәсе – тарихчы Рафик бәк әл-Әзимнең «Тормыш һәм дин» исемле китабында исә сүз исламны заманча аңлау турында бара. Европа социалист, анархист, нигилистларының ислам турындагы фикерләрен мисалга китереп, Кадыйри мөселманнарның артта калу сәбәпләрен тарих күзлегеннән аңлатырга омтыла.

Тәрҗемә өчен Кадыйри татар дөньясына артык билгеле булмаган шәхесләрнең заманның актуаль мәсьәләләренә җавап эзләгән хезмәтләрен сайлый. Нәкъ менә шул мәсьәләләр XX гасыр башы татар җәмгыятен дә борчый, дулкынландыра. Әйтик, күренекле ислам фәлсәфәчесе

1
Закир Кадыйри (өченче рәттә, уңнан өченче) «Галия» мәдрәсәсе укытучылары һәм шәкертләре белән. Уфа ш., 1910–1911 нче уку елы.

Җәүһәрир Тәнтәвинең Кадыйри тәрҗемә иткән өч хезмәтендә исламның прогресска һәм европалашуга каршы килмәве, бер үк вакытта традицион кыйммәтләрне өйрәнү кирәклеге хакында сүз бара («Әт-тәҗел-мәсъриг» исемле трактат, «Низам вә ислам» (1911), «Ислам, галимнәр, фәкыйх вә ишаннар вә ганҗәләремез» (1908)). Аның фамилиядәше, Әл-Әзһәр университеты галиме, 1840–1861 елларда Санкт-Петербург университетында эшләгән профессор Мөхәммәд эт-Тәнтәвинең гарәпчәдән тәрҗемә ителгән «Илле ике җәүһәр» хезмәте ислам мәдәниятенә багышланган. Шулай ук замандашы, гарәп фикер иясе Җөрҗи Зәйданның ислам дөньясында бик популяр булган «Ислам мәдәнияте тарихы» хезмәтен дә татар җәмәгатьчелеге игътибарына Кадыйри тәкъдим итә (Уфа, 1913). Аерып алып, аның русча тәрҗемәсендә хаталар булганлыкны, мөселманнарга карата ялган гаепләүләр килеп чыкканны күрсәтеп уза.

Кадыйриның тирән белеменә таянып эшләгән тәрҗемәләре XX гасыр башы татар мәгърифәтчеләренең халыкка алдынгы фикерләр һәм белемнәр тарату омтылышына тәңгәл була. Шушы юл белән зыялылар татар милләтенең иҗтимагый аңына тәэсир итәргә һәм заманча белемле яңа шәхес тәрбияләргә теләгән. XX гасыр башының милли-мәдәни күтәрелеше аларның бу кузаллаулары дөрес булганлыкны күрсәтә.

МӨХӘРРИР ҺӘМ СӘЯСӘТЧЕ

Утыз меңнән артык мөселман яшәгән губерна шәһәрендә татарча басма булмау үзен нык сиздерә. Шушы хакта уйланып, 1912 елда Кадыйри хакимияткә Уфада газета бастырырга рөхсәт сорап мөрәҗәгать итеп карый. Ләкин Россиягә кайтканнан бирле полиция күзәтүе шартларында яшәгән шәхескә хакимият уңай җавап бирми.

1913 елда Томск шәһәрендә нәшер ителгән «Сибирия» газетасы редакторы Мөхәммәтвәгыйзь Нәүрүзов белән Уфа каласы җәмәгать эшлеклеләре арасында бу матбугат чарасын яңа урынга күчерү турында сөйләшү була. Килешенгәнчә, рөхсәт алгач, газета «Тормыш» исеме белән Нәүрүзов редакторлыгында атнага өч тапкыр басыла башлый. 1914 елның көзендә газета Стәрлетамак шәһәре сәүдәгәре Гыйбадулла Госманов кулына күчә, 5 октябрь саныннан «Тормыш»ны Закир Кадыйри нәшер итә башлый. Зур форматтагы газета атнага алты тапкыр басыла, озак та үтми, «Вакыт» һәм «Кояш» кебек бик популяр матбугат органына әверелә.

Яңа редактор газетаның төп девизы итеп алдынгы «мәдәни милләт» төзүне куя. Шул ук вакытта матбугат чарасының элекке программасы белән дә дәвамлылык саклана: газета битләрендә яңа кануннар, социаль һәм сәяси яңалыклар, әдәбият, икътисад, әхлак темалары, ил халыкларының тормыш-көнкүреше, хатын-кыз мәсьәләсе, Россиядәге, дөньядагы һәм мөселман илләрендәге яңалыклар, Мәхкәмәи шәргыя һәм земство хәбәрләре, авыл тормышы, мәктәп һәм мәдрәсәләр, мөгаллимнәр һ.б. темалар күтәрелә. 1914 елның июль аенда Беренче бөтендөнья сугышы башлангач, басмада фронт хәлләре, халыкның тормышы начараюы, иганәчелекне арттыру кирәклеге турында һ.б. яңа темалар пәйда була.

Газетада татар җәмгыятендә әле борынлый гына башлаган, рус дөньясында зур бәхәсләр уяткан мәдәни күренешләр дә фикерләшү-бәхәсләшү предметына әйләнә. Мөхәррир үзе милләт төзелешен, динне һәм иҗтимагый тормышны үзәккә куеп яза. Шул рәвешле «Тормыш» газетасы Кадыйрины сәясәтчегә әверелдерә.

IV Дәүләт Думасында мөселман фракциясен тәшкил иткән 6 депутатның өчесе Уфа губернасыннан сайланган була. «Тормыш» битләрендә аларның чыгышлары һәм Дума эшчәнлеге даими яктыртылып килә. 1915 елда депутатлар фракциясе вәкилләре, хөкүмәткә теләктәшлек күрсәтеп, Прогрессив блокка берләшә. 1916 елның февралендә, мөселман фракциясе җитәкчесе Котлымөхәммәд Тәфкилев тәкъдиме белән, Прогрессив блокка мөселманнарның мөнәсәбәтен ачыклар өчен киңәшмә оештырыла. Бу киңәшмәдә Закир Кадыйри да катнаша, анда мөселман фракциясе каршында бюро оештыру турында һәм элекке «Иттифак әл-мөслимин» партиясенең программасы фракциянең сәяси платформасы булырга тиеш, дигән карар кабул ителә.

Кадыйри 1917 елгы Февраль инкыйлабыннан соң «Тормыш»та «Мәмләкәт идарәсе рәвешләре» исемле публицистик хезмәтен бастыра, бүгенге Россия өчен иң кулай идарә формасы – федератив республика дигән нәтиҗә ясый.

1917 елның 22 ноябрендә Уфада Эчке Русия һәм Себер төрки-татарларының парламенты – Милләт мәҗлесе ачыла. 1918 елның гыйнвар аенда Милләт мәҗлесе башкарма

органы – Милли идарә һәм аның дин, мәгариф һәм финанс нәзарәтләре оеша. Мәгариф нәзарәтенә сайланган Закир Кадыйри, «Тормыш»та редакторлык вазыйфасын калдырып, оештыру эшләренә чума. Ләкин 1918 елның апрелендә большевиклар Милләт мәҗлесен һәм Милли идарәне тарката. Аның әгъзалары Кызыл Яр шәһәренә качып китәргә мәҗбүр була.

КАДЫЙРИНЫҢ ЭМИГРАЦИЯДӘГЕ ТОРМЫШЫ

1917 елда 39 яшьлек Закир Кадыйри һәм 16 яшьлек татар шагыйрәсе Сания Гыйффәт гаилә кора. Чистай шәһәрендә сәүдәгәр гаиләсендә туган Сания Хәбирҗан кызы 12 яшеннән шигырьләр яза, мөгаллимә булып эшли. «Тормыш»та актив язышa. Озак та үтми, яшь гаиләдә бер-бер артлы кызлары – Азад һәм Ләлә туа.

Себердә совет хакимияте урнашкач, Закир Кадыйри гаиләсе белән Кытайга барып сыена, күченә-күченә Күлҗә, Пекин, Хайлар шәһәрләрендә яши. Хайларда хатынын башлангыч мәктәптә укытырга калдырып, үзе 1922 елда Төркия Республикасына бара, дәүләттә Ататөрек башлаган үзгәрешләр белән таныша. 1925 елда аның дусты Хәмдуллах Сөбхи Төркиянең мәгариф министры итеп билгеләнә. Ул Кадыйрины Истанбулда Төрки дөньяны өйрәнү институты төзергә чакыра. Кадыйри Мәгариф министрлыгы каршындагы Тәрҗемә комиссиясендә эшли башлый. Комиссия ябылгач, Истанбулдагы Сөләймания мәчете китапханәсенә өлкән китапханәче булып урнаша.

1930 елда булачак Тарих җәмгыятенең 16 кеше (шул исәптән Закир Кадыйри) катнашында Үзәк комитеты җыела. 1932 елда Төркиянең беренче Тарих конгрессы утырышы була. Анда иң мөһим максат итеп Төркия тарихын өйрәнү бурычы куела. Тарих җәмгыятендә Кадыйрига рецензент вазыйфасы йөкләнә. Турысын әйтергә яраткан Кадыйри, «Төрек тарихының төп юнәлешләре» исемле дәреслек кульъязмасына биргән кискен тәнкыйтьтән соң, республика җитәкчелегенең ышанычын югалта, чөнки ул текстның авторы Төркия Президенты Ататөрек булып чыга. Эшсез калгач, рус һәм Көнчыгыш телләрендә язылган фәнни хезмәтләрне төрекчәгә тәрҗемә итү белән шөгыльләнеп көн күрә.

1934 елгы Төркия гражданына яңа фамилия алу мәҗбүрилеге турындагы канунга буйсынып, Кадыйри үзенә Уган тәхәллүсен ала. Рифкать Әхмәтьянов аңлатуынча, борынгы төрки телдә Уган «кодрәтле һәм түземле булу» дигәнне аңлата.

1936 елда Закир Кадыйрины Финляндиядә яшәүче татарлар үзләренә чакыра. Биредә Кадыйри беркадәр вакыт Хельсинки университетының Көнчыгыш телләр факультетында эшли, «Татарлар һәм төрекләр тарихы дәресләре» исемле китап яза. Галим шәһәр татар җәмгыяте тормышында актив катнаша. Хатыны Сания Гыйффәт балалар укыта. Ләкин 1939 елда совет-фин сугышы башлангач, Кадыйри гаиләсе белән кабат Төркиягә күченә.

Бик кызганыч, Төркиядә Кадыйрига гыйльми дәрәҗәсе туры килә торган эш табылмый, ул мәктәпкә укытучы булып та урнаша алмый. Аның фәнни потенциалы С.Максуди, Й.Акчура, Ә.Нигъмәт Курат, А.Инан, З.Вәлиди, Г.Баттал-Таймас дәрәҗәсендә Төркиянең социаль һәм мәдәни үсешендә зур роль уйнамый. Ул төрки халыкларның тарихы, мәдәнияте, теле, этнографиясе, этник үзенчәлекләренә караган хезмәтләр яза, аларны журналларда бастыра. Әмма аңа фән белән тирәнтен шөгыльләнү өчен мөмкинлекләр-юллар ябылган була. Кадыйри нигездә дөньякүләм танылган галимнәрнең хезмәтләрен гарәп, фарсы һәм рус телләреннән тәрҗемә итеп, яңа белемнәрне һәм фикерләрне дөньяви булып килүче төрек җәмгыятенә җиткерүдә нәтиҗәле эшли. Алар арасында иң мәшһүре – Ибне Халдунның өч томлык «Зур тарихы»на язылган «Мөкаддимә»се.

Кадыйриларның олы кызлары Азад күренекле төрек тарихчысы, милләттәшебез Әхмәт Тимергә кияүгә чыга. Кадыйри, кияве белән хезмәттәшлек итеп, урта гасыр галиме эт-Табәринең биш томлык «Халыклар һәм хакимнәр тарихы» исемле хезмәтен төрекчә әзерли. Шулай ук русчадан А.Крымскийның өч томлык «Гарәп әдәбияты тарихы»н тәрҗемә кыла.

Закир Кадыйри 1954 елның 22 октябрендә Әнкарада вафат була. Күренекле фикер иясе, дин белгече, гарәп телчесе, мөгаллим, тәрҗемәче, тарихчы, журналист-милләтпәрвәр Закир Кадыйри исеме татар дөньясына XX–XXI гасырлар чигендә әйләнеп кайта. Төркиядә аны нигездә тәрҗемәче буларак беләләр.

2 Закир Кадыйри (икенче рәттә, уртада) һәм Сания Гыйффәт укучылар белән. Финляндия, Терийокки ш., 1936 ел.

НИЯЗ ӘХМӘДУЛЛИННЫҢ

МИЛЛИАРД ТАТАРЫ



СӘЯСӘТ АКСАКАЛЫ БОРҺАН ШАҺИДИ

Автор:
Нияз Әхмәдуллин

1994 елда Кытай югары җитәкчелеге Пекинда зур җыелыш үткәрә. Күкасты иле җитәкчеләре анда бары тик бер кеше турында сөйләшә. Ни гаҗәп, әмма кытай сәясәтенең әлеге аксакалы милләте буенча кытай булмый.

Территориясендә 11 миллион уйгур, шулай ук башка төрки телле халыклар яшәгән Синьцзян-Уйгур төбәген 1949 елда Кытай Халык Республикасы составына кертүне оештырган кеше хакында сүз бара. Кытай сәясәтенең әлеге татар чыгышлы иләмәненең исеме Борһан Шаһидуллин, яки Борһан Шаһиди (кытайча Бо Ер Хан яки Бао Эрхань дип әйтелгән) була.

ШӘРЫККА ЮЛ

1912 елда Синьцзян провинциясе башкаласы Өремче шәһәрендә татар сәүдәгәрләре Җаббаровлар компаниясенең яңа хезмәткәре – Борһан исемле унҗиде яшьлек егет пәйда була.

Гади татар гаиләсеннән чыккан яшь егет татар һәм рус сәүдәгәрләре инде күптәннән үз кеше булган шулкадәр ерак җиргә ничек барып эләккән соң? Борһан Шаһиди бу турыда үзе болай яза: «Мин 1894 елның 3 октябрендә Казан губернасы Тәтеш өязе Аксу авылында туганмын. Гобәйдулла бабам сөйләве буенча, борынгы уйгур бабаларым ерак Кытайда, Аксу елгасы ярында яшәгән». Бүген Шаһидинең туган авылы Татарстанның Буа районына керә.

Ундүрт яшьлек үсмер Казанга килә. Үзләренең зур хосусый нәшрияты булган туганнары биредә аны китап кибетенә сатучы итеп урнаштыра. Борһан эшли дә, шул ук вакытта Казанның атаклы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә дә укый.

Тагын өч елдан соң зиһенле, төпле егетне Түбән Новгород ярминкәсендә Семипалатинск сәүдәгәре Исмәгыйль Җаббаров күреп ала. Әлеге очрашу Борһанның тормышын тамырдан үзгәртәчәк. Сәүдәгәр аңа Кытай белән арадашчы булган «Тянь-Шань» сәүдә компаниясендә эш тәкъдим итә. Озак уйлап тормыйча, Борһан ризалаша һәм күп тә үтми Синьцзян провинциясенә – үзенең борынгы бабалары ватанына барып җитә.

КҮЗГӘ КҮРЕНМӘС ФРОНТ СУГЫШЧЫСЫМЫ?

Шаһидинең Кытайда беренче еллардагы эше коммерция белән бәйле. Ул кытай, рус, уйгур, татар эшкуарлары арасында эшлекле һәм дустанә мөнәсәбәтләр урнаштыра. 1920 нче еллар башында аны дәүләт хезмәтенә чакыралар. Таможняда, Синьцзян транспорт идарәсендә эшли. Бер үк вакытта ул Синьцзян генерал-губернаторы ярдәмчесе һәм тәрҗемәчесе дә була (Борһан татар, уйгур, кытай, рус телләрен камил белгән, соңрак немец телен дә үзләштергән). Аңа Германиядә техник товарлар сатып алуны йөклиләр, һәм ул берничә тапкыр Европага бара.

Бу чорда Борһан Шаһидинең Советлар Союзы белән хезмәттәшлеге сәүдә сферасында гына булмаган күрәсең. Үзенең совет разведкасы белән тыгыз элемтәсе хакында Шаһиди соңрак үзе яза. Ул 1920–1930 нче елларда Германиядә һәм Советлар Союзында еш булуын, Мәскәү һәм Казанда тукталуын искә ала. Хәтта Казаннан Синьцзянга кайбер туганнарын да алып китә. Кытай ватандашының Совет Россиясе буйлап шулай иркен күчеп йөрүен, хәтта үзенең шәхси мәсьәләләрен дә хәл итүен хакимият химаясеннән башка күз алдына китерүе дә кыен.

1929-1933 елларда Борһан Шаһиди, Синьцзян хөкүмәтенең Германиядәге сәүдә вәкиле вазыйфасын башкаруы белән берргәттән, Берлин университетында да укый һәм аны тәмамлый. Әлеге фактны соңрак аны гаепләү өчен файдаланачаклар, немец шпионы итеп игълан итәчәкләр. 1937 елда Борһан Шаһиди Кытайның СССРдагы консулы (чик буендагы Зайсан шәһәрендә) итеп билгеләнә.

МАОГА МӘДХИЯ

1934 елда Синьцзянда уйгурлар Кытай хакимиятенә каршы баш күтәрә, биредә кыска вакытка булса да Көнчыгыш Төркестан ислам республикасы төзелә. Аны көч белән буйсындырганнан соң Синьцзянда хакимияткә, Советлар Союзы ярдәмендә, Шэн Шицай исемле кеше утыртыла, баштарак ул социалист, СССРның дусты булып кылана.

Шаһиди үз истәлекләрендә, Синьцзянда Шэн Шицай өчен яшерен хезмәтләр булдыруда, Мәскәүдән килгән совет инструкторлары белән бергә, шәхсән үзенең дә катнашуын яза. Ул үзенең совет дипломатлары һәм НКВД хезмәткәрләре белән еш очрашуын искә ала.

Әлбәттә, нәкъ менә шул вакытта кемнең кемне һәм ничек файдалануы хакында сораулар туа. Ихтимал, билгеле бер мизгелдә Шаһиди, аларга буйсынудан туктап, мөстәкыйльлек күрсәтә башлагандыр. Һәм совет разведкасына да, Синьцзянныкына да кирәге калмагандыр. Шэн Шицай аны Германия һәм Япония файдасына шпионажда гаепли һәм үтерергә куша. Шаһиди алты ел төрмәдә утыра, әмма могҗиза белән исән кала.

Борһан Шаһиди төрмәдә дә вакытын бушка әрәм итми. Бик энергияле кеше булганга, үзенә шөгыльләр таба: өч телле уйгур-рус-кытай сүзлеген төзи, Мао Цзедунга багышланган шигырьләр иҗат итә.

«Сез хакыйкатькә һәм бәйсезлеккә, эшчеләр өчен бәхеткә юл ачтыгыз... Мин – Сез кабызган йолдыз», – дип яза Шаһиди.

Нәрсә бу: тиңдәшсез сизгерлекме, киләчәкне күрә белү сәләтеме?Ә бәлки, коммунизм идеяләренә ихластан ышанудыр? Тик шунысын төгәл әйтергә мөмкин: Шаһиди шигырен нәкъ менә кирәкле кешегә багышлаган булып чыга.

МӘСКӘҮ ГАФУ СОРЫЙ

1944 елда Шэн Шицай бәреп төшерелгәннән соң Шаһиди иреккә чыга һәм шундук Өремче шәһәре мэры итеп билгеләнә. Берничә көн үтүгә үк аның өенә Мәскәүдән кунак килә һәм совет хөкүмәте исеменнән рәсми гафу үтенә – янәсе, Синьцзян губернаторының иминлек буенча киңәшчесе, совет кешесе, аңа ялган гаеп

Кытай компартиясе җитәкчелегенең очрашуы (июнь, 1950 нче еллар). Уртада – Мао Цзэдун, аңардан унда – Борһан Шаһиди, Чжоу Эньлай.

«Тәнкыйтьне кабул итү».

таккан, шул яла аркасында Борһан Шаһидигә җәзаланырга туры килгән.

Совет хакимиятенең сәясәткә кире әйләнеп кайткан Шаһидигә шундый игътибарлы мөнәсәбәте Синьцзянда һаман активлаша барган нindидер катлаулы сәяси уенда аңа билгеле бер бурыч йөкләнүен фаразларга мөмкинлек бирә.

СУГЫШЫРГА ЯРАМЫЙ: ШАҺИДИ КУЙГАН «ӨТЕР»

1948 елда Чан Кайши Борһан Шаһидине Синьцзян коалицион хөкүмәте рәисе итеп билгели. Һәм (!) төбәктәге иң мөһим вакыйгалар нәкъ менә шул чакта була. 1949 елда Чан Кайшига буйсынган гоминьдан гаскәрләрен коммунистлар җиңелү артыннан җиңелүгә дучар итә. Гражданнар сугышында Кытай компартиясенең җиңәчәге шик тудырмый. Синьцзян территориясенең бер өлешендә төзелгән икенче Көнчыгыш Төркестан республикасы тирәсендә вазгыять катлаулана бара.

Шул чакта Борһан Шаһиди Мао Цзедунга телеграмма җибәрә һәм Синьцзянның, Чан Кайшига буйсынудан туктап, яңа Кытай республикасы составына керергә әзерлеген хәбәр итә.

Борһан Шаһиди җитәкчелегендәге Синьцзян хөкүмәтенең әлеге карары ул чакта да Көнчыгыш Төркестан бәйсезлеге тарафдарларының кискен канәгатьсезлеген тудыра һәм уйгур оппозициясе тарафыннан бүген дә тәнкыйтьләнә. Синьцзянны коммунистларга бирү Көнчыгыш Төркестан республикасы халыкларына каршы хыянәт буларак бәяләнә.

Әмма мондый нәтиҗә ясарга ашыкмау мөһим. Ул мизгелдә Борһан Шаһиди кем мәнфәгатьләрен кайгыртса да, аның сайлау мөмкинлеге булмый. Теләсә нинди каршылык күрсәтелгән очракта, Синьцзянга таба Кытайның өч миллионлык халык-азатлык армиясе юнәлергә әзер тора. Синьцзянның үзендә барлыгы 100 мең тирәсе гоминьдан кылычы исәпләнә. Көнчыгыш Төркестанда исә 10 мең солдат була. Сугыш башланса, аның кырылып бетәчәге көн кебек ачык. Соңрак Шаһиди үзе язганча, бу карар бик күп тыныч халыкның гомерен саклап калырга булышкан. Моның белән бәхәсләшүе кыен.

ДИПЛОМАТИЯ МОГҖИЗАЛАРЫ

1949 елның 1 октябрендә Пекинда Кытай Халык Республикасы игълан ителә, ә 20 октябрьдә кытай армиясе Өремче шәһәренә килеп тә җитә. Кытайның яңа җитәкчелеге Борһан Шаһидинең күрсәткән хезмәтләрен югары бәяли.

1953 елда Шаһиди Кытай Ислам ассоциациясен төзүчеләрдән берсе һәм аның беренче рәисе була. Аның Кытай мөселман бергәлеге үзәк хакимият сәясәте тирәсендә берләштерүдәге активлыгы күзгә бәрелеп тора, яңа Кытай республикасы файдасына тырышлыгы да онытылмаслык була.

1955 елда Борһан Шаһидине Пекинга чакырып алалар һәм Бөтенкытай сәяси консультатив советы рәисе урынбасары итеп сайлыйлар. Әлеге органны Кытай премьер-министры, тышкы эшләр министры Чжоу Эньлай җитәкли. Бу – Шаһидинең кытай сәяси Олимпындагы карьерасының иң югары ноктасы.

Чжоу Эньлай кушуы буенча Шаһиди халыкара дипломатиягә муеннан чума. Яңа Кытай республикасы каршында бик катлаулы – халыкара танылуга ирешү бурычы тора. Тик чит илләр ашыкмый. Ислам дөньясына «тәрәзә уюны» Борһан Шаһидигә тапшыралар. Диндәшләре белән дипломатик мөнәсәбәтләр

Мао Цзэдун һәм Борһан Шаһиди.

урнаштыру хакында килешү төзергә үзе этник төрки һәм мөселман булган Шаһидидән башка тагын кемнең хәленнән килсен соң? Ул бу эшкә алына һәм аны бик яхшы башкарып чыга.

Якын Көнчыгыш илләренә сәфәре вакытында ул Мисыр, Сүрия, Йәмән кебек ислам дәүләтләре белән илчеләр алмашу хакында килешү төзүгә ирешә. Борһан Шаһиди Согыд Гарәбстаны, Ливан, Иордания, Эфиопия, Судан җитәкчелеге белән Кытай өчен бик мөһим сөйләшүләр үткәрә. Боз кузгала. Кытай җитәкчелегенең өмете аклана, Шаһиди сынатмый. 1950 еллар азагында Борһан Шаһиди кытай делегациясе составында Мәскәүдә СССР башлыгы Никита Хрущев белән очраша.

«РЕВОЛЮЦИЯ» КОРБАНЫ

Аннан соң исә аның язмышына илне хаоска батырган мәдәни революция бәреп керә. 1966 елда Цзедун ил җитәкчелегендә ныгыган, Маоның көчәя барган шәхес культын таныргa теләмәгән, аны икътисадый уңышсызлыкларда шәхсән җаваплы санаган оппозициягә һөҗүмен башлый.

1966 елның августында Мао Цзедунны яклаучы хунвейбиннар һәм цзаофаньнәр (студент һәм эшче яшьләр) отрядлары формалаша, алар илнең сәяси, икътисадый, мәдәни элитасын рәхимсез җәберләү-җәзалау белән шөгыльләнә.

1960 нчы еллар уртасында Шаһидигә дә яла ягалар. Аны бөтен вазыйфаларыннан мәхрүм итәләр. Түбәнсетү, мәсхәрәләү башлана. 1966 елның җәендә йортына хунвейбиннар бәреп керә. Янәсе, Шаһидине хыянәттә гаепли торган документлар эзлиләр, тик бернәрсә дә тапмыйлар. Җәзасызлыктан оятын югалткан ертлачлар, сәясәтченең мөлкәтен һәм архивын талап, дәлилләр тапмыйча, Шаһидине тәнкыйть кабул итүгә мәҗбүриләр. Бөтен халык каршында мыскыллау процедурасы шулай аталган. Хунвейбиннар Шаһиди йортына «бирedә халыкара шпион гаиләсе яши» дигән язу элеп калдыра.

Бер елдан соң җитмеш яшьлек картны аерым камерага ябалар, ул шунда сигез ел утыра. Бердәнбер өмете һәм таянычы хатыны Рәшидә була. Ул аңа кирәкле әйберләрен китерә, китап-журналлар җибәреп тора.

БУ – КЫТАЙ!

Аны 1975 елның җәендә, мәдәни революция тәмамланып килгәндә генә азат итәләр. Төрмәдән Шаһиди инде сәламәтлеге шактый таушалган сиксән яшьлек карт булып чыга. Бу яшьтә киләчәктән нәрсә көтәргә мөмкин? Тик бу – Кытай, һәм безнең героебыз да гадәти кеше түгел.

Тагын берничә елдан Борһан Шаһиди зур сәясәткә кабат әйләнеп кайта. 1978 елда Кытай Сәяси консультатив советын Дэн Сяопин җитәкли. Илнең яңа лидерының икътисадый реформалары Күкасты илен тиз арада ныклап аякка бастыра. 1980 елда Шаһиди тулысынча аклана һәм Дэн Сяопинның урынбасары, шулай ук Кытай Коституциясенә төзәтмәләр кертү комиссиясе әгъзасы итеп сайлана.

Дэн Сяопин – илнең яңа лидерының икътисадый реформалары Күкасты илен тиз арада ныклап аякка бастыра.

Конституция комиссиясендә эшләү Шаһиди өчен формальлек кенә булмый. Ул милли азчылык хокукларын яклый, Кытайдагы аз санлы милләтләр яшәгән территорияләрнең вәкаләтләрен киңәйтүне кайгырта. Билгеле инде, шул исәптән уйгурларның мәнфәгатьләрен дә яклау белән шөгыльләнә. Дин тоту ирege яклы була. 1984 елда Борһан Шаһидинең «Синьцзянда 50 ел гомер» дигән истәлекләр китабы дөнья күрә. Тәҗрибәле сәясәтче, өлкән яшьтә булса да, үзенең активлыгы, яхшы хәтере, зиһене белән таң калдыра.

Әмма картаю барыбер үзен сиздерә, һәм 1988 елда 93 яшьлек Борһан Шаһиди отставкага чыга. Тяньаньмэнь мәйданындагы вакыйгалардан соң озак та үтми, ул 1989 елның 27 августында вафат була. Мәрхүм белән хушлашырга Кытайның бөтен югары җитәкчелеге, шул исәптән Коммунистлар партиясе генераль секретаре Цзян Цзэминь, КХР рәисе Ян Шанкунь һәм башка абруйлы түрәләр килә.

ҮЗ КЕШЕ

Кытайларда «лаовай» сүзе бар, ул чит ил кешесе, чит дигәнне аңлата. Кытай телен, кытай мәдәниятен һәм гореф-гадәтләрен белмәүчене бераз кимсетеп әйтелә. Ә менә Борһан Шаһиди – кытайлар үзләренеке санаган бик аз санлы чит ил кешеләреннән берсе, бәлки әле бердәнбере дәдер. Кытайлар аның дәүләт файдасына хезмәтләрен бик югары бәяли.

МОРТЫШТАМАК АВЫЛЫ МУЗЕЕ: «БЕЗДӘ КИРӘКСЕЗ ӘЙБЕР ЮК»

Автор: Руфия Фазылова

«Татарстан» журналы музейлар турында күп язды. Әдәбият, тарих, сәнгать, нефть, техника өлкәсе – кайсыларында гына булмадык. Инде бу темага нокта куярбыз диган идек. Тик Сарман районының Мортыштамак авылы музеен читләтеп узып булмады, чөнки бик үзенчәлекле ул.

КҮЛМӘК КЕНӘ ДИМӘГЕЗ

Мортыштамак туган якны өйрәнү музее рәсми рәвештә 1990 елның 1 сентябрендә ачылган. Ул тарихның үзе кебек – еллар узган саен зурая бара. Бүген бирedә дүрт зал бар. Беренче игътибарны җәлеп иткәне – Мортыштамак мәдәният йортына кереп, кайсы ишекне ачып карасаң да, музейга юлыгасың. Мортыштамак мәдәният үзәге үзе 1978 елда ачылган. Шул зур вакыйгага дип, махсус милли концерт күлмәкләре тектерелгән була. Еллар узу белән әлеге күлмәкләр

Фото: Александр Ефремов

искергән. Гадәттә кулланылыштан чыккан андый кием-салымны ташлыйлар. Ә биредә исә һәркайсын юып, ремонтлап, стеналарга элеп куйганнар. Музыка уен кораллары да шунда тора. Шулай итеп, музейның беренче залы барлыкка килгән. Мәдәният йортында куелган спектакль, концертлардан күренешләр... Кыскасы, биредә авылның мәдәни тарихы тупланган.

Музей җитәкчесе Миләүшә Җәлилова белән икенче залга узабыз. Монысы инде заманча итеп ясалган. 2017 елда музей хезмәткәрләре, «Татнефть» оештырган конкурста катнашып, грант откан. Шушы акчага әлеге залны ачканнар. Биредә Мортыштамакның иң дәрәҗәле кешеләре турында төрле мәгълүмат табарга була. Ә алар авылда шактый күп. Мортыштамакта биш Ленин ордены кавалеры, Социалистик Хезмәт Геройлары бар. Язучы, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе иясе Мәдинә Маликова да Мортыштамактан. Музейда язучы ханымның шәхесен яктырткан махсус заманча стенд эшләнгән.

– Бер генә хезмәт иясен дә игътибарсыз калдырмаска тырыштык, – ди Миләүшә Җәлилова. – Алдынгы сыер савучы яки колхоз рәисе булсынмы, мәктәп, авыл җирлеге идарәсе белгечләре – барысы турында да кызыклы мәгълүмат бар. Безнең җирлектә үсүче балалар бәхетле дип саныйм – ата-бабаларының нәрсә белән шөгыльләнгәнен кечкенәдән күреп үсәләр. Алар өчен даими рәвештә төрле чаралар үткәрәбез.

Мортыштамакта революциягә кадәр өч мәчет булган. Мәдрәсә, кызлар мәктәбе эшләгән. Ләкин совет власте килгәннән соң, алар барысы да юкка чыккан. Бүген мәнә алар турында шул музейдагы сурәтләрдән генә күреп була.

ТАБЫЛГАН АКЧАЛАР

Күп авылларда музейлар бар бүген. Һичьюгы музей почмаклары булса да эшләп куйганнар. Мортыштамакта да ул шулай башланган эш. Бу очракта аерым бер кеше – Фәнүзә Салихованың тырышлыгы, үҗәтлеге белән почмактан аерым бер бүлмәгә, аннан икенчесенә, өченчесенә, дүртенчесенә күчкән ул.

– Музей ачылганда «Үрнәк» колхозы яши иде, – дип сөйли Фәнүзә Салихова. – Миллионер колхозыбызның исеме бөтен республикага билгеле чаклар. Менә шул вакытта колхоз рәисе Ильяс Гыйльфанов 17 мең сум акча күчерде. Ул заман өчен күп акча инде бу, бер «Жигули» машинасы алырлык. Ильяс Вилдан улына хәзер дә рәхмәт әйтәбез, авыл өчен зур бүләк булды. Музейны бөтен таләпләренә туры килерлек итеп ясарга кирәк иде. Тик бит теләсә кем аны эшли алмый, пыялалы киштәләрне ясарга, дөрес итеп урнаштырырга кирәк. Бигрәк тә ул заманда. Шуңа да андый белгечләрне авырлык белән таптык. Алар рус кешеләре иде.

1
– Татарстан буенча эзләсәң, башка бер генә музейда да кояш сәгате очрата алмыйсың, – ди Фәнүзә Салихова.

2 3
Музейдагы үзенчәлекле экспонатлар.

Һәр экспонатка татарча яздырып, хаталарны төзәтеп, шактый эшләргә туры килде.

Биредә эшләүчеләр әйтүенчә, Сарман туган якны өйрәнү музеенда да моның кадәр экспонат юк икән. Мортыштамак туган якны өйрәнү музее 1993 елда Татарстан милли музее филиалы итеп теркәлә, Россия музейлар каталогына кертелә. Бүген исә ул Сарман туган якны өйрәнү музеена карый, гәрчә аннан алданрак оештырылса да.

Музей булдыру турында хыялланып йөргән ул мәлдә гаҗәп хәл була. Иске мәчет бинасын сүткәндә, стена арасыннан бер төргәк иске акча килеп чыга. Мәчетләрнең узган гасырның егерменче елларында халыкка хезмәт итүдән туктаганлыгын исәпкә алсак, әлеге акчалар, ким дигәндә, бер гасыр элек яшерелгән дигән сүз. Ә бүген алар – музейның кадерле ядкәре.

Тагын бер үзенчәлекле экспонат – кояш сәгате. Агачтан ясалган бу предмет бүгенге көннәргә кадәр бик сирәк сакланып калган.

– Татарстан буенча эзләсәң, башка бер генә музейда да кояш сәгате очрата алмыйсың, – ди Фәнүзә Салихова. – Бу сәгать исә безнең мәчет ишегалдында торган. Унҗиде-унсигезенче гасырларда эшләнгән дип уйлыйбыз. Күләгә кайсы санга төшә, шуннан вакытны белгәннәр.

Сәгать белән бәйле тагын бер тарих – ул мәчеттә Аяз Гыйләҗевнең бабасы Сәхәбетдин хәзрәт мулла булып торган. Аяз Гыйләҗев исән вакытта үзе дә Мортыштамакка кайтып йөргән.

4
Музейның дүртенче залы җирле халыкның көнкүрешенә багышланган.

5
Бу залда гаҗәп матур хатын-кыз киемнәре, бизәнү әйберләре дә бар.

6
– Үткән көн – тарих, – диде музей җитәкчесе Миләүшә Җәлилова.

«ПЛЮШКИН УРЫНЫНА...»

Алда әйтелгәнчә, авылда өч мәчет, мәдрәсә эшләгән. Димәк, халык динле, мәгърифәтле булган. Һәм бу музей экспонатларында да чагыла. Дистәдән артык Коръән китабы, юлъязмалар бар. Алар арасында унҗиденче гасырга караган дини эчтәлектәге китаплар да шактый.

– Коръәннәрне кулга алмыйбыз, – дип пыяла астындагы китапларны күрсәтә Миләүшә Җәлилова. – Алар бик иске, кулга алгач уала. Аларны әби-бабаларыбыз бик кадерләп тоткан. Чүпрәккә төреп. Арада рус китабы тышлыгына беркетелгән Коръән китаплары да бар. Монысы мөгаен дин тыелгач шулай эшләнгәндер – ят күзләрдән саклау өчен. Өйләргә теләсә кайчан тикшерү килеп кергән бит.

Бу залда гаҗәп матур хатын-кыз киемнәре, бизәнү әйберләре дә бар. Барысын да авыл кешеләре бүләк итеп биргән.

– Болар кем өчендер бик кадерле – әниләре, әбиләре истәлеге бит. Ничек аны музейга тапшырдылар? – дим.

– Халык шундый бездә. Нәселе авыл тарихында калуын тели, – ди Миләүшә ханым.

– Кайбер өлкәннәр: «Мин үлгәч, балалар аны барыбер ташлый», – дип, үзләре үк алып килде, – дип сүзгә кушыла Фәнүзә апа. – Ә музейда ул югалмый. Монда бөтен әйбер сыя. Бүген гади әйбер тоелса да, утыз, кырык елдан ул тарих булачак.

– Үткән көн – тарих инде, – дип өсти Миләүшә ханым. – Артык әйберегез булса, монда алып килегез, дип еш әйтәм. Плюшкин урынына әйбер җыябыз. (Көлә. – **Авт.**)

Музейда өч мең экспонат бар. Күргәзмәләрне даими рәвештә яңартып торалар. Күпмедер вакыт залда торган экспонатлар архив бүлмәсенә китә. Аннан янә чыга...

7
Дистәдән артык Коръән китабы, юлъязмалар бар. Алар арасында XVII гасырга караган дини эчтәлектәге китаплар да шактый.

– Кулланылыштан төшеп калган техникага багышланган зал булдырасы килә, – ди музей җитәкчесе. – Авыл җирлеге башлыгы рөхсәт бирде. Мәдәният йортында тагын бер буш бүлмә бар. Менә шуңа алынасы иде.

Музей хезмәткәрләренең тагын бер хыялы – элеккеге кино күрсәтә торган бүлмәгә дә җан өрү. Моның әллә ни авырлыгы да юк кебек – аппаратуралар әле дә шунда тора. Аларны тәртипкә китереп, язып куйсаң, тарихка тагын бер адым якынаю булачак.

Музейның дүртенче залы җирле халыкның көнкүрешенә багышланган. Ул нәкъ егерменче гасыр башындагы авыл өен хәтерләтә – олы мич, янәшәсендә ипи савытлары, табагач тора. Мич янында агач сәке, чыбылдыклы бала бишеге, чигүле япмалар... Ак яулыгын таратып бәйләгән әби белән матур алъяпкычлы, озын толымлы килен генә җитми.

...Әлеге музей заллары Мортыштамак мәдәният йортын тагын да ямьләндерә кебек тоелды. Ул аннан чын мәдәният учагы ясый. Мортыштамакта сәнгатьне яраткан, тарихны аңлаган халык яшәвенә бу тагын бер дәлил булып тора.

Музей эшчәнлегенә зур бишле билгесе куябыз!

БЕЗ ЯШӘГӘН ҺӘМ БЕЗ ЯШӘМӘГӘН ДӨНЬЯЛАР

Автор: Луиза Янсуар

Бу сезон сериалларга шактый бай булды, әле Яңа елга кадәр стримингларга чыгасы яңа ымсындыргыч релизлар да бар. Бер-берсенә бөтенләй охшамаган, әмма шул охшамавы белән кызыклы 2 премьерага тукталып узыйк.

Фотолар:www.kinopoisk.ru, www.goodfon.ru/



ДӘВАЛЫЙ ТОРГАН ЧЫНБАРЛЫК

«Ир белән хатын тормышыннан манзаралар»,18+
Жанры: драма
Иле: АКШ
Сценарий авторлары: Ингмар Бергман, Эми Херцог, Хагай Леви
Режиссеры: Хагай Леви
Студиясе: HBO
Релизы: 4 сентябрь 2021

Ингмар Бергман төшергән һәм кинематографның алтын фондына кергән «Ир белән хатын тормышыннан манзаралар» фильмына ремейк әзерләү, бигрәк тә аннан мини-сериал эшләү, ким дигәндә, көтелмәгән авантюра. Хәер, Бергман үзе үк сериал турында уйлаган, хәтта ниятләгән дә, диләр. Ә инде бу камералы һәм киеренке атмосфераны таләп иткән проектка төп рольләргә Джессика Честейн белән Оскар Айзекны чакыру – бөтенләй дә интрига. Нәкъ бу икәү булачак сериалның реклама кампаниясе башланганда ук инде эстетикасын да, стилен дә билгели иде.

Бергман картинасы фанатлары өчен артык борчылыр урын юк – HBO эпизодларга һәм сериалның фокусына кадәр даһи режиссерның оригинал версиясенә якынлык сакларга тырышкан. Беренче мәртәбә әлеге әсәр белән танышучыларга соңыннан Бергман оригиналын да карарга киңәш итәр идем – сериалда экран тарихын заманчалаштыру өчен әллә ни махсус механизмнар кулланылмый, шуңа да ул бе-



раз ракурсы ягыннан сәер, ялыктыргыч тоелырга мөмкин. Әмма ымсындыргыч. Дөрес, монда гендер һәм ир-ат белән хатын-кызның рольләре үзгәрүе, бер җенес вәкилләре мөнәсәбәтләре турында да сөйләшәләр, ләкин сериал авторлары фильм фактурасына XXI гасыр технологияләре белән реалийләрен көчләп тутырмый һәм шуның белән аның аурасын ямьлирәк төшә, миңа калса.

Шулай да, режиссер керткән иң зур үзгәреш ремейкның бөтен мәгънәви асылын билгели – оригиналда аерылышу инициаторы Йоханн булса, сериал версиясендә бу – Марианна. Биредә без иреннән күбрәк акча эшли торган, үзен җәмгыятьтә бик тә уңышлы дип исәпләүче, ләкин барыбер дә ярату һәм назга сусаган ханым белән очрашабыз. Сериалдагы социаль яссылык – нәкъ без яшәгән чорныкы. Әмма мөнәсәбәтләрне саклап калу проблемасы, гаиләдә бәхетле була алу мәсьәләсе – моның заманы бар микән?

Хагай Леви әйтүенчә, аның өчен Бергман геройларының мораль йөзе әһәмиятле булган. Ул нәкъ менә алардагы чалымнарны үзгәртүне, яңартуны күздә тоткан. Һәм, әйтергә кирәк, Честейн белән Айзек ремейкта катлаулырак һәм күппланлырак. Шул ук вакытта Леви безгә һәр кадрда диярлек тоемларга мөмкинлек калдыра – бу бары тик бер гаилә тарихы һәм аның төзеп булмаслык кысаларга кергән язмышы гына, сез моны гаилә психотерапиясе дип кабул итегез, әмма – шуннан ары түгел.

Атаклы швед режиссерының кайбер биографлары әйтүенчә, «Ир белән хатын тормышыннан манзаралар» фильмы чыккач, Швециядә аерылышулар саны артып китә һәм Бергман моның белән горурлана торган була.

Эре планнар, камераның шуып кына озаклап эмоцияләрне аулавы, әмма тоткарланса да, ул хисләрдән спекуляция ясамыйча, сак эш итүе – бик тә интим, камералы, хәтта ки класустрофобик халәткә китерә. Син үзеңне геройларның аш яки йокы бүлмәсендә итеп кенә түгел, ә башларында итеп тә хис итә башлыйсың. Бер үк вакытта сериал авторлары үтә театраль алымнарга да мөрәҗәгать итә. Шунысын да ассызыкламый булмый: сериалның башыннан алып ахырынача ике герой арасында искиткеч химия барлыгы сизелеп тора. Ул һәр кадрда экраннан бөркелә һәм ышандыра.

HBO әлеге проектын инде стримингларга чыгарды, аны тулаем карарга була. Зур акчалар һәм амбицияләр белән төшерелгән күпчелек проектлардан аермалы буларак, «Ир белән хатын тормышыннан манзаралар» нәкъ менә шул камералы булуы белән кызыклы һәм кадерле. Әйе, бу – фэнтези дөньялары да, блокбастерлар да түгел, ә безнең көндәлек ялыктыргыч та, әчпошыргыч та тормышыбыз. Әмма без бу дөньядан башка планеталарга һәм яссылыкларга чыгып китә алмыйбыз, һәрхәлдә, ракетасыз һәм спонсорларсыз. Ә шул чынбарлыкка Честейн һәм Айзек геройлары аша караганда, моның авырттыра да, шул ук вакытта дәвалый да торган үзенә бер көче бар.

«МИН БҮТӘН КАЛЬМАР АШЫЙ АЛМЫЙМ...»

«Кальмар уены», 18+
Жанры: триллер, детектив, драма
Иле: Көньяк Корея
Сценарий авторы: Хван Дон-хёк
Режиссеры: Хван Дон-хёк
Студиясе: Netflix
Релизы: 17 сентябрь, 2021

Һәм менә чынбарлыкны гипертрофия дәрәҗәсенә җиткереп сурәтләгән, бу елгы иң шау-шулы, хайп дип исәпләнгән сериалга тукталыйк. Һичшиксез, бу – Көньяк Корея кинематографының да, режиссерның да уңышы. Бик яхшы касса җыюларына ия булулары һәм, сериал бюджетын каплап кына калмыйча, аның белән бик яхшы акча эшли алулары турында әйтеп тә торасы юк. Иң кызыгы – сериал үзе үк шул темаларга кагыла һәм аларны безгә үтә сискәндергеч, кансыз һәм кешелексез яссылыкта тәкъдим итә...

Сериалның Young Adult аудиториядә зур кызыксыну уятуы һәм бүгенге заман яшүсмерләренә бик тә ошавы турында сүз Интернет мәйданында инде күп булды. Аны хәтта «яшьләрне боза» дигән гаепләү тамгасы сугып, Россиядә күрсәтүне тыярга сораучылар да табылды. Әмма ул тыелмады, алай гына да түгел, һаман да стримингларда рекордлы караучылар санын җыюын дәвам итә.

Дөресен генә әйткәндә, мондый төр тематикага кагылган һәм көч куллануны бар детальләре белән күрсәткән картиналар, сериаллар моңа кадәр дә булды, арада бик популярлары бар иде, артык күзгә чалынмый калучылары, билгеле, күбрәк. Ни өчен нәкъ менә «Кальмар уены» шулкадәр бәгырьгә үтәрлек тәэсир калдыра соң? Югыйсә, без экранда бик тә таныш, хәтта инде күп фильмнарда һәм сериалларда кабатланган сюжет белән очрашабыз – маска киеп алган берәү ангарда бер төркем кешене җыя да аларны кыргый, кагыйдәләре коточкыч булган уенга җәлеп итә, азакта исән калучыны 45,6 миллиард вона (40 миллион доллардан артыграк) көтә. Безнең, әйтерсең, Стэнфорд экспериментына нигезләнгән яки башка шок халәтенә китерердәй фильмнарны караганыбыз юк, монда нәрсәдер башкачарак тәэсир итә... Нәрсә соң, дип баш ватасың. Минем яшүсмер бер туганым тәэсирләре белән болай уртаклашты: «Шундый үзенә суырып ала, карыйсың һәм туктый алмыйсың, дөньяның чыннан да кемнәрдер тарафыннан «махсус ясалган» булуына ышанасың, укшыйсың, сокланасың... мин ул сериалдан соң бүтән кальмар ашый алмыйм».

Октябрь азагында Netflix сериалның фанатлары саны 111 миллионга җитте, бу безнең тарихыбыздагы иң масштаблы проект, дип игълан бирде. Шулай ук сериалдагы кебек спорт костюмнарына, гомумән сериал белән бәйле мерчка сорау бик нык арткан булуын шәрехләде.

Сериалның режиссер тарафыннан һәм үз мәдәнияте, һәм Көнбатыш мәдәнияте вәкилләренә җиткерергә теләгән төп мотивларыннан берсе, миңа калса, Тарантино стилендәгечәрәк – әй, менә мин сезгә канлы калҗалар күрсәтәм, махсус бер стилистикада, эстетикада күрсәтәм, сез шуларны гына күрәсезме, әллә минем әйтергә теләгәнемне дә ишетәсезме? Ә-ә-әй?!

Әйе, билгеле бу – караучы үзаңы һәм психологиясе белән спекуляция ясау, аны комфорт зонасыннан чыгарып, тотып селкү. Әмма бит Хван Дон-хёк нәкъ шул ысулны кулланмый торып, кешеләр үзләренең чын-чынлап көндәлек чабышта булуларын, система коллары икәнлекләрен ваемламаска да мөмкин. Президентларның, илләрнең, сәяси партияләрнең, банкларның коллары. Шуңа да картинада анык кына төп герой да, тогәл генә коткарырга, якларга теләгән персонаж да юк, бу – ялган ясалма карнавал һәм менә-менә шартлап юкка чыгам, ә аннан тагын бер ялган тудырам дип янап торган декорацияләр. Бу – үзенә күрә бер кәмит шоу да, сызлангыч ритуал хор да.

Әйтүләре буенча, Корея кредитлар саны буенча дөньякүләм лидерлар исемлегендә, һәм халыкның психологиясендә бу, билгеле, чагылмый калмый. Әмма безнең Җир планетасында хәзер системага бурычлы булмыйча ирекле яши алган берәүне дә эзләп тапмаслык түгелме соң?

...Ә ул арада тамашачы үз ипие белән корбанын тагын да көтә – 2 нче сезонда «Кальмар уенында» нәрсә булачагы турында бүген инде аермачык сүз куерталар.

МӘЧЕТЛЕ ОЛЫ ЕЛГА

Автор: Руфия Фазылова

Берничә ел элек Лаеш районының Кече Елга авылы турында язган идек. Шулчак җирле халык Олы Елга авылын еш искә алды. Зур юл гына бүлеп торган бу ике авыл гомергә дус яшәгән. Югыйсә берсе Лаеш, икенчесе Балык Бистәсе районына карый. Һәм менә җай чыкты – ноябрьнең яңгырсыз бер көнендә Олы Елгага кузгалдык.



Фото: Александр Ефремов

ОЛЫ ЕЛГА

КАЙТУ...

Олы Елга зур авыл. 954 кеше яши, 338 хуҗалык бар. Өлкәннәр сөйләве буенча, элек тә авылда халык саны якынча шул тирә булган. Аны үсеп бара торган авыллар рәтенә кертергә кирәк. Ел саен яңа йортлар калкып чыга. Быел сигез бала туган. Балалар бакчасына кырыкка якын бала йөри, ә урта мәктәптә 103 укучы белем ала.

Соңгы елларда Олы Елга журналистлар теленә еш керде. (Бу хакта безнең журнал да язды.) Ни өчен дигәндә, өч ел элек авылның 1879 елда төзелгән мәчет бинасын реставрациягә Вологда өлкәсендәге Кириллов шәһәренә алып киттеләр. Бүрәнәләрне шулай еракка алып китүнең сәбәбе – Татарстанда борынгы объектларны төзекләндерүче осталар юк, дип аңлатты моның өчен җаваплы кешеләр. Шуңа да тәҗрибәле оста – Александр Поповка мөрәҗәгать иткәннәр. Ә аның остаханәсе Кириллов шәһәрендә икән.

Дөресен әйтим, тарихи мәчетнең әнә шулай ике мең чакрымга китүенә авыл халкының эче бик пошты. «Тарихи бина кайтырмы?» – дип борчылдылар. Алар өчен мәчет бик кадерле, изге бина... Совет чорында күрше авыл кешеләре Олы Елганы «мәчетле авыл» дип йөрткән. Бөтен республикада манарасы калкып торган сирәк гыйбадәтханәләрнең берсе Олы Елгада булган. Бу урында шуны әйтми кала алмыйм: 1930 нчы елларда мәчетнең манарасын кисәргә дип, авылга читтән кешеләр килгән. Шулвакыт давыл чыгып, күктә кап-кара болытлар куерган. Килгән кешеләр, бу хәлне күреп, кире киткән. Шулай итеп, авылда мәчет манарасы торып калган. Әлбәттә, ул совет чорында гыйбадәтханә булмый. Аннан колхоз амбары ясыйлар – ашлык белән ашлама саклыйлар.

Дин ирегә кире кайткач, ягъни 1990 нчы еллар башында, авылның аксакалы Исмәгыйль Мөхәммәтов, район җитәкчеләреннән рөхсәт сорап, иман йортын ашламадан арындыра.

Аңлашыла ки, гасыр ярым элек сафка баскан мәчет бинасы искерә. Менә шуңа да аңа реставрация ясарга хәл итәләр. Инде әйткәнемчә, мәчетне сүтеп, Кириллов шәһәрендәге остаханәгә алып китәләр. Тик берничә ай узгач, ат тәртәгә тибә: Александр Попов, сөйләшенгән сумма (20 миллион сум) җитмәде дип, төзекләндерү эшләрен тукта-

1 2
– Мәчетнең 70 проценты үзенеке дип ышандырдылар безгә, – диде әлеге иман йортының мулласы Таһир Гайнетдинов.

та. Һәм борынгы мәчет бинасының язмышы ярты юлда торып кала.

Эшләр зурга киткәч, килеп туган проблемага ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов кушыла. Александр Попов белән онлайн очрашу уздыра ул. Нәтиҗәдә, мәчет бинасын кире Татарстанга алып кайту турында килешенә.

Вологда өлкәсеннән мәчет бүрәнәләре быел февраль башында кайта башлый. Аны Лаеш районындагы остаханәгә урнаштыралар.

– Мәчетнең 70 проценты борынгы, үз материалы, дип ышандырдылар безгә, – диде әлеге иман йортының мулласы Таһир Гайнетдинов. – Бүрәнәләрнең астагы өч рәте алышынган. Матчаларның искеләрен яңартканнар. Ә инде идән, такталар яңа. Дөрес, арада элеккеге – үз такталары да бар.

Тагын шунысын әйтим: Олы Елгада бүген ике мәчет. Элек тә авыл ике мәхәлләгә бүленгән булган. Ерак түгел кызыл кирпечтән таш мәчет бар. Анда да шактый халык йөри.

– Җирле халык монысын «Иске мәчет», тегесен «Яңа мәчет» дип атап йөри иде, – ди Таһир хәзрәт. – Хәзер инде монысын «Иске яңа мәчет» дип атыйлар. Узган җомга намазында егерме җиде ир-ат бар иде. Ә көндәлек өйлә намазларына ун кеше йөри.

– Мәчет бинасы кайтмас дигән куркыныч уйлар булдымы? – дим.

– Бермәл күңелгә андый шик кереп алды. Авылга полициядән, прокуратурадан кадәр килделәр. Комиссия белән ике тапкыр үзебез дә Кириллов шәһәренә бардык. Инде ахыры хәерле бетте. Шуңа бик сөендек.

– Мәчет бүрәнәләре яңгырда, карда, җир өстендә яткан, диделәр. Бу дөресме?

– Без барганда мәчет бүрәнәләре инде эшләнеп, өелеп куелган, дөрес, башы ябылмаган иде. Ә менә Кама Тамагы Keләр (Архангельские Кляри) чиркәве бүрәнәләре шул килеш җирдә ята. Александр Попов теге вакыт мәчет белән чиркәүне дә реставрациягә алып киткән иде бит.

Яңартылган мәчетне тулысынча карап чыктык. Матур дию генә бу очракта аз! Күңелне гаҗәп бер рәхәт нур биләп ала... Бер мизгелдә әлеге иман йорты чынлап та гайре бер көчкә ия тоелды. (Мәчет белән бәйле гаҗәп хәллләр

күп булган.) Яңартылган мәчет бинасы белән янәшә аерым юыну бүлмәсе эшләп куйганнар. Заманча, ир-атлар, хатын-кызлар өчен аерым ул. Монысы Рөстәм Миңнехановның бүләге икән. Мәчет ишегалдына таш (брусчатка) җәелгән, куаклар утыртылган. Җирле халык өчен чын күңелдән сөендек. Тарихлы мәчет әлеге урында тагын озак еллар халыкка иман нуры таратсын, дип теләп, авыл буенча сәяхәтне дәвам иттек.

«БАЛАЛАРЫБЫЗ – АЛЛАҺ БҮЛӘГЕ»

Олы Елгада ике, өч балалы гаиләләр шактый. Хәтта биш балалы яшь гаилә дә бар икән. Гаилә башлыгы Рафаэль Әхмәдиев кырык ике яшен тутырган, Миләүшәгә – кырык. Ир белән хатын икесе дә Олы Елганыкылар, гаилә корганнарына унтугыз ел булган. Берничә ел элек ике катлы йорт салып чыкканнар. Күп итеп мал асрап, үз көчләре белән тормыш итеп яталар.

– Төп эш урыным «Кама-Агро»да, – диде Рафаэль. – Хәзер бит колхозлар урынына агрофирмалар калды. Механизатор мин, кыш көне фермада эшлим. Фермада мөгезле эре терлек шактый әле. Эшлим дигән кешегә эш бар.

Миләүшә балалар бакчасында кече тәрбияче булган, әлегә бала ялында.

Яңа елдан соң эшкә чыгу нияте бар икән.

– Бүгенге көн өчен биш бала күп. Ничек батырчылык иттегез? – дим ана кешегә.

– Балаларыбыз – Аллаһ бүләге. Рафаэль дә, мин дә гаиләдә өч бала үстек. Биш бала ук алып кайтырбыз дип уйлаганыбыз булмады. Беренче, икенче бала белән генә кыен икән ул, аннары сизмисең дә. Бер-берсенә ярдәм итәләр. Акмаса да тама – дәүләт тә ярдәм итә бит.

– Дәүләттән нинди ярдәм аласыз? – дим.

– Балалар мәктәптә бушка туклана, зурлары да. Йорт салганда бер миллион сумнан артык субсидия алдык. Утка, газга ташламалар бар. Юл акчасы, бүтәне дигәндәй. Аннары, без балаларны үзебез өчен алып кайттык. «Минем фәлән бала, ярдәм итегез», – дип йөргән кешеләргә аптырыйм.

Ярдәм дигәннән, Әхмәдиевләр ул яктан бәхетле – икесенең дә әти-әниләре Олы Елгада яши. Балалар үстерешергә алар бик булышкан. Хәзер дә шулай. (Миләүшәнең әнисе күршедә генә яши, без барганда да аларда иде.)

– Әти-әниләргә рәхмәтебез зур, – диде биш бала анасы. – Зур терәк алар. Хәер, аларга да без авылда калгач күңелле дип уйлыйм. Зур эшләрне кумәкләп башкарабыз. Башта җыелып бер йортка, аннан икенчесенә барабыз. Эштән курыкмыйбыз. Шуңа күрә авылда калдык та. Рафаэль дә, мин дә бер көн дә шәһәрдә яшәмәдек.

Әхмәдиевләрнең олы кызлары, тугызны тәмамлап, Казанда техникумга укырга кергән.



3

Уллары Фирдүс Олы Елга мәктәбенең сигезенче сыйныфында укый, өченчеләре Фаризга сигез яшь, ул икенче сыйныфта белем ала. Ә дүртенче балалары Фирдәвескә җиде тула, әлегә балалар бакчасына йөри. Төпчек уллары Фирзәргә – яшь тә ике ай.

– Яшь барган саен бала тәмен аңлыйсың икән, – дип елмая Рафаэль. – Олыраклары үскәнен күрмәдем дә кебек – гел эштә булдым. Бу ике кечкенәсе күбрәк минем янда. Фирдәвес кызым бигрәк якын итә, эштән кайтуга йөгереп килә.

Күп балалы әлеге тырыш гаиләгә иминлек телибез. Кем белгән, бәлки әле бу нигездә тагын сабый тавышы ишетелер. Һәрхәлдә, «юк» дип өздереп әйтмәделәр.

ҮҖӘТЛЕК

Авыл олы юл буенда урнашкан, дидем. Казанга кадәр җитмеш биш чакрым ара. Шуңа да җирле халык читкә йөреп эшли, бигрәк тә яшьләр. Авыл башында ягулык салу станциясе, машина юа торган урын бар. Аэропортка йөреп эшләүчеләр дә байтак, махсус автобус килеп ала икән. Кыскасы, биредә ир-атлар да, хатын-кызлар да эшсезлектән интекми.

Олы Елгада данлыклы фермерлар бар – Исмәгыйлевлар. Алар бүген тирә-як районнарны, Казанны сөт продуктлары белән тәэмин итә. Гаилә башлыгы Минзөфәр абый үз эшен егерме ел элек башлаган. Дөрес, сөт продуктларын соңрак – 2007 елда гына җитештерүгә керешкән. Фермер, башта җирләрне арендага алып, иген, печән үстергән, мөгезле эре терлек үрчеткән.

– Бүгенгесе көндә сөт заводында гына да егермеләп кеше эшли, – ди Илфар Исмәгыйлев. – Моннан тыш, сигез йөз гектарга якын

3 Биш балалы Әхмәдиевләр гаиләсе.

4 – Бүгенгесе көндә сөт заводында гына да егермеләп кеше эшли, – диде Илфар Исмәгыйлев.

җиребез бар. Анда да механизаторлар эшли. Сезонлы эш.

Илфар – этисенең уң кулы. 2012 елда КХТИны тәмамлап, туган авылына кайткан. Гаиләсе белән бүген аерым йортта яши.

– Мин мәктәптә укыганда, эти фермерлык эше белән шөгыльләнә башлады, – диде ул. – Гел аның янында идем. Шуңа да югары белем алып, этинең ярдәмчесе буласым килде. Ә менә энемә фермерлык эше кызык түгел – ул табиб булачак, КДМУда белем ала.

Исмәгыйлевлар хуҗалыгында бүген тәүлегенә ун тоннадан артык сөт эшкәртелә. Бу сезонга карап икән – язын сөт арта, көзгә таба кими.

– Хәзер безнең продукцияне беләләр, даими сатып алучыларыбыз бар, – диде Илфар. – Әлбәттә, эш башлаган чорда этигә бик җиңел булмады.

– Әтиегезнең фермерлык юнәлешендә эш тәҗрибәсе бар идеме? – дим.

– Юк. Эти полиция, ДАИ хезмәтендә эшләде. Алар бит лаеклы ялга иртә чыга. Утыз тугыз яшендә ул энә шулай бөтенләй яңа өлкә буенча китте.

Исмәгыйлевлар бүген алты төрле ит продукциясе дә җитештерә. Шулай ук Балык Бистәсенең һәм республиканың төрле сәүдә үзәкләренә сатуга чыгаралар.

– Эре челтәрле сәүдә үзәкләрендә безнең продукция юк, – диде Илфар. – Казанга продукцияне үзебезнең машина белән алып барабыз, көн дә шулай. Базарларда аерым бер билгеләнгән урыннар бар.

Исмәгыйлевлар, берничә фермер белән берләшеп, кооператив оештырган. Монда барысы да алдан уйланган – бер фермер иген, печән үстерә, икенчесе ит җитештерә, сөт сава.

– Кооперативта үзебезнең район фермерлары, күршедән дә бар, – ди Илфар Исмәгыйлев. – Әлбәттә, болай эшләүнең уңай, тискәре яклары да бар. Тик үзең генә шуның кадәр күләмне алып барып булмый. Бер фермер фәлән тонна сөт савып, ит җитештереп өлгертә алмый.

Бу очракта шуңа сөендем: Балык Бистәсендә фермерларга эшләргә юл биргәннәр. Кызганыч, республика буенча йөргәндә, район җитәкчеләренең фермерларны кысу очракларын еш ишетәбез.

«ӨЕБЕЗНЕҢ НУРЫ УЛ!»

Олы Елгага баргач, сөйкемле бер әби белән таныштык – Мәүлия апа Хәйретдинова. Улы Мансур, килене Гөлсинә белән яши ул. Килен-кайнана булып яшәүләренә кырык ике ел вакыт узган. Әбекәй киләсе елга сиксән биш яшен тутыра.

– Үзем дә этисез үстем, ул сугыштан кайтмады. Балаларга да эти канаты бик эләкмәде, – диде Мәүлия апа. – Кырык яшемдә тол кал-

дым. Иремнең бавыры авырта иде. Нишлисең, балаларны аякка бастырырга кирәк – гел хезмәттә булдым. Төзелештә эшләдем мин. 1972 елда авылда төзелеш бригадасы оештырдылар. Без анда унсигез хатын-кыз идек. Район буенча да йөрдек. Авылның клубын, мәктәбен, авыл җирлеге идарәсе бинасын без салдык.

Мәүлия апа бер ул, ике кыз үстергән. Кызларның берсе гаиләсе белән Олы Елгада гомер итә, икенчесе Казанда яши.

– Гөлсинә – өченче кызым, – диде әбекәй.

Мансур абый белән Гөлсинә апа башлангыч сыйныфта бергә укыганнар. Бишенчегә күчкәч, берсен «А», икенчесен «Б» сыйныфына күчергәннәр. Мәктәпне тәмамлагач, икесе арасында җылы хисләр уянган. Инде егет армиядән әйләнеп кайткач, яшьләр кавышкан.

– Әлеге нигезгә килен булып килгәч, егерме бер тулды, – диде Гөлсинә апа. – Яшь вакытта мин бу йортның барлыгын да белми идем. Авыл зур бит, без югары очта яшәдек.

Ир белән хатын өч бала үстергән – бер малай, ике кыз. Уллары Балык Бистәсендә яши, кызлар Казанда гомер итә. Мансур абый белән Гөлсинә апа лаеклы ялга чыккан инде. Шулай булса да, хуҗалыклары зур – малтуар, кош-корт асрыйлар. Бакчалары да зур.

– Бакчаны әни карый, – диде Мансур абый. – Ул безгә караганда иртәрәк тә торып чыгып китә әле. Тынгысыз кеше, тик утыра белми. Аллага шөкер, бүген дә шулай. Өй тулы гөлләр дә аның хезмәте. Элек малларны да ул карый иде, хәзер инде чыгармыйбыз.

Мәүлия апа кулга оста. Гомер буе бәйләгән. Бүген дә кулы буш тормый. Заманында шәлләр дә бәйләп саткан. Хәзер сорау булмагач, ул эшен ташлаган. Бүген ул урындык япкычлары, бияләй, башмаклар бәйли.

– Оныкларга, туганнарга бүләк итәм, – ди әбекәй.

Сөйкемле әбекәй улына, килененә әллә ничә тапкыр рәхмәт әйтте.

– Картлыгымны ялгыз үткәрмим, бу бик зур бәхет, – диде. – Мансур белән Гөлсинәгә: «Төп йортны ташлап чыгып китмәгез», – дип әйттем. Сүземне тыңладылар. Алланың рәхмәте булсын.

...Олы Елга. Авылның исеме җисеменә туры килә – урамнары киң, йортлар күп биредә. Ә халкының күңеле ачык, киң. Нинди зур сала булуына карамастан, юлсыз урамнар юк, шунысына сөендек. Гомумән, Олы Елга өчен шатланып кайттык – киләчәге өметле аның! Т

5
Мәүлия Хәйретдинова улы Мансур, килене Гөлсинә белән яши.

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

Хәтимә Солтанова, Олы Елга авылы
Туган якны өйрәнү музее җитәкчесе:
– Нугай юлы өстендә Олы Елга һәм Икенче Елга (Кече Елга) дип йөртелгән авыллар Казан ханлыгы чорында да булган. Казан өязе теркәү кенәгәсендә (1602-1603 еллар) Олы Елга авылында йомышлы һәм ясаклы татарлар яшәве әйтелә. Шулай ук биредә археологлар болгар чорына караган ике зират һәм авыл хәрабәсе тапкан. Д. А. Корсаковның XVIII гасыр тарихын үз эченә алган хезмәтендә Олы Елга авылы да искә алына. Биредә ясаклы 278 татар кешесе яши, дип күрсәтә.
Олы Елга халык телендә Олы Юлга исеме белән йөри. Авылның исеме Казанга илтә торган олы юл буенда урнашуга бәйле дигән фикер бар. Һәм бу дөреслеккә бик туры килә кебек.

АЙ КӘЕФЕ: КАРИКАТУРАЛЫ

«Чаян» журналын сез дә безнең кебек үк яратасызмы? «Чаян» журналы үзенең искиткеч рәссамы Борис Старчиковның йөз еллык юбилеен билгеләп үтә – «Татмедиа» галереясында аның эшләреннән күргәзмә ачылды.

– Предлагаю выбрать в родительский комитет штукатура Иванова и паркетчика Сидорова.

Фото: «Татар-информ» МА. Реклама. 16+

РСФСР ның атказанган рәссамы Борис Александрович Старчиков «Чаян» журналының баш рәссамы булып ун ел – 1957–1967 елларда эшли.

Ул дәвердәге күп кенә совет кешесенеке кебек үк, аның тормышы да бик катлаулы була. Мәскәүдә туа, Мәскәү консерваториясе каршындагы сәләтле балалар өчен музыка мәктәбендә укый. 1939 елда мәктәпне тәмамлагач, сәнгать институтына укырга керергә ниятли һәм үзешчән рәссамнар студиясендә шөгыльләнә башлый. Институтка керергә өлгерми, армиягә алалар.

Сугыш вакытында Украина фронтында санитар булып хезмәт итә. Һәм кече комсостав әзерләү мәктәбе ансамбленең сәнгать җитәкчесе була. Сугыш аның өчен Польшада тәмамлана. Яла ягылып, 58 нче маддә буенча кулга алына һәм советларга каршы әдәбият саклаган өчен сигез елга лагерьга сөрелә.

Хөкем срогын Коми АССРда үтә, Борис Александрович өчен һөнәри рәссамлык эше шунда башлана. Аңа танылган картиналарның күчермәләрен, пейзажлар, плакатлар, портретлар ясарга, скульптура белән шөгыльләнергә туры килә. Ул боларны шулкадәр оста башкара ки, Төньяк тимер юл хезмәттөзәтү лагереның (Севжелдорлаг) Микунь бистәсендә аның белән бергә эшләгән профессиональ рәссам Старчиковның сәнгать буенча белеме булмавына ышанмый.

Бүген Микунь китапханәсе аның исемен йөртә, Мәдәният йортында ул ясаган рәсемнәр, төбәкне өйрәнү музеенда исә рәссамның хезмәтләре һәм шәхси әйберләре саклана.

1953 елда азат ителгәннән соң, Борис Старчиков Казанга килә, сәнгать училищесында укый. Ун ел буе «Чаян» татар сатира журналының баш рәссамы булып эшли, киләчәктә Казан карикатура мәктәбенең нигезен тәшкил итәчәк талантлы рәссам-графикларны редакция тирәсендә туплый. 1970 елда Мәскәүгә күчենә һәм «Крокодил» журналы белән актив хезмәттәшлек итә.



– А ну, гражданин, повторите: "На дворе трава, на траве дрова..."

– По ноге вижу, быть тебе рекордсменом!

–Баба Яга, ваша избушка идёт под снос – здесь будет новая трасса!

– Вот разрешение на вырубку новогодней ёлочки...

«Чаян» – һаман минем өем булып кала! – дия торган була Борис Александрович. – Анда минем иң бәхетле елларым үтте. Бу бит ун ел буена саннан санга көндәлек эш дигән сүз! «Чаян»ны сагынам. Минем тамырларым анда!»

«Чаян» да Старчиковны сагына. Рәссамның карикатуралары хәзер дә актуаль – моңа аның «Татмедиа» галереясындагы күргәзмәсендә инана аласыз.

– Вам не стыдно такое показывать детям?

«ТАТАРСТАН»НЫҢ КИЛӘСЕ САНЫНДА:

«Совет Социалистик Республикалар Союзы – 1922 елның 30 декабреннән 1991 елның 26 декабренә кадәр яшәгән дәүләт» – дип укырга мөмкин бүген Википедиядә. Ягъни быелның декабрендә дәүләтнең таркалуына – 30 ел, ә киләсе елның декабрендә аның оешуына 100 ел була. Дәүләтнең чишмә башы белән аның таркалуын символлаштырган ике ел чиге үткәннәрне искә алуга бер сәбәп дип уйлыйбыз, шул ук вакытта совет чорыннан калган мирасның бүгенгегә ничек әверелүен карарга да менә дигән форсат туа. Чор-дәверләр алмашканда исән калган нәрсәләрнең бүгенге көндә яңа сыйфатта ничек яшәвен карарга... Җимерелеп, илнең үзе белән бергә тарих чоңгылына кереп югалганнарны да...

СССРда ЭШЛӘНГӘН

Республикабызда алдынгы колхозлар калдымы?

Татарстанда ничә Ленин һәйкәле бар?

Казандагы нинди заводлар совет чорындагы күрсәткечләрне куып җитте һәм узып китте?

Советныкы булмаган айныткычларда эчүчелек белән ничек көрәшәләр?

Коммуналка буенча элеккеге күршеләр кайда очрашалар?

ТАТМЕДИА

ТАТМЕДИА ГАЗЕТА-ЖУРНАЛЛАРЫ ҺӘМ ОТКРЫТКАЛАРЫ — МАРКЕТПЛЕЙСЛАРДА

WILDBERRIES

KazanExpress

OZON

Я Маркет

АО «ТАТМЕДИА». Адрес: 420066 г. Казань, ул. Декабристов, 2. ГРН 1071690057834

16+

Реклама

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘРҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

Реклама 16+

Безнең Инстаграмда –
«Татарстан»ның йөрәге!